

# Уйныйк, куаныйк әле...

**(Балалар бакчасында уеннар)**

Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма





ТҮБӘ
КҮРШЕ
УМАРТА
ул үрдәк
умырзая
ит
зәңгәр
ҮЛӘН
СҮЗ
сулыш
сыйфат
сум
нәрсә
өй
заман
ЗАТ
мөһим
кыяр
һәйкәл
ОЧРАШУ
ЗИННҺАР
юл
лачын
кыш
ләкләк
көчтәнәч
өн
җөмһүрият
АТ
олы
ел
ЕЛ
мәхәббәт
пәрәмәч
елга
нечкә
оста
кибет
песи
ТӨЗ
кадерле
сабан
нигез
ЭТ
дуслашырга
гөбәдия
вак
ерткыч
исә
кайдан
үрдәк
лаек
ЯЛ
оя
озак
океан
кызыл
ҮЗ
оча
дуслык
гадел
вазыйфа
егет
ещ
дарухана
дүрт
ут
җавап
егерменче
кавын
олы
УСМЕР
ОН
НЕФТЬ
күрше
очрашу
һәйкәл
җөмлә
кыяр
нәрсә
хәл
нигез
җомга
ҖИТМЕШ
чүл
КЫЙБАТ
кыйммәтле
һәм
мәңгегә
һава
нәни
һәрвакыт
җылыта

УДК 821.512.145-343.4
ББК 83.84(2=632.3)-45

Автор
**К. В. Закирова**

Рецензентлар:
**М. З. Закирова**, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары, п.ф.к.
**Л. Н. Ногманова**, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАББУ ректоры, п.ф.д.
**Й. Ш. Хисамиева**, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы

**К. В. Закирова**
Уйныйк, куаныйк әле... (балалар бакчасында уеннар): балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2022. – 160 бит.

ISBN 978-5-6046008-2-5

Китап төбәкнең «Куаныч» дип исемләнгән мәктәпкәчә белем бирү программасына (авторы Р.К. Шәехова) туры китереп иҗат ителде.

Җыентыкка тупланган уеннарның эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен катлаулы түгел, гади һәм аңлаешлы, шул ук вакытта кызыклы, мавыктыргыч та. Алар нәниләрдә кыюлык, җитезлек, игътибарлылык кебек әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итә.

Китап балалар бакчасы тәрбиячеләренә һәм физкультура инструкторларына атап чыгарыла. Аннан педагогия көллияте студентлары, башлангыч сыйныф укытучылары, озайтылган көн төркемендә эшләүче педагоглар һәм әти-әниләр дә файдалана ала.

ISBN 978-5-6046008-2-5

© К. В. Закирова, 2022
© Бизәлеш.
Татар балалар нәшрияты, 2022
Барлык хокуклар да якланган

К.В. ЗАКИРОВА

# Уйныйк, куаныйк әле...

**(Балалар бакчасында уеннар)**

*Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма*

КАЗАН
ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
2022

# КЕРЕШ

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган (17.10. 2013 № 1155) «Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты»ның (алга таба – ФДББС. – авт.) «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе баланың мәктәпкәчә балачагын тулыканлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә; балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру бурычларын билгели. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында әлеге бурычлар төрле юллар (махсус физкультура шөгыльләре, чыныктыру чаралары, гимнастика күнегәләре һ.б.) белән гамәлгә ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе, үтемлесе һәм нәтиҗәлесе – ***уеннар.***

Уеннар, тәрбия чарасы буларак, баланың шәхес булып формалашуына зур йогынты ясый. Уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Физик активлык балаларда җитезлек, өлгерлек, кыюлык сыйфатлары тәрбияләү белән беррәттән, нәниләрнең игътибарын арттыруга, хәтерләрен үстерүгә дә булышлык итә. Алай гына да түгел, алар нәниләрдә дуслык, иптәшлек, гаделлек, зирәклек кебек әхлакый сыйфатлар да тәрбияли. Уеннар нәниләрнен иҗади мөмкинлекләрен, хыялларын баетуда, фикер активлыгы һәм зиһеннәрен үстерүдә ныклы этәргеч булып тора.

ФДББС нигезендә төзелгән төбәкнең **«Куаныч»** исемле мәктәпкәчә белем бирү программасында ***(Р.К. Шәехова. Казан, 2022)*** «хәрәкәтле уеннар аша җитезлек, тизлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү; балаларның халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү һ.б.»* бурычлары күрсәтелә.

**«Куанычым-багалмам»** җыентыгы балалар бакчаларында эшләүче барлык педагогларга әлеге бурычларны гамәлгә ашыруда ярдәмлек буларак иҗат ителде.

Китап өч бүлектән тора. ***«Балачак – матур чагыбыз...» исемле I бүлеккә*** тулысы белән „Куаныч» программасында күрсәтелгән уеннар тупланды. Уеннар балаларнын психологик үзенчәлекләрен истә тотып, яшь аермалыкларына карап, һәр төркем өчен бүленеп бирелде: беренче һәм икенче кечкенәләр, уртанчылар, зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәре.

• Р.К. Шәехова. Төбәкнең «Куаныч» мәктәпкәчә белем бирү программасы. – Казан:, 2022.

Җыентыкта физик тәрбия чарасы булу ягынннан зур әһәмияткә ия булган ***хәрәкәтле уеннарга*** нык игътибар бирелде. Әлеге уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлеген ныгыта, аларның хәрәкәт координациясен яхшырта. Уен кагыйдәләренә буйсыну балаларда чыдамлык, ихтыяр көче, сабырлык тәрбияли. Нәниләр үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәнәләр. Уртак шатлык, күмәк ярышу балаларны шәхес буларак үстерә, камилләштерә.

Хәрәкәтле уеннар үзләре дә йөгерүле, сикерүле, ыргытулы, үрмәләүле һ.б шундый төрләргә бүленәләр. Китапта алар төрләре буенча бер урынгарак урнаштырылды: һәр төркемдә иң башта йөгерүле уеннар, алар артыннан сикерүле, аннары үрмәләү һәм шуышулы, алардан соң ыргыту һәм тотып алу уеннары, туплы уеннар килә.

Соңгы елларда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, нәниләрне туган халкының рухи-әхлакый һәм милли-мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү белән беррәттән, башка милләт вәкилләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыруга җитди игътибар бирелә. Әлеге максатларны истә тотып, беренче бүлеккә татар халык уеннары белән беррәттән, рус һәм янәшәбездә яшәүче башка *тугандаш халыкларның уеннары* да кертелде. Бу уеннар балаларда Идел буенда яшәүче төрле милләт вәкилләренә, аларның гореф-гадәт, йолаларына ихтирамлы мөнәсәбәт тудыруда; башкаларны ихтирам итү, кешелеклелек, тату яшәү һ.б. шундый матур әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә ярдәмче булыр. Аларны катнаш төркемнәрдә, шулай ук мәдәниятара багланышларны ныгыту максатында, татар балаларын башка милләтләрнең мәдәнияте белән таныштырганда файдаланырга мөмкин.

***«Без уйныйбыз, уйныйбыз» дип исемләнгән II бүлектә*** уеннар хәрәкәтле уеннарның төрләре (йөгерүле, сикерүле, ыргытулы, үрмәләүле һ.б.) буенча тупланды.

Хәрәкәтле уеннар күп очракта күмәкләшеп уйнала. Бер төркем булып уйнау, уенның бербөтенлеген сакларга омтылу балаларның үзара мөнәсәбәтләре ныгуга ярдәм итә, тәртип сакларга өйрәтә, күмәк уен барышында бер-береңә ярдәм итү, теләктәшлек хисләре тәрбияләнә. Уртак максат, уртак тойгылар балаларны берләштерә, дуслаштыра. Иптәшләре алдында югалып калмау, уен барышында туган ситуацияләрдән оста чыга алу баланы эмоциональ яктан ныгыта, аның башкалар алдында дәрәҗәсен үстерә. Уен барышында

билгеләнгән кагыйдә һәм таләпләргә буйсыну баланы башкалар алдында һәм җәмгыятьтә үз-үзен дөрес тотарга өйрәтә. Нәниләр дөреслеккә омтыла, тәртипле һәм түземле булырга өйрәнәләр. Шулай итеп, хәрәкәтле уеннар бала организмын ныгытып кына калмый, аның зирәклеген, дикъкатен, ихтыяр көчен, игътибарлылыгын арттырырга ярдәм итә.

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасында «балаларны илдә барган спорт өлкәсендәге яңалыклар, уңыш-казанышлар һәм спорт уеннары белән таныштыру; кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру» бурычлары күрсәтелгән. Әлеге бурычларны гамәлгә ашыруда ярдәмлек буларак, бу бүлектә ярышлы уеннар, ярыш-эстафеталар, уен-аттракционнар тупланып бирелде. Шулай ук, спорт уеннарының милли варианты буларак, *кече Сабантуй уеннары* кертелде, әлеге уеннарның үткәрү тәртибе күрсәтелде. Һәр уен алдыннан бәйрәмне алып баручы яисә уенда катнашучы бала тарафыннан сөйли торган шигырьләр бирелде. Алар сабыйларның милли уеннар белән кызыксынуларын арттырырга ярдәм итәләр.

Балалар бакчасында эшләүче күп кенә педагогларның сорауларын истә тотып тупланган кышкы уеннар да әлеге бүлектә урын алды. Шуны истә тоту мөһим: кышкы уеннарны оештырганда иң беренче чиратта куркынычсызлык чараларын уйлау кирәк. Балалар авызларына кар, боз капмасыннар. Киемнәре хәрәкәтләнергә комачауламаслык булсын. Аларны артык тиз хәрәкәтләнеп тирләү яисә аз хәрәкәтләнү нәтиҗәсендә туңудан сакларга кирәк.

Сабыйларны тәрбияләүдә иң мөһим һәм алыштыргысыз чараларның берсе – *халык уеннары*.

Уеннар элек-электән күңел ачу чарасы гына булып калмыйча, иң беренче чиратта тирә-юньне, дөньяны танып-белүдә, тормышта иң кирәкле булган белем һәм күнекмәләрне үзләштерүдә дә зур роль уйнаганнар. Әлеге уеннарда әби-бабаларыбызның эш-гамәлләре, һөнәри эшчәнлекләре чагылыш тапкан. Бу уеннарга карап халкыбызның күңел көзгесен күз алдына китерергә, уй-кичерешләрен белергә мөмкин. Халык уеннарының әһәмияте бүгенге көндә дә кимеми, киресенчә, вакытлар үтү белән арта гына бара. Шушы хакыйкатьне истә тотып, китапка халкыбызның балалар яратып уйный торган иң матур кагыйдәле хәрәкәтле уеннары кертелде. Шулай ук балалар бакчасының барлык төркемнәрендә дә уйнарга мөмкин булган җырлы-биюле уеннар бирелде. Бу уеннарны тәрбия һәм белем бирү эшендә дөрес файдалану тарихыбызны, халкыбызның борынгы гореф-гадәтләрен яхшырак белергә, балаларыбызның милли үзаңы формалашуга ярдәм итәр.

**«Әйдәгез, дуслар, җыелыйк!..»** дип исемләнгән **III бүлектә** дәрес-шөгыльләрдә, режим моментларында файдалану өчен физкульминутлар һәм хәрәкәтле уен вакытларында кулланырга мөмкин булган санамышлар тупланды.

*Физкульминутлар* төрле эшчәнлек вакытында нәниләргә кыска вакытлы ял итү мөмкинлеге бирә; ишетү, күрү органнарын, гәүдә мускулларын, кул чукларын ял иттерә. Аяк-кул, бармак, муен, гәүдә өчен хәрәкәтләрне эченә алган гимнастик күнегүләр күңелле, файдалы узсын өчен, аларны төрле җыр, такмаклар белән башкарырга мөмкин. Шигъри юллар белән яисә көй ярдәмендә (аудиоязма, бубен) үткәрелә торган ял минутларын балалар бигрәк тә ярата.

Татар халык иҗатының иң борынгы жанрларыннан берсе булган *санамышлар* йөгерешле, качышлы һәм башка күмәк уеннарда уенны алып баручыны, әйдәүчене сайларга мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта санамышлар

баланың зиһене, истә калдыру сәләте артуга да булышлык итә. Шуны истә тотып, китапта иң уңышлы дип тапкан санамышларны туплап бирергә булдык.

Уен – ул сәламәтлек чыганагы. Тән сәламәтлеге белән бергә, баланың рухи яктан дөрес формалашуы иң беренче чиратта уеннар һәм аларның дөрес оештырылуына бәйле. Шуңа күрә балалар бакчаларында да, гаиләдә дә уеннарны дөрес итеп оештыруга җитди игътибар итәргә кирәк. Уеннар никадәр кызыклырак итеп оештырылса, аларның файдасы шулкадәр зуррак. Балаларга алар яратмаган уенны көчләп тагарга ярамый. Өлкәннәр барлык төр уеннарны да җанлы, кызыклы, тәэсирле итеп оештыра белергә тиешләр.

«Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак» җыентыгы сабыйларыбызны рухи яктан бай, әхлаклы, физик яктан сәламәт итеп үстерүдә, буыннар арасындагы бәйләнешне саклау, туган телгә, милләтебезгә мәхәббәт тәрбияләүдә, янәшәдә яшәүче башка халыкларның гореф-гадәтләренә, йолаларына кызыксыну уятуда файдалы ярдәмлек булыр дип ышанасы килә.

*Автор*

# I БҮЛЕК

## Балачак – матур чагыбыз

Чү, әйдәгез, теләгәнчә
Без уйныйк, шау-гөр килик.
Балачак – матур чагыбыз,
Шатланыйк, куаныйк, көлик...

*С. Миңлекәй*

## БЕРЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ
(2 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен уеннар)

**Аю һәм балалар**

Балалар бүлмәнең бер башында урындыкларда утырып торалар.

Бер читтә «аю» утыра. Тәрбияче: «Балалар, көн кояшлы. Урамга уйнарга чыгыйк!» – дигәч, балалар, урыннарыннан торып, бүлмә буйлап йөгереп китәләр, сикерәләр, уйныйлар, бииләр. Тәрбияче: «Аю килә!» – диюгә, балалар урыннарына йөгерәләр. Аю аларны куа.

Уен шулай дәвам итә.

**Атта йөрибез**

Тәрбияче «ат» ролен башкара. Ул кыршау (обруч) алып, аны горизонталь рәвештә тота, 2-3 балага кыршау эченә керергә куша. «Атта йөрибез», – ди. Кыршау эченә кергәндә, һәр бала үз исемен әйтә. «Ат китте! На-на!!» дигән сигналга вак-вак атлап баралар, «Тр-рр, туктадык!» дигән сүзләрдән соң туктап калалар.

**Эт һәм үрдәкләр**

Тәрбияче – «эт», балалар – «үрдәкләр». Үрдәкләр алпан-тилпән килеп йөриләр, җим чүпләү хәрәкәтләре ясыйлар. Эт килеп чыга да алрны куркыта: «Һау-һау!» Үрдәкләр ояларына (урындыкларга) йөгерәләр. Эт аларны тотарга тырыша.

Уен шулай 2-3 тапкыр кабатлана.

**Куышу**

Бер бала урындыкта утырып тора. Калган балалар белән тәрбияче, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, әлеге бала янына киләләр:

Без күңелле, шат балалар,
Яратабыз уйнарга.
Без качабыз, син әйдә ку,
Тырыш куып тотарга.

Соңгы сүзләрдән соң балалар йөгереп китәләр, утырып торган бала аларны куа. Тотылган бала урындыкка утыра.

Уен шулай дәвам итә.

**Яңгыр, яу**

Тәрбияче балаларны уйнарга чакыра. Кулында матур зур кулчатыр (зонт).

Яңгыр, яу, яу, яу!
Бакчаларда алмагач
Үсми яңгыр яумагач.
Яңгыр яу, яу, яу!

Тәрбияче сөйләгән әлеге шигырь юлларын балалар да кабатлыйлар, сикерәләр, уйныйлар. Тәрбияченең «Яңгыр ява!» дигән сигналы буенча балалар тәрбияче янына йөгереп киләләр, кулчатыр астына керәләр, яңгырдан яшеренәләр.

**Бау аша сикер**

Балалар урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче идәнгә 3-4 м озынлыктагы төсле бау сала. Берничә бала (6-8) бау янына киләләр һәм тәрбияче сигналы буенча бау аша сикереп чыгалар.

Уенны идәнгә тагын бер бау салып катлауландырырга була. Балалар башта -беренче бау аша, аннары икенче бау аша сикереп чыгалар.

**Кояшкай**

Тәрбияче балаларны үз янына чакыра, сөйли:

Кояшкай, кояшкай!
Безгә син елмай.
Бик рәхәт син булганда,
Яратабыз уйнарга.

Балалар башта кулларын чәбәкләп торалар, «яратабыз уйнарга» дигән сүзләрдән соң бер урында сикерәләр.

**Матур уенчык**

Бүлмәнең (мәйданчыкның) бер башында 5-6 бала басып тора. Каршы якта, 2,5-3 м ара калдырып, 5-6 уенчык куела. Тәрбияче һәм балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Сикереп-сикереп барабыз,
Бер уенчык (матур флаг) табабыз.

Балалар флагларга таба ике аякларында сикереп баралар. Флагларны кулларына алып селкиләр, аннары үз урыннарына куеп, кире кайталар.

**Кошлар очалар**

Уен балаларны биек булмаган әйбер өстеннән сикереп төшәргә, таралып йөгерергә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү максатыннан уйнала.

Балалар 5-10 см биеклектәге берәр әйбергә (шакмак, такта һ.б.) менеп басалар. Бу әйберләр бүлмәнең бер башына балаларга җитәрлек санда, араларын ераграк итеп (балалар бер-берләренә комачауламаслык булсын) куела. Тәрбияче: «Күктә кояш көлә. Кошлар ояларыннан чыгалар, кояшлы көнгә сөенәләр, җим эзлиләр», – ди. Балалар такталардан сикереп төшәләр, кулларын як-якка җәеп, бүлмә буйлап йөгереп йөриләр, чүгәлиләр, идәнгә (яки тезләренә) бармаклары белән сугалар («җим чүплиләр»). Тәрбияченең «Яңгыр башланды. Кошлар ояларына очып кайттылар» дигән сигналы буенча, балалар үз урыннарына йөгерәләр.

*Уенга искәрмә*

* Уенны кабатлап уйнаганда сигналны кыскартып, «Кояш!» яисә «Яңгыр!» дип кенә бирергә мөмкин.

**Шалтыравыкка кадәр**

Балалар бүлмәнең бер башында урындыкларда утырып торалар. Алар каршына 3-4 м ара калдырып шалтыравык куела. Тәрбияче бер баланы үз янына чакыра һәм

шалтыравыкка таба мүкәләп барырга куша. Бала шалтыравык янына килеп җиткәч, аны ала, баса һәм баш өстенә күтәреп, шалтырата. Аннары шалтыравыкны урынына куя. Кире урынына килә.

**Югарырак үрмәлә**

Уен өчен гимнастика баскычы, өскәрәк беркетеп кую өчен, ачык төстәге матур уенчык кирәк.

Тәрбияче балаларга баскыч буйлап ничек үрмәләргә кирәклеген аңлата. Балалар бакскычка карап басалар. Тәрбияче ярдәме белән бер бала, баскычның һәр аратасына басып, өскә таба үрмәли. 5-6 нчы аратага кадәр менә, уенчыкны алып, тәрбияче ярдәме белән әкрен генә баскычтан төшә.

**Туп кемдә?**

Балалар түгәрәк ясап идәндәге паласка утыралар. Аяклары як-якка җәелгән. Тәрбияче уртада утыра. Ул, чиратлаштырып, балаларга таба тупны тәгәрәтеп җибәрә: «Туп кемгә таба тәгәрәде?» («Тупны кем тотты», «Туп кемдә?») – дип сорый. Тупны тотып алган бала үзенең исемен әйтә һәм тупны кире тәрбиячегә җибәрә.

**Тупны тәгәрәт**

Балаларга төрле төстәге кечкенә туплар (диаметры 6-8 см) бирелә. Тәрбияче балаларга тупларны урындыкта утырып торган курчак янына кадәр тәгәрәтеп барырга кирәклеген аңлата. Яхшы итеп тәгәрәтеп барган балаларны мактый, биремне үти алмаган балаларга булыша, берничә тапкыр тәгәрәтеп карарга мөмкинлек бирә. Барлык балалар да берничә тапкыр тәгәрәтеп уйнаганнан соң, тупларны кәрзингә тутыралар.

**Кем тизрәк?**

Уен өчен төрле төстәге туплар һәм шул төсләрдәге тартмалар кирәк була. Балалар бүлмәнең бер читенә тезелгән урындыкларда утыралар. Тәрбияче алар каршына туплар салынган төрле төстәге берничә тартма куя һәм уенның эчтәлеген аңлата. «Туплар тәгәрәп киткәч, сез аларны берәмләп китереп тартмага салырга тиеш: туп кызыл төстә булса – кызыл тартмага, яшел булса – яшел тартмага» һ.б.

Тәрбияче: «Бер, ике, өч, йөгер!» – ди һәм балалар йөгерергә тиешле якка тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Туплар тәгәриләр, балалар алар артыннан йөгерәләр. Һәрберсе берәр туп алып килеп, шул туп төсендәге тартмага салалар. Соңыннан туплар бергә кушыла, һәм уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Туплар саны балалар санына туры килергә тиеш.

• Балалар бары тик тәрбияче сигналыннан соң гына йөгерергә тиешләр.

• Йөгергәннән соң балаларга бераз утырып ял итәргә мөмкинлек бирергә, уенны кабатлауны ашыктырмаска кирәк.

**Төз ыргыт**

Балалар түгәрәккә басалар. Һәр балага кечкенә туп бирелә. Түгәрәк уртасына зур кәрзин куела (балалар белән кәрзин арасы 15-2 метрдан артмасын). Тәрбияче сигналы буенча балалар тупларын кәрзингә ыргыталар, аннары барысы бергә тупларын кәрзиннән барып алалар да үз урыннарына кире кайталар. Бала тубын кәрзингә кертә алмаган очракта, ул аны барып ала да калган балалар белән түгәрәккә баса.

**Машиналар**

Тәрбияче балаларга төрле төстәге боҗралар (серсо) өләшә. Болар – рульләр, балалар «машиналар» булалар. Алар, боҗраларны ике кул белән тотып, рульләрне уңга-сулга боргалап, зал буйлап йөриләр, туктап «шиннарын кабарталар»: аякларын тыпырдаталар. Аннары, тыпырдап бара-бара, юлларын дәвам итәләр. Тәрбияче «Светофор!» дип сигнал бирә. Әгәр тәрбиянеченең кулында кызыл түгәрәк булса, машиналар туктап калалар, яшел төскә тагын китеп баралар.

Уен 2-3 тапкыр кабатлана.

**Кайда шалтырый?**

Балалар стенага карап басалар. Шул арада тәрбияче ярдәмчесе кая да булса яшеренә. Кулында кыңгырау. Ул качкан урынында кыңгырауны шалтырата. Тәрбияче: «Балалар, әйтегез әле, кыңгырау кайда шалтырый?» – ди. Балалар кыңгырауны эзлиләр. Тапкач, тәрбияче аларны мактый һәм кабат стена янына барып басарга куша. Тәрбияче ярдәмчесе башка урынга яшеренә һәм кыңгырауны тагын шалтырата.

Уен шулай дәвам итә.

**Соңга калма!**

Уен ярдәмендә балалар бер-берләренә комачауламыйча, бәрелешмичә йөгерергә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнәләр.

Тәрбияче идәнгә, ярымтүгәрәк ясап, балалар санынча шакмаклар (шалтыравыклар, резина уенчыклар һ.б.) куя. Балалар уенчыклар янына килеп басалар. Тәрбияче сигналы буенча алар бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөгереп китәләр. «Соңга калма!» дигән сүзләрдән соң шакмаклар янына йөгереп киләләр.

**Кәҗә**

Бу уен балаларны бүлмәдә үз урыннарын истә калдырырга, табарга, күзәтүчән, игътибарлы булырга өйрәтә.

Балаларның урындыклары бүлмәнең кара-каршы якларына куела. Балалар урындыкларда утырып торалар. Бер читтәрәк тәрбияче басып тора – ул «кәҗә» ролен үти.

Уен башлану белән, күңелле көй астында, балалар бүлмә буйлап йөри башлыйлар. Берникадәр йөргәннән соң, тәрбияче җыр җырлый башлый:

Балаларны куып килә
Зур мөгезле бер кәҗә,

Сөт эчмәгән балаларны
Мөгезе белән ул сөзә.

Җырның соңгы сүзләрен әйтеп бетерүгә, кәҗә балаларны куа башлый, балалар, йөгерешеп, үз урыннарына качалар (урындыкларына барып утыралар).

**Инеш аша**

Тәрбияче җирдә ике сызык сыза (бүлмәдә уйнаганда бау яки сикергечтән файдаланырга мөмкин) – бу «инеш». Аннары сызыклар өстенә 2-3 м озынлыктагы (киңлеге 25-30 см) такта куела – бусы «күпер». Балалар күпер аша инешнең икенче ягына чыгарга тиешләр.

Тәрбияче такта буйлап кына барырга, күпердән егылып төшмәс өчен бик сак булырга кирәклеген, аякларны суга чылатырга ярамаганлыгын аңлата.

*Уенга искәрмә*

* Күпер аша йөгереп үтәргә дә мөмкин.

* Тактаны бераз биегрәк күтәртеп уенны катлауландырырга була.

**Сукмак буйлап**

Идәндә яки җирдә (асфальтта), бер-берсеннән 25-30 см ара калдырып, 2,5-3 м озынлыкта ике параллель сызык сызыла (сикергеч яки бау салырга мөмкин). Тәрбияче балаларга: «Хәзер без сукмак буйлап йөрербез», – ди. Сукмак буйлап сак кына, сызыкның кырыйларына басмыйча барырга кирәклеген аңлата.

Балалар, бер-бер артлы әкрен генә, ашыкмыйча шул сукмак буйлап (сукмактан чыкмыйча) йөрергә өйрәнәләр.

**Татар халык уеннары**

**Куянкай**

Уен башында балалар урындыкларда утырып торалар.

Мәйданчыкның бер ягында «куяннар»га урын билгеләнә. Балалар түгәрәкләнеп басалар. Тәрбияче тарафыннан билгеләнгән бер «куян» уртага баса. Балалар тәрбияче белән бергә шигырь әйтәләр һәм эчтәлегенә яраклаштырылган хәрәкәтләр ясыйлар:

Ак куянкай утырган,
Колакларын селкетә,
Менә шулай, менә шулай
Колакларын селкетә.

»Менә шулай» сүзләреннән соң балалар кулларын колаклары янына күтәрәләр дә, шигырь укылып беткәнче, аларны селкетеп торалар.

Куян туңа башлагач,
Аякларын җылыта,
Менә шулай, менә шулай
Аякларын җылыта.

«Менә шулай» дигән сүзләрдән башлап, шигырь беткәнче, балалар кул чабалар:

Куян һаман да туңа,
Сикергәләп тә куя.
Менә шулай, менә шулай
Сикергәләп тә куя.

Шигырьнең соңгы ике юлын әйткәндә, балалар бер урында ике аяклап сикереп торалар:

Кемдер аны өркетте,
Ул урманга элдертте.

Тәрбияче кул чаба, балалар йөгерешеп, үз урыннарына утыралар.

**Песи**

Балаларның урындыкларын тезеп, түгәрәк ясала. Балалар – «тычканнар» . Алар урындыкларның артларына качалар. Уртада , паласта, «песи» утыра.

Тәрбияче җырлый:
Мич башында ялкау песи
Мыр-мыр йоклый, берни белми.
Уяна да сузылгалый,
Битен юа, борылгалый.

Көн озын, төн килеп җитә,
Песи торып ауга китә.
Ауга китә, тычкан тота,
Куа-куа барып тота.

Тәрбияче җырлаганда, песи сузылгалый, битен юа. Җыр тәмамлануга, тычканнар, ояларыннан чыгып, төрле якка йөгерә башлыйлар. Песи берсен тота. Уен кабатлана.

## ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ

(3 яшьтән 4 яшькә кадәрге балалар өчен уеннар)

### Минем яныма йөгерегез

Балалар урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче бүлмәнең икенче башына балалар каршына барып баса. Ул: «Минем нәни дусларым, йөгерә-йөгерә килегез», – ди. Балалар, урыннарыннан торып, тәрбиячегә таба йөгерәләр. Тәрбияче аларны кулларын җәеп каршы ала, мактый. Аннары: «Өлгер, җитез балалар кире йөгереп баралар», – ди. Балалар, борылып, кире урыннарына йөгерәләр, урындыкларына утырып ял итәләр.

Уен кабатлана.

### Песи һәм тычканнар

Уенда берничә бала катнашырга мөмкин. Алар – «тычканнар» – «ояларында» (стена буена куелган урындыкларда) утырып торалар.

Бүлмәнең икенче башында «песи» басып тора. Песи ролен өлкәнрәк бала яки тәрбияче башкара (кулына уенчык песи тота яисә песи битлеге кия).

Песи йокыга киткәч, тычканнар бүлмә буйлап чабышып йөриләр. Ниһаять, песи уяна, мияулый-мияулый тычканнарны тотмакчы була. Тычканнар үз ояларына таба йөгерәләр һәм урындыкларга утыралар. Песи үз урынына кайтып тагын йокыга китә. Уен шулай дәвам итә.

### Маэмай

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Бер бала уртада чүгәләп утырып тора. Ул – «маэмай». Балалар түгәрәктә баскан килеш, тәрбияче белән бергәләп, түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...

*(Муса Җәлил)*

«Күп күрә» сүзләреннән соң «һау-һау» дип «маэмай» торып баса, балалар төрле якка йөгереп китәләр, «маэмай» аларны куа.

### Флагка таба йөгерегез

Уен ярдәмендә балалар игътибарлылыкка, төсләрне аера белергә һәм күрү сигналы буенча хәрәкәтләнергә өйрәнәләр.

Балаларның бер төркеменә – зәңгәр, икенче төркеменә кызыл төстәге флаглар бирелә.

Тәрбияче балаларга таралышырга тәкъдим итә. «Бер, ике, өч минем яныма тизрәк куч!»- ди дә флаглы кулларын як-якка җәя. Балалар үзләренең флаглары төсле флаг янына йөгереп киләләр.

**Төлке һәм тавыклар**

Бүлмәнең бер почмагы «тавык кетәклеге» итеп билгеләнә. Аның зурлыгы уенда катнашучылар санына бәйле. Каршы якта – «төлке оясы». Калган буш урын – «ишегалды». Бер бала – «төлке», калганнары «тавыклар» була. Алар ишегалдында йөгерешеп уйнап йөриләр, җим чүплиләр, канат кагыналар.

Тәрбияченең «Төлке!» дигән сигналы буенча тавыклар кетәклеккә йөгерәләр. Төлке куа, тотылган тавыкны оясына алып китә.

**Күңелле сыерчыклар**

Идәнгә кечкенә кыршаулар салына. Алар – «сыерчык оялары». Кыршауларның саны уйнаучы балалар саныннан бергә ким булырга тиеш. Күңелле көй яңгырый. Кошлар бүлмә буйлап очып йөриләр, музыка бетүгә, һәрберсе үз оясына кереп өлгерергә тырыша, бер бала оясыз кала.

Уен берничә тапкыр кабатлана. Соңгы тапкыр уйнаганда идәнгә тагын бер кыршау салырга кирәк (һәр балага җитәрлек булсын).

**Атлар**

Балалар, үзе теләгән бала белән парлашып, берсенең артына икенчесе басалар. Аларның алда торганы – «ат», икенчесе – «кучер» була. «Ат»ның муенына «йөгән» (төсле бау, сикергеч) кидерелә. Атлар бүлмә буйлап йөгереп китәләр, кучерлар дилбегәне тотып, аларны куалар. Бераздан тәрбияче балаларга рольләрне алмашырга куша.

**Такси**

Ике бала зур кыршау (диаметры 1 м) эченә – берсенең артына икенчесе – кереп басалар. Кулларын төшереп, кыршауны ике яктан тоталар. Алда басып торган бала – «такси йөртүче», икенчесе – «пассажир». Балалар бүлмә буйлап йөгереп йөриләр. Берникадәр вакыттан соң рольләрен алмашалар.

Балалар бер юнәлештә йөрергә өйрәнгәннән соң, юнәлешләрне үзгәртеп, тукталышлар ясап, уенны катлауландырырга мөмкин.

**Түгәрәктә**

Мәйданчыкта (залда) зур түгәрәк сызыла (диаметры 4 м тирәсе), аның эчендә диаметры 2 метрлы икенче түгәрәк сызыла. Балалар бер-бер артлы зур түгәрәкнең тышында йөриләр. Ике түгәрәк арасында тәрбияче йөри. «Тизрәк түгәрәккә!» дигән сигналга балалар, йөгереп, кечкенә түгәрәк эченә керергә тырышалар, тәрбияче аларны тотмакчы була. Тотылган балалар урыннарында тукталып калалар. Бераздан тагын зур түгәрәк тышына басалар.

**Инеш аша үтәбез**

Уенда 6-8 бала катнаша.

Мәйданчыкта, 1,5-2 м ара калдырып, ике сызык сызыла. Бу – «инеш». Сызыклар арасына, яхшы күренерлек итеп, кечкенә түгәрәкләр сызыла, алар – «ташлар».

Балалар сызык кырыена килеп басалар. Алар, ташларга баса-баса, аякларын чылатмыйча, инешнең икенче ягына үтәргә тиешләр. Түгәрәкләр арасы балалар берсеннән икенчесенә сикерә алырлык булырга тиеш.

Инеш аша берьюлы 2-3 бала үтә. Калган балалар аларны күзәтеп торалар. Аягын суга чылаткан бала кырыйга барып утыра, кояшта аякларын киптерә. Соңрак алар тагын уенга кушылалар.

**Күбәләкне тот**

Балалар, бер-берләре арасында җәелгән куллар кадәр ара калдырып, түгәрәккә басалар. Тәрбияче 1-1,5 м таяк тотып түгәрәкнең уртасында басып тора. Таякның очына бау белән кәгазьдән (яки паролоннан, чүпрәктән) эшләнгән «күбәләк» беркетелгән. Тәрбияче бауны уйнаучыларның баш өсләреннән йөртә – күбәләк оча. Балалар, күбәләкне куллары белән тотып алырга теләп, урыннарында сикергәлиләр. Күбәләкне тота алган бала: «Мин тоттым!» – ди. Тәрбияче аны мактый, таякны кабат әйләндерә.

Уенга күрсәтмәләр

• Сикергән вакытта балаларның түгәрәкне кечерәйтмәвенә игътибар итәргә кирәк (1-2 адым артка чигенсеннәр).

• Күбәләкле таякны әйләндергәндә, тәрбияче аны, балаларның буе җитәрлек итеп, бер төшерергә, бер югарырак күтәрергә тиеш.

**Песи һәм чыпчыклар**

Балалар бүлмәнең бер ягында 15-20 см биеклектәге эскәмияләрдә, зур шакмакларда (кубларда) басып торалар. Алар – түбәдәге (яки оядагы) «чыпчыклар». Бер бала «песи» итеп билгеләнә, ул читтәрәк утырып тора. Тәрбияче: «Чыпчыклар очып киттеләр», – ди. Чыпчыклар түбәдән (оядан) очып төшәләр һәм, канатларын як-якка җәеп, бүлмә буйлап очып, сикергәләп йөриләр. Песи бу вакытта йоклый. Кинәт песи уяна, «ми-яу!» дип, чыпчыкларны куа башлый. Чыпчыклар песидән түбәгә (ояга) менеп качалар (кире үз урыннарына кайталар). Тотылган чыпчыкларны песи үз өенә алып кайта.

**Түмгәктән түмгәккә**

Балалар залның бер ягында басып торалар. Тәрбияче идәнгә, бер-берләреннән 20 см ара калдырып, кыршаулар сала. Тәрбияче сигналы буенча, балалар, бер кыршаудан икенче кыршауга кереп, залның икенче ягына үтәләр.

Уенга күрсәтмәләр

* Балалар бер кыршаудан икенче кыршауга кереп йөрергә өйрәнгәч, кыршаулар аша йөгереп үтәргә тәкъдим ясарга мөмкин.

* Уен мәйданчыкта уйналганда, җиргә түгәрәкләр сызарга була.

**Тавык һәм чебиләр**

Уен ярдәмендә балалар үрмәләү күнегүләре алалар.

Уен алдыннан мәйданчыкның бер башында 40-50 см биеклектә бау тарттырыла (бау ике агач арасында яисә ике терәккә бәйләнеп куела). Бу – «тавык һәм чебиләрнең өе».

Уенда берничә бала катнаша. Алар – «чебиләр», тәрбияче – «тавык».

Тавык, бау аша үрмәләп чыгып, җим эзләргә китә. Берникадәр вакыт үткәч, ул: «Кыт-кытак, кыт-кытак», – дип чебиләрне үз янына чакыра. Аны ишетүгә, чебиләр бау астыннан үрмәләп чыгалар, әниләре янына йөгереп киләләр, бармаклары белән җиргә чиртеп, җим чүпләгән күк итәләр. «Тилгән килә!» дигән сигналга, чебиләр өйләренә йөгерәләр.

**Йорт куяннары**

Бүлмәнең бер башына, ярымтүгәрәк ясап, урындыклар куела (утыргычларын түгәрәк эченә каратып). Болар – «куяннарның читлекләре». Балалар – «куяннар». Каршы якта – «каравылчы өе». Бүлмә уртасында – «күлләвек». Тәрбияче сигналы буенча куяннар читлекләреннән – урындык астыннан шуышып чыгалар, ике аякта сикереп, күлләвектә уйныйлар. Тәрбияченең «Өйләрегезгә кайтыгыз!» дигән сүзләреннән соң куяннар, урындыклар астыннан кабат шуышып чыгып, читлекләренә кайталар, урындык артына чүгәләп утырылар.

**Туплар**

Балалар, түгәрәкләнеп, урындыкларда утырып торалар. Янәшә утырган ике балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер бала тупны – уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар тупларны бер-берләренә бирәләр). Ике туп очрашкач, туплы балалар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта: «Йөгердек, йөгердек», – дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшыралар. Ул аларны башка балаларга бирә.

Уен шулай дәвам итә.

**Кызыл, зәңгәр...**

Уен өчен ике кәрзин, уйнаучылар санынча кызыл һәм зәңгәр төстәге туплар кирәк. Кызыл туплар – бер кәрзингә, зәңгәр төстәгеләр икенче кәрзингә салына.

Балалар, бер-берләренә карап, ике рәткә тезелеп басалар. Зәңгәр туплар тәгәрәгәндә – беренче рәттәге балалар, ә кызыл туплар тәгәрәгәндә, икенче рәттәге балалар йөгерергә тиешлеге аңлатыла. Тәрбияче, чиратлаштырып, кәрзиннәрне аудара һәм тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Балалар туплар артыннан йөгерәләр, җыеп, кире кәрзингә салалар, үз урыннарына килеп басалар.

Уенны, ике кәрзинне дә берьюлы аударып, катлауландырырга мөмкин.

**Капкага керт**

Идәндә сызык сызыла. Сызыктан 2-3 адым ара калдырып, дуга куела. Бу – «капка». Тәрбияче бер балага идәндә яткан тупны алып, шул капкага кертергә куша. Бала, иелеп, идәндә яткан тупларның берсен ала һәм аны, капкага кертергә тырышып, тәгәрәтеп җибәрә. 3-4 тупны тәгәрәткәннән соң, уенны икенче бала дәвам итә.

Уенга күрсәтмәләр

* Тупны бер яисә ике кул белән тәгәрәтергә мөмкин.

* 2-3 дуга куеп, биремне берьюлы 2-3 бала башкара ала.

### Тот, ыргыт, төшермә

Балалар түгәрәк ясап басалар, тәрбияче уртада. Кулында зур туп. Ул тупны әле бер балага, әле икенче балага ыргыта: «Тот, ыргыт, төшермә», – ди. Балалар тупны тотып алырга, кире тәрбиячегә ыргытырга тиешләр. Аннары тәрбияче: «Минем яныма килегез, туплар кебек сикерегез», – ди. Балалар, аяк очларында сикерә-сикерә, тәрбияче янына киләләр. Тәрбияче тиз генә тупны өскә күтәрә һәм: «Качыгыз, туп сезнең арттан сикерә», – ди. Балалар йөгереп китәләр. Тәрбияче тупны идәнгә бәреп ала, балалар туктыйлар.

Уен шулай дәвам итә.

### Чыпчыклар һәм автомобиль

Уен ярдәмендә балалар төрле юнәлештә йөгерергә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнәләр, сикерү күнекмәләре алалар.

Уен өчен алдан картоннан руль ясала (яисә теләсә нинди түгәрәк формалы әйбер файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, тәлинкә, поднос, серсо боҗрасы һ.б.). Балаларның башларына чыпчык битлекләре кидертелә.

Бүлмәнең бер башына урындыклар куела. Ул – кошчыкларның «өйләре». Ә икенче башында «гараж» өчен урын билгеләнә.

«Минем кулымда руль. Мин автомобиль булам, ә сез – нәни кошчыклар. Шушы матур аланда очып, сикергәләп йөрерсез», – дип, тәрбияче уенны аңлата.

«Чыпчыклар ояларыннан чыкты» дигән сүзләрдән соң балалар, кулларын җәеп, бүлмә буйлап кош кебек «очып» йөриләр.

Гараждан автомобиль чыга: «Би-бип! Би-бип! Автомобиль килә. Сак булыгыз!» – ди. Чыпчыклар куркалар һәм үз ояларына очалар. Автомобиль дә гаражга әйләнеп кайта.

Уенны бер тапкыр уйнаганнан соң, автомобиль ролен балалар башкара.

### Трамвай

Балалар, җитәкләшеп, бер-бер артлы басалар. Очлары бәйләнгән озын бауны икенче куллары белән тотып, бау эчендә калалар. Тәрбияче бүлмәнең бер почмагында кулына өч флагчык (сары, кызыл, яшел) тотып басып тора. Яшел флагчыкны күтәргәндә, балалар йөгерә башлыйлар: трамвай кузгала. Сары флагчык күтәрелгәч акрынаялар. Кызыл флагчыкка туктыйлар һәм яшел флагчык күтәрелгәнен көтеп торалар.

### Үз төсеңне тап

Уен ярдәмендә балалар төрле юнәлештә йөрергә, йөгерергә, бер урынга җыелырга, төсләрне танырга өйрәнәләр.

Балаларга 3-4 төстәге флаглар таратыла. Кайберләренә – яшел, икенчеләренә кызыл (сары, зәңгәр) флаглар туры килә. Яшел флаг тоткан балалар – бүлмәнең бер почмагына, кызыл флаглылары икенче почмакка барып басалар. Әлеге почмакларга балалардагы флаглар төсендәге флаглар куела.

Тәрбияченең «Әйдәгез, уйнап алыйк!» дигән сүзләреннән соң балалар бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөри башлыйлар (төркем булып та, берәмләп тә йөрергә мөмкин).

«Өйләрегезгә кайтыгыз!» дигән сүзләрдән соң балалар кулларындагы флаг төсендәге флаг янына җыелалар.

Бу уенны катлауландырып (мәсәлән, уен барышында почмаклардагы флагларның урыннарын алыштырып һ.б.) уртанчылар һәм зурлар төркемнәрендә дә уйнарга мөмкин.

**Үз өеңне тап**

Балалар бүлмәнең бер башында урындыкларда утырып торалар. Урындыклар – аларның «өйләре». Тәрбияченең «Без уйнарга яратабыз, әйдәгез, уйнап алабыз» дигән сүзләреннән соң балалар, урыннарыннан торып, бүлмә буйлап йөриләр (кем кайда тели). «Өйләрегезгә кайтыгыз!» дигән сигналдан соң, балалар үз өйләренә (урындыкларга) таба йөгерәләр.

Уен 3-4 тапкыр кабатлана.

*Уенга күрсәтмә*

* Баштарак балаларга теләсә кайсы урындыкка утырырга рөхсәт итәргә мөмкин. Соңрак һәр бала үз урындыгына гына утырырга тиеш.

**Уенчыкны сакла**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Һәр баланың аяк очына шакмак яисә шалтыравык (зур булмаган башка уенчык) куела. Тәрбияче түгәрәк эчендә басып тора. Ул әле бер, әле икенче баланың уенчыгын алмакчы була. Уйнаучы бала, тәрбияче аңа таба якынлашканда, тиз генә чүгәләп, куллары белән уенчыкны каплый, тәрбиячедән аны саклый. Тәрбияче башка бала ягына киткәч, уенчыкны идәндә калдырып, торып баса.

**Куык**

Уен башлаганда балалар урындыкларга утырып торалар. Тәрбияче (уенны алып баручы) бер бала янына килә, йомшак тавыш белән аның исемен сорый. Әлеге бала үз исемен әйткәннән соң, уенны алып баручы аны уйнарга чакыра һәм, баланы җитәкләп, икенче бала янына килә. Аның да исеме сорала. Җавап алынганнан соң, алар җитәкләшеп өченче бала янына киләләр. Шулай итеп, уенда катнашучы һәр баланың исеме сорала. Балалар түгәрәк ясап басалар. «Безнең түгәрәк куыкка охшаган», – ди тәрбияче. – «Әйдәгез, түгәрәкне зурайтабыз». Балалар, түбәндәге сүзләрне әйтеп, артка таба әкрен генә чигенәләр (куыкны зурайталар):

Өрел, куык, зур булып,
Тик шартлый күрмә тулып;
Һаман да син бул матур –
Күпереп, кабарып тор!

Зур түгәрәк барлыкка килә. Балалар, тиз генә кулларын ычкындырып, кул чабалар. Кинәт тәрбияче: «Куык шартлады!» – ди. Балалар барсы бергә: «Шалт!» – дип әйтеп, җиргә чүгәлиләр.

Тәрбияче яңа куык өреп кабартырга тәкъдим итә. Балалар, тураеп басып, кабат тыгыз түгәрәккә тезеләләр. Уен яңадан кабатлана. Аны 3-4 тапкыр кабатларга мөмкин.

**Уенның II варианты.**

«Купереп, кабарып тор!» дигән сүзләрдән соң, тәрбияче: «Куыклар очып киттеләр», – ди. Балалар, очу хәрәкәтләре ясап, төрлесе-төрле якка таралалар.

Бу уен ярдәмендә балалар түгәрәккә тезелергә, чүгәләргә, уенның II вариантында төрле юнәлештә йөгерергә өйрәнәләр. Уен балаларның сөйләм телен үстерергә дә ярдәм итә.

### Кошчыклар

Тәрбияче балаларны уйнарга чакыра. «Мин – «әни кош», ә сез – «бәби кошлар» буласыз», – дип, уенны аңлата. Идәнгә зур түгәрәк сызыла. Бу – « бәби кошлар оясы». Балалар түгәрәк эченә керәләр, чүгәләп утыралар. Тәрбиячененң «Җим эзләргә кирәк, очыйк тизрәк» дигән сүзләреннән соң балалар түгәрәк эченнән сикереп чыгалар һәм, кулларын як-якка җәеп, бүлмә буйлап кошлар кебек очып йөриләр. Әни кош та балалар арасында. «Җимнәр таптык, өйгә кайтыйк» дигән сүзләрдән соң кошлар өйләренә (түгәрәккә) очып кайталар.

Уен берничә тапкыр кабатлана.

### Флагны тап

Берничә бала (6-8) урындыкларда (яисә чирәмдә) утырып торалар. Тәрбияче сигналы буенча алар күзләрен йомалар, ә тәрбияче шул вакытта төрле урыннарга балалар санынча флаглар яшерә.

«Әйдәгез, флаглар эзлибез», – ди тәрбияче. Балалар күзләрен ачалар һәм флагларны эзли башлыйлар. Флаг тапкан бала үз урындыгына килеп утыра. Барлык балалар да флагларны табып бетергәч, алар бер-бер артлы тезелеп басалар. Иң алга флагны беренче булып тапкан бала баса. «Урыннарга утырдык!» дигән сигналга, балалар урындыкларга утыралар һәм уен кабатлана.

## ХАЛЫК УЕННАРЫ

### Күз бәйләш

*(Татар халык уены)*

Тәрбияче балаларга үзләре кая теләсәләр, шунда барып басарга куша. Үзе күзләрен йома яисә яулык белән бәйли. Күзләре каплаулы килеш балаларны тотмакчы була, бүлмә буйлап бик сак кына бара. Балалар булмаган урында аларны тоткан булып кылана. Балалар сөенәләр, көлешәләр. «Кайда соң безнең нәниләр?» – дип, тәрбияче күзләрен ача. «Менә кайда икән алар!» диюгә, балалар тәрбияче янына йөгереп киләләр, тәрбияче аларны кочаклап ала.

**Коймак**

*(Татар халык уены)*

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала уртада басып тора.

Беренче куплетта балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр.

Икенче куплетның беренче һәм икенче юлларын җырлаганда балалар, кулларын ычкындырып, өскә күтәрәләр; өченче юлында – як-якка җәяләр; дүртенче юлда ике кул тоташа.

Өченче куплетта балалар кул чабып торалар, ә уртадагы бала түгәрәктән бер баланы сайлап ала. Алар, кулларын тотышып, кара-каршы басалар һәм әйләнәләр.

Булатның туган көненә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.

Коймакларга карасаң,
Менә шулай кабарган.
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнең сайлап ал.

**Аю урманында**

*(Рус халык уены)*

Мәйданчыкның (бүлмәнең) бер башына сызык сызыла. Бу – «урман чите» була. Шунда аю яши торган урын билгеләнә. Мәйданчыкның каршы ягында – «балалар өе».

Уйнаучылар арасыннан берсе «аю» итеп сайлана. Ул үз өнендә утыра. Барлык башка балалар гөмбә, җиләк җыйган булып кыланып, әкрен генә аю янына баралар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Аю бабай урманында
Җиләк, гөмбәләр җыям,
Аю бабай күрмәсен,
Без йөргәнне сизмәсен!

Әлегә кадәр йокымсыраган кыяфәттә утырган аю бу сүзләрдән соң кыймылдый, киерелә башлый һәм өненнән (түгәрәктән) чыга. Балалар төрле якка йөгерешәләр, аю аларны куа. Тотылган бала аю ролен үти.

## УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ

(4 яшьтән 5 яшькә кадәрге балалар өчен уеннар)

**Ябалак**

Бу уен ярдәмендә балаларда игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Нәниләр бер-берләренә комачауламыйча йөрергә, йөгерергә өйрәнәләр.

Бүлмәнең бер башына эскәмия яисә урындыклар куела. Бу – кошлар кунаклау өчен «оялар». Бер бала «ябалак» итеп билгеләнә, аның башына ябалак битлеге кидертелә. Калган балалар – «кошлар». Ябалак башка балалардан биегрәк урынга – «агач башына» (зур куб һ.б.) утыра. Балалар, кулларын селки-селки, бүлмә буйлап кошлар очкан кебек итеп йөриләр. Шулчак уенны оештыручы ябалак янына килеп сөйли:

Ябалак, ябалаккай,
Ни уйлап утырасың?
Күзләрең дә йомык бит,
Әллә очарга җыенасың?

Шушы сүзләрдән соң ябалак урыныннан идәнгә очып төшә һәм балаларны куа башлый. Кошлар ябалактан качалар: урыннарына очып китәләр. Ябалак оясына кайта. Ул үзе белән качып өлгерә алмаган кошны алып кайтырга мөмкин. Ябалак кабат ауга чыкканда, әлеге кош очып китә ала.

Бер бала ябалак ролен ике тапкыр башкарганнан соң, уенны оештыручы ябалак итеп башка баланы билгели.

**Төсле автомобильләр**

Уен ярдәмендә нәниләр төсләрне аерырга, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнәләр, йөрү һәм йөгерү күнекмәләре алалар.

Балалар бүлмәнең бер башына тезеп куелган урындыкларга утыралар. Урындыклар – «гараж», ә балалар – «автомобильләр». Уйнаучының һәрберсенә кызыл, сары, зәңгәр, (яисә яшел, ак, кара) төстәге боҗралар бирелә.

Уенны оештыручы, балаларга карап, бүлмә уртасына баса. Аның кулында төрле төстәге өч флаг. Уенны алып баручы флагларның берсен югары күтәрә. Кулларында алып баручыдагы флаг төсле боҗра тоткан балалар, машиналар кебек гүелди-гүелди, бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөгереп китәләр. Алып баручы кулындагы флагны түбән төшергәч, балалар туктыйлар һәм гаражларына юнәләләр. Алып баручы икенче төстәге флагны күтәрә, уен яңадан башлана.

Уенны оештыручы берьюлы ике яисә өч төстәге флагларны күтәрергә мөмкин. Флагларның өчесе дә күтәрелгәндә, барлык балалар да гаражларыннан чыгалар.

Уен 5-6 минут дәвам итә.

**Очкычлар (самолетлар)**

Уен ярдәмендә балаларның тирәлектә үз урыннарын таба белү сәләтләре үсә, игътибарлылыклары арта, алар йөгерергә өйрәнәләр.

Уенны бигрәк тә малайлар яратып уйный.

Уенда катнашучыларның санына карап, аларны 2-3 төркемгә бүләргә мөмкин. Һәр төркем өчен флаглар ярдәмендә урыннар – «аэродром» билгеләнә. Уйнаучылар очкычлардагы очучылар булып кыланалар. Уенны оештыручының «Очарга әзерлән!» дигән сигналы буенча балалар, моторларны кабызган сыман, кулларын терсәктән бөгеп, әйләндереп торалар. «Очыгыз!» дигән сигналга нәниләр, кулларын як-якка җәеп, төрлесе-төрле якка йөгереп китәләр. «Җиргә төшәргә!» дигән сигнал буенча, очкычлар үз урыннарын табалар һәм җиргә төшәләр: сыңар аякларына тезләнеп басалар.

Уенны оештыручы кайсы төркемнең тизрәк җыелуын күзәтеп тора.

**Кыңгырау**

Балалар, түгәрәк ясап, идәнгә тезләнәләр. Бер бала, матур көй астында кыңгырауны шалтыратып, түгәрәк буйлап йөри. Көй туктаганда, кыңгырауны бер баланың артына идәнгә куя. Барлык балалар да борылып карыйлар. Артына кыңгырау куелган бала йөгереп китә. Каршы якка кыңгырау куючы бала йөгерә. Кем беренче килеп җитә, шул, кыңгырауны алып, уенны дәвам итә.

**Сиздермичә йөгереп үт**

Балалар бишәр, алтышар булып берничә төркемгә бүленәләр. Алар бүлмәнең бер башында басып торалар. Өлкәнрәк балалардан берәү уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул бүлмәнең уртасына урнаша һәм күзләрен йома. Тәрбияченең сигналы буенча бер төркем балалар, алып баручы кырыеннан сиздерми генә үтеп, бүлмәнең икенче башына таба йөгерәләр. Аларның аяк тавышлары ишетелмәскә тиеш. Әгәр дә алып баручы тавыш ишетсә: «Туктагыз!» – ди. Йөгереп баручылар туктап калалар. Алып баручы, күзен ачмыйча, тавыш ишетелгән якка күрсәтә. Әгәр ул дөрес әйтсә, йөгерүче балалар читкә барып басалар, әгәр дә дөрес әйтмәсә, йөгерүчеләр кире үз урыннарына баралар, һәм уен дәвам итә. Шулай итеп һәр төркем йөгереп үтә.

Алып баручы яныннан сиздермичә үтә алган төркем җиңүче була.

**Беренче булып бас**

Балалар бер-бер артлы тезелеп басалар. Тәрбиячене҇ сигналы буенча, йөгереп китәләр, йөгерү барышында тәрбияче бер баланы исеме белән атый. Исеме әйтелгән бала колоннадан чыга һәм, йөгереп, колоннаның башына барып баса.

Уен шулай дәвам итә.

**Шалтыравык**

Бүлмәнең бер башында сызык сызыла. Аның артына 5-6 бала баса. Каршы якта эскәмиягә (яисә урындыкларга), бер-берләреннән 30-40 см ара калдырып, шалтыравыклар куела. Тәрбиячене҇ «Бер» ике, өч! Йөгерергә кирәк көч!» дигән сигналыннан соң балалар каршы якка таба йөгерәләр һәм, йөгереп килеп, шалтыравыкны алалар, баш өстенә күтәреп аны шалтыраталар. Иң беренче булып йөгереп килгән бала җиңүче була.

### Песи һәм тычкан

Уенчылар, кулга-кул тотынып, түгәрәк ясыйлар. Бер баланы – «тычкан», икенчесен «песи» итеп билгелиләр. Тычкан песине куа башлый. Балалар тычканны песидән сакларга, түгәрәк эченә кертмәскә тиешләр. Һәм, киресенчә, тычкан песидән түгәрәк эченә качып котыла ала.

Уен песи тычканны тотканчыга кадәр дәвам итә.

### Песи һәм кошчыклар

Җиргә диаметры 6-7 адым булган түгәрәк сызыла яки ике очы тотыштырып бәйләнгән бау (шнур) салына. Бер бала түгәрәк уртасына баса. Ул «песи» була. Калган балалар – «кошчыклар» – түгәрәк читендә торалар.

Песи йоклый. Кошчыклар җим эзләп түгәрәк эченә очып керәләр. Песи уяна да кошчыкларны күреп куарга тотына. Кошчыклар түгәрәктән очып чыгарга ашыгалар. Әгәр дә песи кошчыкларның берсен түгәрәк эчендә әбәкләсә (кулы белән кагылса, тотса), бу кошчык тотылган булып санала һәм түгәрәк уртасында кала. Бер песи 2-3 кошчыкны тотканнан соң, башка песи билгеләнә. Тотылган кошчыклар үз иптәшләренә кушылалар.

Уен 4-5 тапкыр кабатлана.

### Соры бүре

Уйнаучылардан берсе «бүре» итеп билгеләнә. Ул өнендә (мәйданчыкта сызып билгеләнгән урында) утыра. Калган балалар «кәҗә бәтиләре» булалар. Алар көтүдә (болында) үлән ашап йөриләр, сикерәләр, уйныйлар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Тәмле үлән ашыйбыз,
Бүреләрдән качмыйбыз,
Ашап туйгач, чабышып
Тагын өйгә кайтырбыз.

Соңгы сүзне әйткәннән соң, бүре, өненнән чыгып, кәҗә бәтиләрен куа башлый. Ике кәҗә бәтие тотылганнан соң, яңа бүре сайлана, һәм уен янадан башлана.

### Тавык кетәклегендә төлке

Мәйданчыкның (залның) бер башы «тавык кетәклеге» итеп билгеләнә. Кетәклеккә «кунача» (эскәмия) куела. Балалар – «тавыклар» – куначага менеп басалар. Каршы якта – «төлке өне».

Бер бала «төлке» итеп билгеләнә. Ул каршы якка барып утыра.

Тәрбияченең сигналы буенча, тавыклар куначадан сикереп төшәләр һәм бүлмә буйлап йөгереп йөриләр, җим чүплиләр, канатларын кагыналар. «Төлке килә!» дигән сигналны ишетүгә, тавыклар кетәклеккә таба йөгерәләр һәм куначага менәләр, ә төлке аларны тотарга тырыша. Тотылган тавыкны үз өненә алып китә.

Уен кабатлана.

**Куяннар**

Бер бала «эт» итеп билгеләнә. Ул яшелчә бакчасын саклый. Калган балалар – «куяннар». Алар, ике аякта сикерә-сикерә, яшелчә бакчасында йөриләр, түтәлләр аша сикереп чыгалар. «Эт килә!» дигән сигналны ишетүгә, куяннар үз өйләренә (алдан сызылган түгәрәкләргә) йөгерәләр. Эт аларны куа. Тотылган куянны үзе белән алып китә.

**Хәйләкәр төлке**

Уен балаларда җитезлек, өлгерлек, игътибарлылык тәрбияли, балалар тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләре алалар.

Алдан бүлмәнең төрле урыннарына урындыклар, эскәмияләр, зур шакмаклар куела. Уен өчен гимнастика баскычларын да кулланырга була.

Балалар, бер-берләренә якын ук басып, түгәрәк ясыйлар, кулларын артка ашерәләр. Бер бала түгәрәкнең тышында кала, аңа уенчык төлке бирәләр. Ул түгәрәк буйлап йөгереп китә һәм, башкаларга сиздерми генә, төлкене бер баланың кулында калдыра. Үзе уртага баса һәм, барлык балалар белән бергә: «Хәйләкәр төлке, син кайда?» – дип кычкыра. Төлке башта дәшми. Балалар өч тапкыр кычкырганнан соң гына, төлке: «Менә мин!» – дип, уртага сикереп керә. Балалар як-якка йөгерешеп китәләр, эскәмия, урындык, зур шакмакларга сикереп менәләр. Кем менәргә өлгерми, ул төлке янында уртада кала. Калган балалар яңа түгәрәк ясыйлар. Уенчык башка балага бирелә.

Уен шулай дәвам итә.

**Инеш аша сикереп чык**

Мәйданчыкта озын параллель сызыклар – «инеш» сызыла. Аның бер башы тар һәм ул киңәя бара (10 см дан 40 см га кадәр).

Бер төркем балалар инешнең башта – тар өлешеннән, аннары – киңрәк, соңыннан иң киң урыныннан сикереп чыгалар.

Тәрбияче инешнең иң киң урыныннан сикереп чыга алган балаларны билгели.

**Курыкмыйм**

Балалар түгәрәк ясап басып торалар. Бер бала «әбәкләүче» итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасына баса. Балалар: «Курыкмыйм! Курыкмыйм!» – дия-дия, бер урында ике аякта сикерәләр. Бу вакытта алар кулларын әле як-якка җәяләр, әле артларына ашерәләр. Әбәкләүче, балалар кулларын як-якка җәйгәндә, аларны әбәкләп өлгерергә (кулы белән кагылырга) тырыша. Әбәкләнгән бала уеннан чыгарыла.

**Көтүче**

Уйнаучылардан берәү «көтүче» итеп билгеләнә. Аңа көтүче башлыгы кидерелә, чыбыркы һәм быргы бирелә. Балалар «сыерлар», «бозаулар» (яки башка терлекләр) була. Тәрбияче түбәндәге шигырь юлларын сөйли (бу вакытта көтүче быргыда уйнаган хәрәкәтләр ясый):

Көтүче алды
Кулына быргысын:
– Ту-ру-ру, ту-ру-ру!
Аның каршына
Чыкты бер сыер:
– Му-му-му! Му-му-му!

Соңгы сүзләрдән соң барлык терлекләр, дүрт аякта мүкәләп, әкрен генә көтүче янына җыелалар. Көтүче аларны болынга (бүлмәнең икенче башына) куа. Уен икенче көтүче сайлаганнан соң кабатлана.

**Песи балалары һәм көчекләр**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр. Бер төркем балалар – «көчекләр», ә икенчеләре – «песи балалары». Песи балалары гимнастика баскычы янына басалар, ә көчекләр бүлмәнең икенче башындагы «эт оясы»на (скамейкалар артына) урнашалар. Тәрбияче сигналы буенча, песи балалары әкрен генә, ашыкмыйча бүлмә буйлап йөгереп йөриләр. «Көчекләр!» дигән сигналны ишетүгә, икенче төркем балалары – көчекләр скамейкалар аша үрмәләп чыгалар. Алар песи балалары артыннан: «Һау-һау!» – дип өрә-өрә, мүкәләп йөгерәләр. Песи балалары: «Ми-яу, ми-яу» – дия-дия, гимнастика баскычына таба йөгерәләр һәм тиз генә баскычка үрмәләп меңәләр (тәрбияче бу вакытта баскыч янында басып тора). Көчекләр үз өйләренә кайтып китәләр. 2-3 тапкыр уйнаганнан соң, балалар рольләрен алмашалар, һәм уен дәвам итә.

**Кошлар оча**

Балалар залда берничә араталы гимнастика баскычы янында басып торалар. Бу – «агачлар». Балалар – «кошлар». «Кошлар очалар» сигналын ишетүгә, алар , кулларын як-якка җәеп, бүлмә буйлап йөгереп йөриләр. «Давыл!» дигән сигнал булуга, баскыч янына йөгереп киләләр һәм аның буенча үрмәләп өскә менәләр. «Давыл тынды!» диюгә, кошлар агачлардан ашыкмый гына төшәләр һәм очуларын дәвам итәләр.

Гимнастика баскычында араталар аз булганда, уен төркемнәргә бүленеп уйнала.

**Ыргыт һәм тотып ал**

Уйнаучылар парлашып басалар. Һәр парга бер туп бирелә. Пардагы бер бала тупны өскә ыргыта һәм аны, җиргә төшермичә, ике кулы белән тотып алырга тырыша. Икенче бала иптәшенең җиргә төшермичә тоткан туплар санын билгеләп тора. Тәрбияче сигналы буенча, балалар рольләрен алмашалар.

**Ераккарак ыргыт**

Берничә бала, туплар алып, алдан ук җиргә сызылган сызык кырыена басалар. Тәрбияче балаларга тупларны булдыра алган кадәр ераккарак ыргытырга тырышырга кирәклеген аңлата. Уен зур туплар белән уйналганда, балалар аларны ике кул белән тотып, күкрәк турысыннан яисә баш артыннан ыргыталар. Кечкенә тупларны, чиратлаштырып, уң һәм сул кул белән ыргытырга тәкъдим ителә. Тәрбияче иң еракка ыргытучы баланы билгели.

**Боҗралар**

Уен өчен серсо боҗралары һәм кызыклы фигуралар (мәсәлән, хортумын өскә күтәреп торган фил, муенын сузган каз, алгы тәпиләрен күтәргән озын колаклы куян һ.б.) кирәк булачак.

Фигурадан 1,5-2 м ара калдырып сызык сызыла. Балалар сызык кырыена басалар. Аларның максаты – боҗраларның фигурага кидертү.

Тәрбияче алдан балаларга ничек итеп сызыкның кырыена басарга, боҗраны горизонталь хәлдә тотарга һәр ыргытырга кирәклеген аңлата. Боҗраны горизонталь тотып ыргыту – бала өчен авыррак эш, шуңа да тәрбияче башта баланың боҗралы кулын тотып, үзе ыргытып күрсәтергә тиеш.

**Төз ыргыт**

Идәнгә зур кыршау салына яисә түгәрәк (диаметры 1-1.5 м) сызыла (баудан ясарга да була). Балалар, кыршаудан 2-3 адым ара калдырып, түгәрәк буенча басалар. Аларның кулларында ком тутырылган янчыклар. Тәрбияче сигналы буенча алар янчыкларны кыршау эченә ыргыталар (башта – уң, аннары сул куллары белән). Аннары барысы бергә янчыкларны барып алалар һәм түгәрәк кырыена кабат басалар.

Уен кабатлана.

**Кем ераграк ыргыта?**

Балалар бүлмәнең бер башында (яисә мәйданчыкта) билгеләнгән сызык артына барып басалар. Кулларында комлы (авырлыгы 150 гр.) янчыклар. Тәрбияче сигналы буенча алар янчыкларны ыргыталар. Һәр бала үз янчыгы кая төшкәнен күрергә тиеш. Тәрбияче әйткәч, алар үз янчыклары янына барып басалар, ике кул белән алып, янчыкларны баш өстенә күтәрәләр. Тәрбияче ераграк ыргыткан балаларны билгели, мактый. Аннары балалар яңадан сызык артына басалар.

**Үз төсеңне тап**

Уенны ел башында икенче кечкенәләр төркемендәге кебек уйнарга мөмкин. Уен кагыйдәләрен яхшылап өйрәнеп беткәч, тәрбияче балаларга бүлмә буйлап йөргәндә туктарга һәм күзләрен йомарга куша. Үзе шул вакытта флагларның урыннарын алыштыра. «Өйләрегезгә кайтыгыз!» дигән сигналга балалар күзләрен ачалар, кирәкле төстәге флагны табып, шунда таба йөгерәләр. Тәрбияче иң беренче булып җыелып беткән төркемне билгели.

**Сыерчык оялары**

Идәндә (мәйданчыкта), уйнаучылар саныннан бергә ким итеп, кечкенә түгәрәкләр сызыла. Бу – «сыерчык оялары».

Балалар – «сыерчыклар». Алар бүлмә буйлап иректә рәвештә йөгереп (очып) йөриләр. «Ояларыгызга!» дигән сигналны ишетүгә, балалар берәр түгәрәк эченә кереп өлгерергә тырышалар. Уен берничә тапкыр кабатлана.

Уенны соңгы тапкыр уйнаганда, тәрбияче, балалар йөгереп йөргәндә сиздерми генә, тагын бер түгәрәк сыза – оялар барлык балаларга да җитә, алар сөенәләр.

### Көн-төн

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртага берәү чыга. Ул – «ябалак», түгәрәктәгеләр «кошлар» булалар.

Ябалак «төн» дип кычкырса, кошлар куллар белән кош очкандагы хәрәкәтләр ясыйлар. Ә «көн» дисә, барысы да катып калалар. Әгәр шул вакыт берәрсе селкенсә, ул уеннан чыгарыла.

Уен, шул рәвешчә, түгәрәктә бер генә кош калганчы уйнала. Ул җиңүче була.

### Үзеңә пар тап

Уен өчен уйнаучылар санынча флаглар кирәк. Аларның яртысы – бер төстә, яртысы – икенче төстә булырга тиеш. Һәр балага бер флаг бирелә. Тәрбияче сигналы буенча (мәсәлән, бубенга сугу һ.б.), балалар бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөгереп китәләр. Икенче сигналга (мәсәлән, «кайтыгыз» сүзенә) бер төстәге флаглы балалар парлашып басалар.

Уенда катнашучы балалар саны так булырга тиеш. Бер бала парсыз кала. Балалар аңа: «Фәрит (Алсу), аптырап калма. Үзеңә иптәш сайла», – диләр. Шушы сүзләрдән соң тәрбияче тагын сигнал бирә һәм уен кабатлана.

### Көтүче һәм атлар

Балалар «атлар» итеп билгеләнәләр, тәрбияче – «көтүче». Ул, курай уйнаган хәрәкәтләр ясый-ясый, түбәндәге шигырь юлларын сөйли:

Курай уйныйм: та-ра-ра!
Атлар кай якка таба бара?
Атлар бара болынга
Яшел чирәм ашарга.

Бу вакытта балалар бер аякларын алга, икенчесен артка куеп, атлар кебек сикергәләп, мәйданчык буйлап йөриләр. Курай уйнаудан туктагач, атлар да туктап калалар, башларын селкеп торалар. Тәрбияче кабат курайда уйный.

Уен кабатлана.

### Бүләкләр

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясап басалар. Бер баланы уртага бастыралар. Калганнары, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, түгәрәк буйлап йөриләр:

Алып килдек бүләкләр –
Курчак, очкыч һәм атлар.
Аю, куян – бар да бар,
Теләгәнеңне сайлап ал!

Шигырь ахырында балалар туктап калалар, ә уртадагы бала уенчыкларның берсен аласы килүен әйтә. Әгәр дә ул ат кирәк дисә, балалар атлар кебек сикергәләп, хәрәкәтләр ясыйлар: кулларын алга сузып, аякларын югары күтәреп, бер-бер артлы түгәрәк буйлап йөриләр; әгәр дә курчак дисә, бию көенә парлашып бииләр; аю сүзенә, алпан-тилпән килеп, авыр басып йөриләр, куян сүзенә бер урында ике аякта сикерәләр һ.б.

Уртага икенче бала баса, уен дәвам итә.

**Үз чиләгеңне тап**

Тәрбияче балаларны өч төркемгә бүлә. Беренче төркемгә – яшел, икенче төркемгә – кызыл, өченче төркемгә сары яфраклар (картоннан ясалган) өләшә. Бүлмәдә, бер-берсеннән ераклаштырып, өч урынга кызыл, сары, яшел чиләкләр куя. Музыка астында (дәртле, җиңелчә көй) балалар яфраклар белән уйныйлар, бииләр. Музыка туктагач, яфракларын кулларындагы яфраклар төсендәге чиләкләргә салалар.

Уенны икенче кабат уйнаганда чиләкләрнең урыннарын алыштырып куярга була (музыка уйнаганда). Тәрбияче балаларның яфракларны ничек салуларын күзәтә. Дөрес чиләкләргә салган балаларны мактый.

**Кайда шалтыраттылар**?

Балалар түгәрәк ясап яки бүлмәнең стенасы буена утырышалар. Уйнаучыларның тәрбияче билгеләгән берсе түгәрәк уртасына яки утырып торучылар алдына (арты белән борылып) баса. Тәрбияче сигналыннан сон күзләрен йома. Тәрбияче балаларның берәрсенә шалтыравык бирә дә аны шалтыратырга куша.

Түгәрәк уртасында басып торучы бала, күзен ачмыйча гына, кулы белән ишарә ясап, тавышның кайсы яктан ишетелгәнен күрсәтергә тиеш. Әгәр дә ул дөрес күрсәтсә, тәрбияче: «Булды», – дип белдерә, һәм уртада басып торучы бала күзен ача, ә шалтыратучы бала шалтыравыкны югары күтәреп барысына да күрсәтә. Әгәр дә уртада’ торучы бала ялгышса, ул тагын күзен йома, һәм уен яңадан кабатлана. Уртадагы бала икенче уйнаучы белән алмаштырыла.

Уенны 3-4 тапкыр кабатлаганнан соң, балалар, тәрбияче сигналы буенча, бүлмәнең (мәйданчыкның) төрле ягына таралалар. Тәрбияченең: «Урыннарыгызга!» дигән сүзеннән соң балаларның һәрберсе үз урынына барып утыра, һәм уен дәвам итә.

Уенның дәвамы – 3-5 минут.

**Кем тавышы?**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә. Ул уртага кереп утыра һәм күзләрен йома. Тәрбияче алып баручыга сиздерми генә, «Кем тавышы?» дигән сүзләрне әйтергә тиешле баланы билгели. Моннан соң балалар түгәрәк буйлап китәләр һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Ясадык зур түгәрәк.
Без йөрибез бергәләп.
Борылабыз тиз генә,
Тиз генә, җитез генә.

Икенче якка тиз генә борылалар һәм хәрәкәтне шул юнәлештә дәвам итәләр. Билгеләнгән бала: «Кем тавышы?» – ди, калган балалар дәвам итәләр: «Белдеңме? Әйтеп бирче син шуны». Балалар туктыйлар, алып баручы күзләрен ача һәм «Кем тавышы?» дигән сүзләрне әйтүче баланың исемен әйтә. Танылган бала уртага утыра, ә алып баручы аның урынына баса. Таный алмаган очракта алып баручыга үзен тагын бер кат сынап карау мөмкинлеге бирелә.

# ХАЛЫК УЕННАРЫ

**Куышу** («Перехватчики»)
*(Татар халык уены)*

Уен мәйданчыгының каршы якларына ике сызык сызыла. Болар – балаларның «өйләре». Барлык балалар бер сызыкның артына (өй эченә) басалар. Сызыклар арасында уйнаучыларның берсе басып тора.

Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без, балалар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга;
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга.
Тот!

Алып баручының «Бер, ике, өч, инде монда күч!» дигән сүзләреннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота.

2-3 бала тотылганнан соң икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

**Ак калач**
*(Татар халык уены)*

Балалар зур түгәрәк ясап басалар. Бер бала түгәрәк уртасында басып тора.

Балалар, түгәрәк эчендәге баланың исемен әйтеп, түгәрәк буйлап җырлап йөриләр: «җәелгән» сүзендә түгәрәкне киңәйтәләр; «кабарган» дигәндә кулларын бергә күтәрәләр; «кечкенә» дигәндә барысы бергә уртага керәләр (кысылалар); «зур» сүзендә янә түгәрәкне киңәйтәләр һәм ахыргы сүзләрдә, тиз-тизрәк җырлап, кулларын чәбәклиләр. Бу вакытта уртадагы бала уйнаучылардан берәүне уртага чыгара. Уен, икенче баланың исемен әйтеп, кабат башлана.

Әлфиянең туган көненә
Без пешердек ак калач,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кабарган,

Менә шулай кечкенә,
Менә шулай зур гына.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!

**Аю-бүре**
*(Татар халык уены)*

Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Балаларның берсе «аю» яки «бүре» булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап сораша:

– Дуслар, кая барасыз?
– Кара урманга барабыз.
– Кара урманда нишлисез?
– Кура җиләк җыябыз.
– Җиләк белән нишлисез?
– Җиләктән как коябыз.
– Бүре килсә нишлисез?
– Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы да кумәкләп сөйлиләр:

Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә;
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.

**Песием**

*(Татар халык уены)*

Бер бала икенче балага кул сыртын сузып тора. Икенчесе, аның кул сыртын сыйпый-сыйпый, түбәндәгечә тиз-тиз такмак әйтә:

Песи, песи, пес итәр,
Ана песи сөт эчәр,
Ана песи сөт эчкәндә,
Ата песи күз кысар.
Ал дигәндә алмасаң,
Лап итәр дә шап итәр!

«Лап итәр» дигәндә, сыйпаганы теге баланың кул сыртына шап иттереп суга. Тегесе кулын тартып алып өлгермәсә отылган була. Отылмаса, тегесе – сыйпаучы, монысы сугучы була.

**Яшелчәләр**

*(Татар халык уены)*

Балалар арасыннан «бакчачы», «яшелчә алучы» билгеләнеп куела. Балалар бер тирәгә җыелыбрак утыралар, һәм бакчачы аларның колагына яшелчә исемнәре әйтеп чыга. Шулвакыт яшелчә алучы килеп ишек кага һәм ике арада шундый сөйләшү була:

– Тук-тук!
– Кем бар?
– Мин.
– Син кем?

– Кеше.
– Нигә килдең?
– Яшелчә алырга.
– Нинди?
– Шалкан *(теләгәнен әйтә)*.

Әгәр яшелчәләр арасында шалкан булса, ул торып йөгерә һәм билгеләнгән урынны урап килә. Әгәр яшелчә алучы ул арада аны куып тота алмаса, шалкан үз урынына килеп утыра, һәм, аңа яңа исем кушылып, уен дәвам итә. Әгәр бала тотылса, ул уеннан чыга.

Уен яшелчәләр тотылып беткәнче дәвам итә.

**Казлар-аккошлар**

*(Рус халык уены)*

Мәйданчыкның бер башына – «казлар өе», икенчесенә «көтүче өе» билгеләп куела. Бу өйләрдән читтәрәк – «бүре өне». Буш урын – «болын».

К ө т ү ч е. Казлар, казлар!
К а з л а р. Кыйгак-кыйгак! Ка-ка-ка!
К ө т ү ч е. Ашыйсыгыз киләме?
К а з л а р. Бик килә шул, бик килә!
К ө т ү ч е. Алай булса кайтыгыз!
К а з л а р. Без бит кайта алмыйбыз,
Тау астында бүре бар,
Ул безне тотып ашар.
К ө т ү ч е. Сезнең бар канатыгыз,
Очып кына кайтыгыз.

Казлар, канатларын җәеп, болын өстеннән өйгә таба очалар, аларга бүре каршы чыга һәм казларны тотарга тырыша. Тотылган казларны бүре үз өненә алып китә.

**Ябалак һәм кошлар**

*(Рус халык уены)*

Уйнаучыларның берсе «ябалак» итеп билгеләнә. Калган балалар – кошлар. Алдан мәйданчыкның бер почмагында түгәрәк – «ябалак оясы» сызыла. Уенны алып баручының «көн» дигән сигналы буенча балалар мәй-данчыкка таралалар да кошлар шикелле кулларын селкеп, йөгерешеп йөри башлыйлар. Ябалак бу вакытта оясында утыра.

Бераз вакыттан соң алып баручы: «Төн», – дип белдерә. Бу сүздән соң кошлар туктап калалар һәм хәрәкәтсез бер урында басып торалар. Кыймылдарга ярамый. Ә ябалак үз оясыннан чыга да, канатларын салмак кына кага-кага, берәрсе кыймылдамый микән дип карап йөри. Кыймылдаучыларны үз оясына алып китә.

Алып баручы яңадан: «Көн», – дип әйтә. Ябалак үз оясына очып китә, ә кошлар яңадан мәйданчык буйлап очып йөри башлыйлар. Ябалак оясыннан 2–3 тапкыр очып чыга. Аннан соң тотылган кошлар саны исәпләнә. Икенче ябалак сайлана, һәм уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

1. Балаларның кыймылдамый торулары 15-20 секундтан артмаска тиеш. Чөнки балаларга озак вакыт кыймылдамый тору авыр. Кошларның очып йөрүләре 30-40 секунд дәвам итә.

2. Ябалак үзенең игътибарын бер балага гына юнәлтмичә, барлык балаларны берьюлы күзәтергә тиеш.

3. Уенны йомгаклаганда, ябалак оясына бер тапкыр да эләкмәгән балаларны билгеләп үтәргә кирәк.

**Минем күңелле тубым**

*(Рус халык уены)*

Балалар бүлмәнең төрле урыннарында урындыкларда утыралар. Әйдәүче уйнаучыларның каршыларына баса. Аның кулында туп. Ул, тупны идәнгә бәрә-бәрә, түбәндәге сүзләрне әйтә:

Минем күңелле тубым
Матур итеп сикерә.
Әгәр тотып өлгермәсәң,
Әллә кая йөгерә.

Шуннан соң ул балаларны үз янына чакыра һәм аларга туп шикелле сикерергә куша, бер үк вакытта үзе кулындагы тупны идәнгә бәргәли. Балалар, тупка карап, аның темпында сикереп торалар. Әйдәүче тупны идәнгә куя һәм, шигырьне кабатлап, куллары белән туп сикерткән кебек хәрәкәтләр ясый. Балалар да сикерәләр. Шигырь тәмам булгач, әйдәүче: «Тотам!» – ди. Балалар урыннарына йөгерәләр.

Уен кабатлана.

**Инеш**

*(Рус халык уены)*

Уйнаучылар, парлашып, бер-бер артлы тезеләләр – озын «инеш» барлыкка килә. Кулларын югары күтәреп, «капка» ясыйлар. Бер бала так кала. Ул «инеш»нең башына (рәт каршына) барып баса һәм түбәндәге сүзләрне әйтә:

Сәлам, инеш, якын дус,
Килдем синең яныңа,
Рәхәтләнеп уйнарга,
Яңа дуслар табарга.

Б а л а л а р:
Әйдә, әйдә, рәхим ит,
Үзеңә дус табып кит.

Так бала, рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм, аны җитәкләп, ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы исә рәт каршына килә. Ул да үзенә шул тәртиптә иптәш сайлый.

Уен шулай дәвам итә.

# ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ

(5 яшьтән 6 яшькә кадәрге балалар өчен уеннар)

### Куышу

Уен мәйданчыгының кара-каршы ике ягына сызык сызып, уйнаучылар өчен урын билгеләнә. Бу – «өйләр». Барлык уйнаучылар, бер өйгә җыелып, тезелешеп басалар. Бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул ике өй арасында – уйнаучыларга йөзе белән борылып, уртада басып тора.

Йөгерешеп, куышып,
Бергәләп уйнап алыйк.
Кем кыю, өлгер, җитез –
Әйдәгез, сынап карыйк!

Әлеге сүзләрне әйтеп бетерүгә, барлык уенчылар да каршы яктагы өйгә йөгерешә башлыйлар. Алып баручы кемне дә булса тотарга тырыша. Тотылган бала уенны алып баручы була. Уен шулай дәвам итә. Уен ахырында иң өлгер, иң җитез балалар (бер дә тотылмаган) билгеләнә.

### Карусель

Уйнаучылар түгәрәккә басалар. Тәрбияче балаларга ике очы бергә бәйләнгән бау (шнур) бирә. Балалар, уң куллары белән бауга тотынып, сулга борылалар да түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Әллә-лә, әллә-лә,
Карусельләр әйләнә!
Аннары борылабыз,
Һәм бик тиз йөгерәбез.

Балалар, шигырьнең эчтәлегенә туры китереп, башта әкрен генә, аннары кызурак йөриләр, ә соңыннан йөгерәләр.

Балалар йөгергәндә, тәрбияче: «Йө-гер-де-ләр, йө-гер-де-ләр», – дип әйтеп тора.

Балалар түгәрәкне ике тапкыр йөгереп әйләнгәч, тәрбияче: «Борылдык», – дип әйтеп, йөгерү юнәлешен үзгәртә. Уйнаучылар, кинәт борылып, сул куллары белән тиз генә бауга тотыналар һәм кире якка йөгерә башлыйлар.

Аннан соң тәрбияче балалар белән бергә түбәндәге сүзләрне әйтә:

Ашыкмагыз, ашыкмагыз!
Каруселне туктатыгыз!
Бер-ике, бер-ике!
Менә уен да бетте!

Карусельнең хәрәкәте әкренәйгәннән-әкренәя бара. «Менә уен да бетте» сүзләреннән соң балалар, бауны идәнгә куеп, мәйданчыкка таралалар.

Балалар бераз ял иткәч, тәрбияче сигналы буенча балалар яңадан бау янына җыелалар.

Уен кабатлана.

**Почмак алыш**

Мәйданчыкның дүрт почмагына җиргә дүрт кыршау салына. Биш бала, мәйданчыкның уртасына чыгып, бию көенә бииләр. Көй кинәт кенә туктый, балалар почмак алырга тырышалар: кыршауларга таба йөгерәләр. Кыршаусыз калган бала – «ачык авыз» – уеннан чыгарыла. Аның урынына икенче бала чыга. Кырыйдагы балалар сөйлиләр:

Каршыгызда дүрт почмак,
Берегезгә юк почмак.
Җитезрәк кылансагыз,
Алырсыз берәр почмак.

Уен шулай дәвам итә.

**Урыныңны тап**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын як-якка җәеп, түгәрәкне зурайталар. Басып торган урынны билгеләү өчен, һәр баланың алдына берәр уенчык (мәмәслән, шакмак һ.б.) куела.

Тәрбияче бубенга сугып яисә «Йөгерегез!» дип сигнал биргәч, балалар як-якка йөгерешеп китәләр, сикерешеп уйныйлар. Шул арада тәрбияче, балаларга сиздерми генә, берәр баланың уенчыгын алып куя. Бубенга сугып иясә «Урыннарыгызга!» дип сигнал биргәч, балалар кире түгәрәккә таба йөгерешәләр. Һәр баланың үз уенчыгы янына басуы мәҗбүри түгел, алар теләсә кайсы урынны сайлап баса алалар. Урын эзләп йөргән балага балалар барысы бергә түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Йөгер тизрәк, Әминә,
Урынсыз кала күрмә.
(Яисә):
Марат, йөгер тиз(е)рәк,
Урын алырга кирәк.

Соңгы тапкыр уйнаганда, тәрбияче, барлык балаларга да урын булсын өчен, уенчыкны алып куймый.

**Балалар һәм әтәч**

Залның бер башында сызылган сызык артына балалар тезелеп басалар. Уйнаучылардан берәү «әтәч» итеп билгеләнә. Балалардан ерак кына түгел бер түгәрәк сызыла. Бу – «әтәч өе». Әтәч өеннән чыга һәм өч тапкыр: «Кикри-күк!» – дип кычкыра. Шуннан соң уенчылар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Безнең өйнең әтәче
Йокыдан иртә тора.
Безгә йокы бирмичә:
– Кикри-күк! – дип кычкыра.

Әлеге сүзләрне тыңлап торган әтәч горур кыяфәт белән канатларын кагына, тагын бер тапкыр: «Кикри-күк!» – дип кычкыра. «Кикри-күк» сүзеннән соң, уенчылар як-якка йөгерешеп китәләр, әтәч аларны куа. Әгәр ул кемгә булса да кагылса, әлеге бала тотылган булып санала. Һәр тотылган бала уеннан чыга бара.

### Песи һәм тычкан

Уйнаучылардан бер бала – «тычкан», икенчесе «песи» итеп билгеләнә. Калган балалар, бер-берсеннән кул сузарлык ара калдырып һәм кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Бер урында түгәрәк тоташмый кала (ике бала кулга-кул тотынмыйлар). Бу урын капка була.

Песи белән тычкан түгәрәк тышына басалар. Балалар түгәрәк буйлап әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге шигырь сүзләрен әйтәләр:

Безнең песи бик сизгер,
Һәр тавышны ишетә.
Тычканнарны totам дисә,
Армый-талмыйча көтә.

Шигырьнең соңгы сүзләреннән соң песи тычканны куа башлый. Тычкан түгәрәкнең читендә һәм эчендә йөгереп йөри. Ул түгәрәк эченә капкадан да, балаларның кул астыннан да үтеп керә ала. Песи түгәрәк эченә капка аша гына үтә ала.

Түгәрәктә басып торучылар песине кул астыннан үткәрмәскә тиешләр. Песи тычканны тоткач, тәрбияче алар урынына бүтән балаларны билгели.

### Төлке һәм тавыклар

Уен мәйданчыгының бер очында «кетәклек» билгеләнә. Анда «тавыклар» һәм «әтәч» урнаша. Капма-каршы якта «төлке» тора. Тавыклар һәм әтәч (3-5 уенчы) мәйданчыкта җим эзләгән булып йөриләр. Алар янына төлке якынлаша башлагач, әтәч: «Кикри-күк!» – дип кычкырырга тиеш. Бу сигнал буенча барысы да кетәклеккә таба йөгерешә башлыйлар, алар артыннан төлке ташлана, ул берәр тавыкны, йә әтәчне эләктерергә тырыша.

Әгәр төлке бер тавыкны да эләктерә алмаса, яңадан төлке булып кала. Эләктерсә, тотылган тавык төлкегә әйләнә.

### Балыклар

Бер бала «чуртан балыгы» итеп билгеләнә. Калган балалар ике төркемгә бүленәләр: аларның берсе – «ташлар» – түгәрәк ясыйлар, икенче төркем – «табан балыклар» (кәрәкәләр), түгәрәк эчендә «йөзеп йөриләр». «Чуртан» түгәрәк тышында басып тора.

Тәрбиячених «Чуртан!» дигән сигналын ишетүгә, чуртан балыгы түгәрәк эченә йөгереп керә, табан балыкларын тотарга тырыша. Бу арада табан балыклар кайсы да булса «таш» артына качып өлгерергә ашыгалар (йөгереп килеп балалар артына чүгәлиләр). Чуртан таш артына качып өлгермәгән табан балыкларын куа. Тотылган балалар түгәрәк тышына чыгалар.

Уен 3-4 тапкыр кабатланганнан соң, тотылган балалар санала. Аннары яңа чуртан сайлана. Түгәрәктә басып торучы һәм түгәрәк эчендәге балалар урыннарын алмашалар.

Уен кабатлана.

### Куяннар һәм төлке

Балаларның бер төркеме – «куяннар», икенче төркеме «агачлар» итеп билгеләнә. Бер бала «төлке» була. Аңа бер читтә «өй» урыны билгеләнә (түгәрәк сызыла).

Мәйданчыкның каршы якларында сызыклар сызыла. Бу – «кырлар». Уен башланганда, куяннар мәйданчыкның бер башында кырда басып торалар. Агачлар ике сызык арасына урнашалар. Бу – «урман».

Куяннар, урман аша үтеп, бер кырдан икенче кырга күчәргә тырышалар. Бу вакытта агачлар итеп билгеләнгән балалар кулларын өскә күтәреп селкиләр (кайсылары чүгәли, иеләләр). Куяннар урман аша үткәндә, аларның каршына төлке чыга. Ул куяннарны куа башлый. Агачлар төлкегә комачаулыйлар: кулларын тотышып, төлкене үткәрмәскә тырышалар. Төлке тотылган куянны үз өенә алып китә. Берничә куян тотылгач, яңа төлке сайлана.

**Чыпчык, чык!**

Балалар түгәрәккә басалар. Уртада бер бала кала. Ул – «сыерчык». Сыерчык бер бала янына килә дә: «Чык әле, әй, кошчык, исемең кем?» – ди. Ул бала: «Чыпчык», – дип җавап бирә – «Ә үзең кем соң син? Йорисең ник борчып?» – дип сорый. Сыерчык: «Кем дисеңме, чыпчык? Мин булам сыерчык. Бу минем йортым, чык моннан, чык, чык, чык», – ди. Алар, түгәрәк тышына чыгып, икесе ике якка йөгерәләр һәм, йөгереп килеп, буш ояга керергә тырышалар. Урынсыз калган бала түгәрәк эченә баса һәм сыерчык итеп билгеләнә.

Уен шулай дәвам итә.

**Чәчәк бәйләме**

Кызлар өч түгәрәк ясап басалар. Аларның кулларында өч төстәге чәчәкләр. Һәр төркемдә уенны алып баручы билгеләнә, аның башына шул төркемдәге чәчәкләр төсендә чәчәк беркетелә. Тәрбиячененң сигналы буенча җиңелчә көй астында балалар бүлмә буйлап йөгереп йөриләр. Көй бетүгә, балалар үз түгәрәкләренә җыелырга тиешләр.

Иң беренче булып җыелып беткән төркем – чәчәк бәйләме – җиңүче була.

**Мин качам, син тот**

Уйнаучылар кулга-кул тотынышып, парлашып басалар. Алда, аларга каршы, уенны алып баручы баса. Балалар, бергәләп:

Без, балалар, яратабыз
Качыш-тотыш уйнарга.
Әйдә безне тотып кара,
Көчең җитсә тотарга», –

дип әйтүгә, беренче булып басып торган пар кулларын ычкындыра, һәм икесе ике якка йөгереп китә. Уенны алып баручы аларның берсен тотарга тиеш. Тотылган кеше уенны алып баручы була.

**Яулык**

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул, кулына яулык тотып, түгәрәк тышында йөри. Яулыкны тиз генә бер баланың җилкәсенә сала да түгәрәк буйлап йөгереп китә. Җилкәсенә яулык салынган бала уенны алып баручыны куа. Алар икесе дә беренче булып буш урынга килеп җитәргә тырышалар.

Әгәр дә куучы бала алдагы баланы куып җитеп, яулыкны аның җилкәсенә сала алса, буш урынга үзе баса. Куып җитә алмаган очракта, ул уенны алып баручы булла: түгәрәк тышына басып, түгәрәк буйлап йөри һәм яулыкны кемнеңдер иңенә сала.

Уен дәвам итә.

**Кармак**

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Уртага, кулына бау (сикергеч) тотып, уенны алып баручы баса. (Бауның очына комлы янчык бәйләнә) Ул, бау һәр баланың аягына тиярлек итеп, бауны идәндә әйләндерә башлый. Һәр бала сикергечнең хәрәкәтен игътибар белән күзәтә һәм, бау аның янына якынлашканда, бауны тидермәс өчен, сикереп ала. Аягына бау тигән бала уртага баса, сикергечне әйләндерә башлый, ә уенны алып баручы әлеге баланың урынын ала.

*Уенга күрсәтмәләр*

1. Кармак үз турыңа якынлашкач кына сикерергә кирәк.
2. Ком тутырылган капчык җиргә (идәнгә) ышкылып әйләнергә тиеш.

**Бау аша сикер**

Ике бала яисә тәрбияче белән аның ярдәмчесе, юан бауны баш башларыннан тотып, кара-каршы басалар. Бауны әкрен генә әйләндерә башлыйлар. Кырыйда торган балалар, бер-бер артлы килеп, бау аша сикерәләр. Сикергән вакытта аякларын бауга тидермәскә тырышалар. Аягы бауга тигән бала уеннан чыга яисә бауны тотып торучыларның берсен алмаштыра.

Уенны кайбер биремнәр белән катлауландырырга мөмкин: мәсәлән, кем 5-10 тапкыр бау аша бер дә ялгышмыйча (аягын бауга тидермичә) сикерә ала һ.б.

**Бүре һәм куяннар**

Уйнаучыларның берсе «бүре» итеп билгеләнә. Калган балалар «куяннар» булалар.

Мәйданчыкның бер ягында куяннар, нарат күркәләреннән, кечкенә ташлардан түгәрәкләр, квадратлар ясап, үзләренә урыннар әзерлиләр (кыршаулар салырга мөмкин).

Уен башында куяннар үз урыннарында торалар. Бүре мәйданчыкның икенче (каршы) ягында «чокырда» утыра.

Тәрбияче түбәндәге сүзләрне әйтә:

Яшел болында куяннар
Сикергәләп йөриләр,
Як-якларына каранып,
Бүре килүен күзлиләр.

Куяннар урыннарыннан (түгәрәкләрдән) сикереп чыгалар да мәйданчыкка таралалар. Алар ике аякта берьюлы сикереп йөриләр, бүре килмиме икән дип, тирә-якка караштыргалыйлар. Шигырьнең соңгы сүзләреннән соң, бүре чокырдан чыга да куяннарны тотмакчы булып, алар артыннан йөгерә. Куяннар исә үз урыннарына (түгәрәкләргә) йөгерәләр. Тотылган куяннарны бүре үзе белән чокырга алып китә.

Бүре китүгә, тәрбияче шигырь сүзләрен кабатлый һәм уен яңадан башлана.

2-3 куян тотылганнан соң тәрбияче яки уйнаучылар икенче бүре сайлап куялар.

**Күчтек**

Идәндә диаметры 20-30 м лы зур түгәрәк, ә аның эчендә уйнаучылар санынча кечкенә түгәрәкләр (диаметры 60-70 см) сызыла. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана, ул зур түгәрәк уртасында басып тора.

Уенны алып баручы: «Күчтек!» – ди. Бу сүздән соң уйнаучылар, бер аякта сикерә-сикерә барып, тиз генә бер-берләре белән урыннарын (түгәрәкләрен) алышалар. Алып баручы да, бер аягында сикерә-сикерә барып, берәр түгәрәк эченә кереп калырга тырыша. Урынсыз калган бала уенны алып баручы була.

**Кем тизрәк?**

Балалар, бер-берләренә комачауламаслык итеп, бер рәткә тезелеп басалар. Кулларында – сикергечләр (скакалкалар). Алардан 15-20 м ераклыкта (мәйданчыкның икенче башында) җирдә сызык сызыла яисә бау тарттырыла.

Тәрбиячене сигналы буенча балалар бөтенесе бергә сызыкка таба сикергечләр белән сикереп бара башлыйлар. Сызык янына беренчеләрдән булып килеп җиткән балаларны җитезлекләре өчен тәрбияче мактый.

**Идәндә калма**

Бүлмәнең төрле җирләренә, бер-берләреннән ара калдырып, 25-30 см биеклегендә төрле әйберләр: баскычлар, биеклеккә куелган такталар, зур шакмаклар, киңлеге 25 см дан ким булмаган эскәмияләр куела. (Балалар шул әйберләр өстенә менәргә тиеш булалар.) Әбәкче сайлана һәм аның кулына тасма бәйләнә. Балалар бүлмәнең төрле җирләренә урнашалар.

Балалар бубен тавышына мәйданчык буйлап йөриләр, йөгерәләр яки сикерәләр. Әбәкче дә балалар белән бергә йөри. Тәрбиячене «Тот!» дигән сигналыннан соң барлык балалар мәйданчыкка куелган теләсә кайсы әйбер (биеклекләр) өстенә менеп урнашалар. Әбәкче әйберләр өстенә менеп өлгермәүчеләрне тота. Тотылган балалар читкә барып утыралар. Уенны 2-3 тапкыр кабатлагач, тотылган балалар саны билгеләнә һәм икенче әбәкче сайлана.  Икенче әбәкче сайлангач, уен яңадан башлана.

**Сазлык**

Бер-берсеннән 10-15 адым киңлегендә ара калдырып, ике сызык уткәрелә («сазлык»). Алар арасына, бер-берсеннән 25-50см ара калдырып, түгәрәкләр («түмгәкләр») сызыла. Балалар шушы түмгәкләргә басып, сазлыкның бер ягыннан икенче ягына (бер сызыктан икенчесенә) күчеп чыгарга тиешләр. Балалар түмгәктән-түмгәккә берьюлы ике аяк белан сикерәләр. Сазга баткан балалар уеннан чыгалар (кырыйга чыгып, «аякларын киптереп утыралар»).

**Аю һәм бал кортлары**

Уйнаучылар икегә – берсе зуррак, икенчесе кечерәк төркемнәргә бүленәләр. Кечерәк төркем (уйнаучыларның өчтән бер өлеше) – «аюлар», зуррагы «бал кортлары»

булалар. Мәйданчыкның бер ягында гимнастика баскычы – «умарта» тора. Икенче якта, «умартадан» 8-10 метр ераклыкта, сызык белән «болын» билгеләнә. Гимнастика баскычыннан 3-5 метр читтәрәк «аю өне» тора.

Бал кортлары гимнастика баскычына (умартага) урнашалар. Тәрбияче сигналы буенча кортлар, безелдәп, болынга бал эзләргә очалар. Кортлар очып китүгә, аюлар, гимнастика баскычына үрмәләп менеп, умартага керәләр һәм бал белән сыйланалар. Тәрбиячедең: «Аюлар!» дигән сигналыннан соң кортлар умартага очалар, ә аюлар, гимнастика баскычыннан төшеп, өннәренә качалар. Өннәренә качып өлгермәгән аюларны кортлар чагалар (аларга куллары белән кагылалар). Аннан соң кортлар гимнастика баскычына кире кайталар, һәм уен яңадан башлана. Чагылган аю икенче тапкыр бал ашарга чыкмый, оясында кала. Уен ике-өч тапкыр кабатлангач, балалар рольләрен алмашалар.

*Уенга күрсәтмәләр*

1. Баскычтан төшкәндә, аның барлык басмаларына да басып төшәргә кирәк. Җиргә сикергәндә, баскычның иң соңгы басмасыннан гына сикереп төшәргә рөхсәт ителә.

2. Уйнаучыларның гомуми саны 10-12 баладан артык булмаска тиеш. Чөнки уйнаучылар күп булганда, аларның барысы да гимнастика баскычына менеп урнаша алмый.

3. Тәрбияче гимнастика баскычы янында торырга һәм кирәк вакытта балаларга булышырга тиеш.

## Янгын сүндерүчеләр

Уенда катнашучылар ике-өч төркемгә бүленәләр. Һәр төркем бер-бер артлы тезелә дә, гимнастика баскычыннан 4-5 м ара калдырып, аның каршына баса. Болар – «янгын сүндерүчеләр».

Баскычның иң өске аратасына төркем санынча кыңгырау эленә.

Тәрбияче сигнал бирүгә, төркемдә беренче булып басып торучылар, гимнастика баскычы янына йөгереп киләләр, баскычка үрмәләп менеп, кыңгырауны шалтыраталар. Җайлап кына баскычтан төшеп, үз колонналарының артына барып басалар.

Тәрбияче яңадан сигнал бирә. Бу юлы колонналарда икенче булып басып торучылар йөгерә. Уен шулай дәва итә.

Уен ахырында тәрбияче баскычта тиз үрмәләргә өйрәнгән балаларны билгеләп үтә.

*Уенга күрсәтмә*

Уен барышында тәрбияче гимнастика баскычы янында басып тора һәм балаларның баскычка дөрес итеп үрмәләп менүләрен, төшүләрен күзәтә.

## Соңга калма!

Бер рәткә 3-4 эскәмия тезелеп куела. Аларның алдында һәм артында, 3 м ара калдырып, сызык үткәрелә. 5-6 бала дүрт аякка басалар, эскәмияләргә кадәр мүкәләп баралар, эскәмия астыннан шуышып чыгалар да басып каршыдагы сызыкка кадәр йөгерәләр. Анда борылалар, кабат дүрт аякка басалар һәм эскәмияләргә кадәр мүкәлиләр, аларның астыннан шуышып чыгып, башлангыч сызыкка йөгереп киләләр.

*Уенга күрсәтмә*

* Эскәмияләр астыннан теләсә нинди ысул белән (турыга, ян белән) чыгарга мөмкин.

**Аучы һәм куяннар**

Мәйданчыкның бер ягында сызык белән аучы урыны билгеләнә. Санамыш ярдәмендә «аучы» сайлана. Икенче якта «куяннар» өчен түгәрәкләр сызыла. Һәр түгәрәккә 2-3 куян урнаша. Аучы, куян эзләрен эзләгән булып, мәйданчыкны әйләнеп чыга һәм үз урынына кайта.

Тәрбияче: «Куяннар аланга чыктылар», – ди. Куяннар, үзләренең түгәрәкләреннән чыгып, ике аякларында сикерә-сикерә, алга таба йөгереп китәләр. Тәрбиячենең «Аучы!» дигән сүзеннән соң, куяннар түгәрәкләр эченә йөгерәләр, ә аучы, урыныннан кузгалмыйча, аларга туп ыргыта. Туп тигән куянны аучы үз янына алып китә.

Уенны ике-өч тапкыр кабатлаганнан соң, икенче аучы сайлана.

Уен дәвам итә.

**Кыршау эченә ыргыт**

Балалар залда 2-3 төркем булып басалар. Аларның каршысына идәнгә кыршаулар (диаметры 50 см) салына. Уйнаучыларга кечкенә туплар бирелә. Төркемнәрдәге балалар тәрбияче сигналы буенча кулларындагы тупларны, кыршау эченә туры китерергә тырышып, ыргыталар. Иң төз ыргытучы балаларны тәрбияче мактый.

**Тупны ыргыт!**

Балалар залның бер башында тезелеп басып торалар. Кулларында – зур туплар. Бүлмәнең (мәйданчыкның) икенче башына, каршы якка, сызык сызыла (ара ераклыгы балаларның көчләренә карап билгеләнә). Уйнаучылар бер адым алга чыгып басалар. Тупны сызык артына җиткерергә тырышып, ыргыталар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче кайсы баланың тупны сызыкка кадәр җиткермәвен, кайсысының сызыктан уздырып җибәрүен билгели.

• Тупны ыргытучылар аны йөгереп барып алып киләләр дә икенче балаларга бирәләр.

**Тупны сетка аша ыргыт**

Мәйданчыкта, балаларның буеннан югарырак итеп, сетка тартылып куела. Балалар, сетканың ике ягына ике адым ераклыкта басып, сетка аркылы туп ыргыталар.

Туп ыргыту түбәндәгечә бара: беренче бала каршыдагы балага ыргыта. Каршыдагы беренче бала киредән үз каршында баскан беренче балага ыргыта. Аннан соң беренче бала тупны икенче балага бирә. Шул рәвештә уен дәвам итә. Яхшы ыргытып, тупны тоткан пар бер адым артка чигә. Димәк, икенче уенда ераграк арадан ыргыталар. Алдан билгеләнеп куелган чиккә җиткәч, уен бетә.

**Серсо**

Ике бала, 3-4 м ара калдырып, кара-каршы басалар. Берсенең кулында серсо таягы һәм 4-5 боҗра (диаметры 20 см), ә икенчесенең кулында таяк кына була. Беренче бала

бождраларын таягы ярдәмендә, бер-бер артлы, каршыда басып торган балага таба ыргыта, ә тегесе аларны таягына кидереп тора. Иң күп бождра тота алган бала җиңүче була.

*Уенга күрсәтмәләр*

Баштарак – балалар бождраларны таяк белән ыргытып, тота алмаган очракта – аларны кул белән ыргытырга һәм тотарга мөмкин.

**Кем тизрәк җыелыр?**

Балалар берничә төркемгә бүленәләр һәм, сигнал буенча, төрле якка йөгерешеп китәләр. Тәрбиячененң «Җыелырга!» дигән командасы буенча, төркемнәр үз урыннарына җыелалар. Тизрәк җыелган төркем җиңүче була.

**Флаг янына**

Уйнаучылар урындыкларда утыралар. Мәйданчыкның (залның) кырыеннан 5-6 адым ераклыкта сызык сызыла. Сызык артына 4-5 бала баса.

Мәйданчыкның каршы ягына, сызыктан 18-20 адым (10-12 м) ераклыкта сызык артында торучы балалар санынча урындыклар куела. Тәрбияче урындыклар өстенә берәр флаг куеп чыга. Тәрбиячененң сигналы буенча (бубен тавышы, кул чабу яки «бер, ике, өч, йөгер» сүзләреннән соң), балалар флаглар янына йөгереп баралар, аларны алып югарыга күтәрәләр һәм яңадан урындыкларга куялар. Тәрбияче балаларның кайсысы флагны алданрак күтәргәнен билгели. Аннан соң балалар урындыкларга утыралар, ә алар урынына сызык артына 4-5 кешедән торган икенче төркем баса.

Барлык балалар да флаглар янына берәр мәртәбә йөгереп узгач, уен тәмам була.

Уен 2-3 тапкыр кабатлана.

**Тупны тизрәк тапшыр**

Уйнаучылар ике рәткә басалар. Беренче булып басып торучыларга зур туп бирелә. Сигнал булуга, балалар тиз-тиз генә тупны бер-берләренә бирәләр. Тупны рәттә иң соңгы басып торучы алгач, барысы да тиз генә кире якка әйләнеп басалар һәм тупны кабат җибәрәләр. Беренче булып басып торучыга туп килеп җиткәч, кабат әйләнеп басалар (баштагы торышларына кире кайталар).

Уен берничә тапкыр кабатлангач, җиңүчеләр билгеләнә.

**Каршылыклар юлы**

Балалар, ике колоннага бүленеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Юлга каршылыклар куела: залның бер башында, рейкаларга тоташтырып, 15-20 см биеклектә бау бәйләнә (яки 50-60 см киңлектә сызык сызыла). Икенче башка, араларын 80 см калдырып, 3-4 кыршау куела һ. б.

Сигнал булуга, колоннада беренче булып басып торган бала бау аша сикереп чыга да, кыршауларга таба йөгерә. Кыршаудан үрмәләп чыкканнан соң, йөгереп килеп, колоннада икенче булып басып торган балага кулы белән кагыла да колоннаның артына барып баса. Ярышны икенче бала дәвам итә.

Каршылыкларны үтеп, беренче булып тезелергә өлгергән команда җиңүче була.

**Кайсы төркем җитезрәк?**

Уйнаучылар 3-4 төркемгә бүленеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Беренче булып басып торучы балаларның кулларында зур туплар. Һәр төркем алдына идәнгә диаметры 50 см лы кыршау салына. Тәрбияче сигнал биргәч, беренче бала тупны кыршау эченә бәрә, сикергән тупны, ике кулы белән тотып алып, икенче уенчыга бирә, ә үзе, йөгереп барып, төркемнең артына баса. Уенны икенче бала дәвам итә. Туп беренче уйнаучыга килеп җиткәч, ул аны тиз генә баш өстенә күтәрә. Тәрбияче җиңүче төркемне билгели.

**Кыршау тәгәрәтү**

Уйнаучылар кыршаулар тотып, бер-берсеннән 1 м ара калдырып, рәткә тезелеп басалар. Тәрбияче сигналы буенча, алар, кыршауларны тәгәрәтеп, 5-6 м ара үтәләр. Финиш сызыгына беренче булып килеп җиткән бала җиңүче була.

# ХАЛЫК УЕННАРЫ

**Кемдә йөзек?**

*(Татар халык уены)*

Уйнаучылар урындыкларда утырып торалар. Алардан берсе йөзек салучы итеп билгеләнә. Ул, кулына йөзек алып, уйнаучыларның һәммәсенең учына йөзек салып чыккан булып кылана, тик йөзекне берсендә генә калдыра. Аннары:

– Кемдә йөзек, сикереп чык! – ди.

Йөзекле бала урыныннан тора һәм: «Йөзек миндә!» – ди. Аңа җәза бирелә (җыр җырлый һ.б.).

**Мияу, мияу, нинди төс?**

*(Татар халык уены)*

Балалар санамыш ярдәмендә бер «песи» сайлап куялар. Калганнары бер сафка тезелә. Песи алга баса һәм: «Ми-яу, ми-яу!» – ди. Балалар: «Нинди төс?» – дип сорыйлар. Песи берәр төсне атый. Мәсәлән, сары булсын, ди. Балалар тизрәк якын-тирәдәге сары төстәге әйберне тотарга тырышалар (сары күлмәк, туп һ.б.). Андый әйбер тапмаган бала тиз генә йөгереп китә. Песи аны тотарга тиеш. Тота алса, тотылучы песи була, тота алмаса, үз урынында кала.

Уен шулай дәвам итә.

**Ак, димә, кара, димә…**

*(Татар халык уены)*

Балалар тезелеп утыралар. Санамыш ярдәмендә сорау бирүче билгеләнә. Ул балаларга төрле сораулар бирә. Аңа җавап бирүче «ак», «кара», «әйе», «юк» димәскә тиеш. Башны түбән иярга һәм көләргә дә ярамый. Сорау бирүче, бер баланың каршына басып, әйтергә ярамаган сүзләрне әйттерү өчен, юри сораулар бирә:

– Синең күлмәгең нинди, акмы?

– Кызыл.

– Синең аягыңда туфлиме?

– Итекләр.

– Сөтнең төсе нинди? һ.б.

Әгәр бала, ялгышып, әйтергә ярамаган сүзләрнең берәрсен әйтсә, йә булмаса башын исә, яки көлеп җибәрсә, ул бала сорау бирүче була. Уенның кагыйдәсен шигырь юллары белән әйтеп, уенны дәвам итә:

«Ак», димә, «кара», димә,
Башыңны түбән имә.
«Әйе», димә, «юк», димә,
Көлмә, елмайма.

**Буяу сатучы һәм буяулар**

*(Татар халык уены)*

Кызлар бер якка, малайлар икенче якка тезеләләр. Уен алып баручы (буяу сатучы) кызларга буяу төсләре кушып чыга. Малайлар берәм-берәм «буяу» сатып алырга киләләр. Алучы сатучыга болай ди:

Буяуларың бар микән,
Зәңгәр микән, ал микән?
«Төсем матур, мине ал», –
Диючесе бар микән?

Буяу сатучы җавап бирә:

Буяуларым күптән-күп:
Зәңгәр, кызыл, яшел, күк,
Кайсы һөнәрен күрсәтсә,
Шуңа шөһрәт, даннар күп.

Сатып алучы бер төсне атый. Әлеге төс белән билгеләнгән бала үзенең нинди дә булса һөнәрен күрсәтә. Сатып алучы бу төсне алып үз сафына китә. Аннан буяу сатып алырга икенче малай килә. Уен буяулар алынып беткәнче дәвам итә.

**Очты, очты**

*(Татар халык уены)*

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Алын баручы түгәрәкнең утрасына чыга һәм: «Очты, очты, казлар очты!» – дип, кулы белән очкан сыман хәрәкәт ясый. Башкалар аның артыннан кабатлый. Шулай, берничә кат оча торган кошларны, әйберләрне (самолет, вертолет, шар һ. б.) очыргач, искәрмәстән генә: «Очты, очты, ташлар очты!» – дип, очмый торган берәр әйбернең исемен атый. Бу вакытта түгәрәктәгеләр кулларын күтәрмәскә тиеш. Берәрсе абайламыйча кулын күтәрсә, алып баручы: «Бар алайса, таш белән бергә оч!» – дип, урынын бирә, үзе түгәрәккә баса. Ялгышучылар берничә булса, уенны иң беренче булып ялгышкан бала алып бара.

Уен шулай дәвам итә.

**Шат балалар**

*(Рус халык уены)*

Уен тиз йөгерергә, җитезлеккә өйрәтә.

Балалар тәрбияче белән бергә түгәрәкләнеп тезеләләр һәм бер-берсе белән кулларына тотынышалар. Түгәрәк уртасына әйдәүче баса. Балалар түгәрәк буенча уңга яки сулга таба әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне көйләп әйтәләр:

Без кечкенә, шат балалар,
Яратабыз уйнарга.
Йөгерергә, җырларга.
Я, безне тотып кара,
Тот!

Соңгы «Тот!» дигән сүзне әйтү белән балалар мәйданчык (бүлмә) буйлап йөгерә башлыйлар, ә әйдәүче аларны куып тотарга тырыша.

Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгалар. Әйдәүче 3-5 баланы тоткач, уен тәмамлана. Уйнаучылар арасыннан яңа әйдәүче сайлана (тотылган балалар сайлана алмый). Яңа уенга уткән уенда тотылган балалар барысы да яңадан катнаша. Уен 3-5 тапкыр кабатлана.

### Ике суык

*(Рус халык уены)*

Мәйданчыкның (бүлмәнең) ике ягында сызыклар белән ике «өй» билгеләнә. Өйләр арасы 25-30 адым (12-15 м) булырга тиеш. Уйнаучылар мәйданчыкның бер ягына урнашалар. Ике бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Алар, йөзләре белән уйнаучыларга карап, мәйданчык уртасына басалар. Уенны алып баручыларның берсе – Суык-кызыл борын, икенчесе Суык-күмгәк борын була. «Башлагыз!» дигән сигналдан соң, алар болай диләр:

Без икебез бертуган,
Ике суык, җил-буран!
– Мин – Суык-кызыл борын,
– Мин – Суык-күмгәк борын.
Юлга чыгып китәргә
Кем курыкмый, әйтегез?
Юлда очраучыларның
Өшетәбез барысын.

Балалар хор белән җавап бирәләр:

Без суыктан курыкмыйбыз,
Йөгерәбез, уйныйбыз!
Шуңа да без туңмыйбыз.

«Туңмыйбыз» дигән сүздән соң барлык уйнаучылар каршы яктагы өйгә йөгерәләр, ә ике суык куллары белән кагылап аларны «туңдырырга» тырыша. (Суык кулы белән кагылуга, уйнаучы туктарга тиеш.) Туңдырылган балалар, тотылган урында туктап, барлык уйнаучылар йөгереп узганчы кузгалмыйча басып торалар. Туңдырылган балалар саны исәпләнә, аннан соң алар калган уйнаучыларга кушылалар.

Йөгереп күченүләр 3-4 тапкыр кабатлана. Туңдырылган балаларның гомуми санын исәпләгәннән соң, икенче суыклар сайлана, һәм уен яңадан башлана.

### Диңгез дулкынлана

*(Рус халык уены)*

Уйнаучылар мәйданчык буйлап таралалар һәм бер-берләреннән 1 м тирәсе ара калдырып туктыйлар. Басып торган урыннарын түгәрәк сызык белән билгелиләр. Уенны алып баручы, төрле хәрәкәтләр ясап, уйнаучылар арасында йөри һәм: «Диңгез

булкынлана», – дип, бер баланың иңенә кулын куя. Бу бала алып баручыга иярә, ул ясаган хәрәкәтләрне ясый. Алып баручы җилкәләренә кулын куйган барлык балалар да берәм-берәм алып баручы артыннан иярәләр һәм аның хәрәкәтләрен кабатлыйлар. Шулай итеп. уйнаучылар үз урыннарыннан ераклашалар. Түгәрәкләрдән читкә киткәч, алып баручы кинәт кенә туктап кала, уйнаучыларга борылып: «Диңгез тынычланды», – ди. Барысы да (уенны алып баручы да) түгәрәкләргә таба йөгерәләр. Түгәрәксез калган бала уенны алып баручы була.

**Тилгән**

*(Рус халык уены)*

Уйнаучылар арасыннан «тилгән», «тавык» сайлана. Калган балалар «чебиләр» булалар. Чебиләр бер-бер артлы тезелеп басалар, тавык аларның алдында тора. Тилгән бер читтә утыра, «чокыр казый». Тавык чебиләре белән аның тирәсендә әйләнеп йөри. «Тавык» белән «тилгән» сөйләшәләр:

– Тилгән, тилгән, син нишлисең?
– Чокыр казыйм.
– Сиңа чокыр нәрсәгә?
– Акча эзлим.
– Сиңа акча нәрсәгә?
– Энә сатып алырга.
– Сиңа энә нәрсәгә?
– Капчык тегәргә.
– Сиңа капчык нәрсәгә?
– Синең балаларыңны салырга.

Шуннан соң тилгән иң арттагы чебине тотып ала да, читкәрәк илтеп, «капчык»ка сала. «Капчык»тагы балалар шул урыннан китә алмый, уенны күзәтеп торалар. Тавык чебиләрнең алдына барып баса, балаларын саклый. Әмма тилгән башка чебиләрне дә тотып бетерә. Барлык чебиләр тилгән кулына эләгеп беткәннән соң, уен тәмамлана.

**Буяу сатыш**

*(Башкорт халык уены)*

Санамыш ярдәмендә «сатучы» һәм «көтүче» билгеләнә. Сатучы бер рәткә тезелешеп утырган балалар тирәсендә йөри һәм һәрберсенең колагына берәр төс әйтеп чыга. Бу вакытта көтүче читтәрәк тора.

Көтүче уйнаучылар янына килә һәм түбәндәге сүзләрне әйтә:

Буяулары бар микән?
Зәңгәр микән, ал микән?
«Төсем матур, мине ал», – дип,
Әйтүчеләр бар микән?

Шуннан соң ул: «Тук-тук-тук!» – дип, сатучы янына килә, ишек шакый. Сатучы белән көтүче арасында түбәндәге сөйләшү була:

– Кем бар анда?
– Хуҗалар өйдәме?
– Әйдә, әйдә, узыгыз!
– Сатучы, син буяу сатасыңмы?
– Сатуын сатар идем дә, сиңа кирәкле буяу бар микән соң үземдә?

Көтүче берәр төсне атый, мәсәлән, «Миңа кызыл төс кирәк», – ди. «Кызыл төс» итеп билгеләнгән бала сикереп тора да йөгереп китә. Көтүче аны куа башлый. Әгәр тота алса, үз янында калдыра, әгәр дә тота алмаса, «кызыл буяу» кире үз урынына барып утыра, аңа башка төрле буяу исемен кушалар (мәсәлән, шәмәхә һ.б.).

Уен барлык буяулар сатылып беткәннән соң гына тәмам була.

### Давыл
*(Башкорт халык уены)*

Балалар, ике төркемгә бүленеп, кара-каршы урындыкларга утыралар. Тәрбияче: «Яшен яшьни!» – дисә, балалар кулларын чәбәклиләр, «Яңгыр ява!» – дигәндә, куллары белән тезләренә суккалыйлар; «Күк күкри!» – дигәндә, аякларын тыпырдаталар; «Давыл чыкты!» – дигәндә, һәр бала үз урындыгы тирәли әйләнеп чыга һәм кире урынына утыра. Кайсы төркем урындыкларга алданрак утырышып бетә, шул җиңүче дип табыла.

### Без унике кыз идек!
*(Башкорт халык уены)*

Бу уенны, гадәттә, кызлар гына уйный. Теләсәләр, уенга малайлар да катнаша ала.

Балалар идәнгә түгәрәк ясап, бер-берсенең баш бармакларына тотынышып утыралар. Барысы бергә түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Бер тактага җыелдык,
Таң атканда юк булдык!

Шигырьнең беренче юлында балалар башларын ияләр, икенче юлында, киресенчә, башларын күтәрәләр, тураялар. «Юк булдык!» – дигәндә сикерешеп торалар да төрле яка йөгерешә башлыйлар. Куучы кыз аларның артыннан йөгерә. Тотылган бала уеннан чыга.

### Биляша
*(Мари халык уены)*

Залның ике башында кара-каршы старт сызыгы сызыла. Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм, 4-5 м ара калдырып, старт сызыгы артына басалар; уң кулларын алга сузалар. Санамыш ярдәмендә уенны башлаучы команда билгеләнә. Сигнал булуга, командадан берәү: «Биляша!» – дип кычкыра һәм каршы як сызыгында басып торучыларга

таба йөгерә. Ул, йөгереп килеп, бер уенчының кулына ябыша һәм аны үз ягына таба тарта башлый. Әгәр дә ул көндәшен үз командасына кадәр тартып китерә алса, көндәше аның «әсире» (пленнигы) булып санала, һәм ул артка баса. Әгәр тартып китерә алмаса, ул үзе әсир була да көндәшләренең артына барып баса.

Хәзер инде уенны каршы як команда дәвам итә. Үз ягына иң күп уенчыны тартып китерүче команда җиңүче була.

**Туп тәгәрәтү**

*(Мари халык уены)*

Уен өчен йон тутырылган туп кирәк булачак.

Мәйданчыкның бер башында туры сызык сызыла. Аннан 3-5 м ераклыкта зур булмаган бер чокыр казыла (тирәнлеге һәм диаметры туптан аз гына зуррак). Уйнаучылар сызык артына басалар.

Беренче уенчы чокырга таба тупны тәгәрәтеп (ыргытырга ярамый) җибәрә. Әгәр дә туп чокырга төшсә, бу балага бер очко бирелә, һәм ул тупны тагын тәгәрәтә. Кертә алмаган очракта, тупны икенче уенчы тәгәрәтә. Иң күп очко җыйган бала җиңүче була.

**Божра кемдә?**

*(Мари халык уены)*

Уйнаучылар, йөзләре белән уртага карап, түгәрәк ясап басалар, кулларын артка яшерәләр. Бер баланың кулында боҗра. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә. Ул уртага баса. Сигнал булуга уйнаучылар, алып баручыга сиздерми генә, боҗраны бер-берләренә тапшыра башлыйлар. Алып баручы боҗраның кемдә икәнен белергә тырышып, уйнаучылардан берсенең исемен атый. Әгәр ул өч тапкыр ялгышса, аңа җәза бирелә (чүгәләргә, ике аякта сикерергә һ.б.).

*Уенның кагыйдәләре*

1. Уйнаучылар бер-берләре белән тыгыз итеп (җилкәләрен тидереп) басарга тиешләр.

2. Боҗра бары тик арттан гына җибәрелә.

**Козгын**

*(Мордва халык уены)*

Уйнаучылар арасыннан «тавык» һәм «козгын» сайлана. Калган балалар – «чебиләр». Козгын уйнаучылардан читкәрәк барып урнаша. Тавык үзенең чебиләре белән болында йөри. Кинәт алар каршына козгын килеп чыга. Козгын белән тавык арасында шундый сөйләшү була:

К о з г ы н. Тавык, тавык, миңа чебиеңне бир!

Т а в ы к. Бирмим сиңа, козгын, бер чебиемне дә бирмим!

К о з г ы н. Мин синең барлык чебиләреңне тотам да алып китәм!

Козгын чебиләрне тота башлый. Тавык, чебиләрен бирмәскә тырышып, аның

каршысына чыга, аңа чебиләрне тотарга комачаулый.

Т а в ы к. Көш-ш! Көш-ш, козгын!

К о з г ы н. Тотам! Тотам!

Барлык чебиләр тотылып беткәч, уен тәмамлана.

**Куяннар**

*(Мордва халык уены)*

Бер уенчы «эт» була, калганнары – «куяннар». Эт алдан билгеләп куелган сызык артына барып баса, ә куяннар, мәйданчык буйлап таралып, йөгереп-сикереп йөриләр. Сигнал булуга эт, урыныннан торып, куяннарны куа башлый. Эт кайсы да булса берәр куянга якынлашса, әлеге уенчы тиз генә чүгәли. Чүгәләгән куянны тотарга ярамый. Әгәр дә эт берәр куянны тота алса, ул куян да башка куяннарны куа башлый. Уен куяннар тотылып беткәнче дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

1. Буталыш килеп чыкмасын өчен, тотылган куян: «Мин –эт!» – дип кычкыра, шуннан соң гына куяннарны куа башлый.

2. Эт куяннарны сигнал булганнан соң гына куа башларга тиеш.

**Яулыклар**

*(Мордва халык уены)*

Санамыш ярдәмендә «әби» һәм «бабай» сайлана. Калган балалар – «яулыклар», алар урындыкларда утырып торалар. Бабай уенчылар яныннан читкәрәк китеп баса. Әби яулыкларның колагына, бабай ишетмәслек итеп, төсләр әйтә. Бабай әби янына килә һәм алар арасында шундый сөйләшү була:

– Исәнме, әби. Сәлам бирдем.

– Исәнме, бабай. Әйдә, уз.

– Синдә яулыклар бар дип ишеттем. Сатмассыңмы икән?

– Әйе, яулыклар бар. Акчаң җитәрме соң?

– Миндә ике сандык акча бар.

– Алайса, сатам. Ал әйдә. Нинди төстәге яулык кирәк?

– Яшел (сары, кызыл һ.б.)

Бабай әйткән төстәге яулык йөгереп китә, бабай аны куа. Тота алса, үзе белән алып китә. Тота алмаган очракта, әби яулыкка бүтән төс әйтә һәм ул башка уенчылар янына барып баса.

Уен барлык яулыклар тотылып беткәнче дәвам итә.

**Туп һәм чокыр**

*(Удмурт халык уены)*

Уенда 3-5 бала катнаша. Уен җәй көне урамда уйнала. Җиргә 1,5-2 м диаметрлы әйләнә сызыла, әйләнә эченә уйнаучылар санынча кечкенә чокырлар казыла. Һәр уенчы

үз чокырын билгели – төрле төстәге шакмак, таш, яфрак һ.б. ны сала.

Бер уенчы, әйләнәдән 3–4 м ераккарак китеп, тупны тибеп җибәрә. Туп кемнең чокырына төшә, шул бала туп тибүче итеп билгеләнә. Уен балалар арыганчы уйнала.

**Тоттым!**

*(Удмурт халык уены)*

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Араларыннан берсе санамыш ярдәмендә куучы билгели:

Биш сакал, алты сакал,
Җиденчесе – сакаллы бабай!

Соңгы сүздән соң балалар төрле якка йөгерешеп китәләр. Куучы бала уйнаучыларны куа башлый. Кулы белән кемгә дә булса кагылса: «Тоттым!» – ди. Тотылган бала уеннан чыга.

3–4 бала тотылганнан соң, барлык балалар түгәрәккә җыелалар һәм, санамыш ярдәмендә, яңа куучы сайлана.

**Кәҗә бәтие һәм этләр**

*(Удмурт халык уены)*

Санамыш ярдәмендә «кәҗә бәтие» сайлана. Калган балалар – «этләр». Бүлмәнең бер башында «яшелчә бакчасы» билгеләнә. Этләр бүлмәнең икенче башына барып басалар.

Кәҗә бәтие яшелчә бакчасында кәбестә ашап йөри. Аны этләр күреп алалар һәм, түбәндәнге сүзләрне әйтә-әйтә, акрын гына кәҗә бәтие янына таба киләләр:

Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй,
Кермә безнең бакчага!
Кермә безнең бакчага!
Кагылма кәбестәгә!

Этләр, бер-берсенең куллары белән тотынышып, кәҗә бәтиен камап алырга тырышалар. Кәҗә бәтие, этләрдән куркып, йөгерә башлый. Этләр, кулларын ычкындырмый гына, аны куалар. Әгәр тота алсалар, яңа кәҗә бәтие сайлана.

Уен шулай дәвам итә.

**Чәчәкләр**

*(Чуваш халык уены)*

Уенда так сандагы балалар катнаша. Балаларның яртысы түгәрәк ясап, чүгәләп утыралар. Һәрберсенең артында берәр бала басып тора. Ялгыз калган бала уенны алып баручы була. Ул түгәрәк тирәли әйләнеп йөри һәм басып торган уенчының берсеннән сорый:

– Синең ничә чәчәгең бар?

Уенчы берәр сан әйтә. Сораучы да, җавап бирүче дә капма-каршы якка йөгереп әйләнә башлыйлар. Алар әйтелгән сан кадәрчә (мәсәлән, биш тапкыр) әйләнеп чыгалар. Ялгыз утырган баланың артына иң беренче булып кайсы килеп баса һәм аңа куллары белән кагыла, шул җиңгән санала. Соңга калганы уенны алып баручы була.

Уен вакытында чүгәләгән балалар әйләнү санын бергәләп кычкырып әйтеп торалар.

**Диңгездә – ерткыч!**

*(Чуваш халык уены)*

Уенда унлап бала катнаша.

Уйнаучыларның берсе «ерткыч» итеп сайлана. Калган балалар – «балыклар». Уен өчен 2-3 м озынлыктагы бау кирәк була. Аның бер башын төйниләр һәм җиргә кагып кертелгән казыкка киертәләр. Ерткыч булып уйнаучы бала бауның икенче башын кулына ала һәм, тартылып, түгәрәк буйлап йөгереп китә. Бауның биеклеге ерткычның тезе турысында булырга тиеш. Бау балыклар янына якынлашканда, алар бау аша сикерергә тиешләр.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Бау аша сикереп өлгермәгән бала уеннан чыгарыла.
2. Ерткыч сигнал булгач кына йөгерә башлый.
3. Бау һәрвакыт тартылып торырга тиеш.

**Таралыгыз!**

*(Чуваш халык уены)*

Балалар, кулларын тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Нинди дә булса таныш җыр җырлап, түгәрәк буйлап йөриләр. Уенны алып баручы уртада басып тора. Кинәт ул: «Таралыгыз!» – ди. Уенчылар төрле якка йөгереп китәләр. Алып баручы аларны куа. Тотылган бала уенны алып баручы була.

**Балыклар**

*(Чуваш халык уены)*

Мәйданчыкта (идәндә) бер-берсеннән 8-10 м ераклыктагы ике кара-каршы сызык сызыла. Санамыш ярдәмендә «акула» сайлана. Калган балалар, ике төркемгә бүленеп, сызыклар артына кара-каршы басалар. Алар – «балыклар». Сигнал буенча уйнаучылар бер үк вакытта каршыдагы сызыкка таба йөгерәләр. Акула йөгерүче балыкларны тотарга (кулы белән кагылырга) тырыша. Һәр командадан ничә бала тотылганы санала. Иң күп балык тоттырган команда җиңелүче була.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Бер сызыктан икенче сызыкка сигнал булгач кына йөгерә башларга кирәк.

2. Кара-каршы йөгереп килгәндә уйнаучылар бер-берләренә бәрелергә, төрткәләшергә тиеш түгелләр.

## МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ

(6 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өчен уеннар)

### Йортсыз куян

Уйнаучылар арасыннан «аучы» һәм «йортсыз куян» билгеләнә. Калган балалар – «куяннар» – һәрберсе җиргә түгәрәк сызып, шул түгәрәк эченә кереп басалар.

Тәрбияченең сигналы буенча аучы йортсыз куянны куа башлый. Куян, теләсә кайсы түгәрәк эченә кереп, аучыдан кача ала. Бу вакытта түгәрәк эчендә басып торучы куян тиз генә йөгереп китәргә тиеш, чөнки хәзер инде ул йортсыз куян була, һәм аучы аны куа. Аучы куянны тота алса (кулы белән кагылса), алар рольләрен алмашалар, һәм уен дәвам итә.

### Аю

Уенчылар бер-берсенә карап, түгәрәкләнеп басалар. Бер уенчы, кулына ярты метр чамасындагы бау тотып, түгәрәк тышында йөри. Ул: «Аю китте, күрдеңме?» – дип, иптәшләренең берсенә бау белән сугып ала һәм үзе йөгерә. Сугылган кеше аны куып җитеп бауны алырга тиеш. Тота алмаса, ул уеннан чыга, һәм, киресенчә, тота алса, бауны алдырган кеше уеннан чыга. Уен түгәрәктә бер генә уенчы калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.

### Куышу

Бу уен балалар арасында киң таралган. Ул йөгереклек, җитезлек һәм уяулыкны үстерү өчен тышта, ачык һавада уйнала.

Уенны төркем белән дә, икешәр бала арасында да уйнарга мөмкин. Арадан бер бала, икенче баланың аркасына йомшак кына итеп: «Әбәк», – дип, тиз генә бәрә дә үзе бер якка кача. Сугылучы аны куып җитеп әбәкне кайтарырга тырыша.

### Ачкычлар

Мәйданчыкта (яисә идәндә) түгәрәкләр сызыла. Уйнаучылар шул түгәрәкләргә кереп басалар. Арадан берсе уенны алып баручы була. Ул уенчыларның берәрсе янына килеп сорый: «Ачкыч кайда?» Тегесе җавап бирә: «Алсудан сора, ул әйтер сиңа». Алар сөйләшкән арада калган балалар бер-берсе белән урыннарын алмашалар (бер түгәрәктән икенче түгәрәккә күчәләр). Алып баручы да тиз генә берәр буш түгәрәк эченә кереп өлгерергә тырыша. Түгәрәксез калган бала уенны алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.

### Сыерчык оялары

Мәйданчыкның (залның) төрле урыннарына акбур белән сызып түгәрәкләр ясала. Болар – «сыерчык оялары», һәр ояга бер пар «сыерчык» урнаша. Уйнаучылар саны так булырга тиеш. Шулай итеп, бер сыерчык һәрвакыт урынсыз кала.

Балалар-сыерчыклар мәйданчык буйлап йөгереп («очып») йөриләр. Тәрбияченең «Сыерчыклар очып кайттылар» дигән сигналыннан соң алар ояларына йөгерәләр.

Урынсыз калган бала оттырган булып санала. Барлык сыерчыклар да түгәрәкләргә парлашып урнашкач, тәрбияче: «Сыерчыклар очалар», – ди. Бу сүзләрдән соң уйнаучылар, түгәрәкләр эченнән чыгып, яңадан мәйданчык буйлап йөгереп йөри башлыйлар, һәм балалар теләсә кайсы түгәрәккә урнаша алалар.

**Төлке**

Уйнаучылар бер-берсеннән бер адым ара калдырып түгәрәккә тезеләләр.

Түгәрәктән читтә сызык белән «төлке өе» билгеләнә. Тәрбияче уйнаучыларга күзләрен йомарга куша. Балалар күзләрен йомалар, ә тәрбияче түгәрәкне әйләнеп чыга һәм балаларның берсенә кулы белән кагыла. Бу бала «хәйләкәр төлке» була. Аннан соң тәрбияче балаларга, күзләрен ачып, бер-берсенә игътибар белән карарга тәкъдим итә. Балалар үз араларында кем хәйләкәр төлке икәнлекне белергә тырышалар. Алар өч тапкыр, башта әкрен генә, ә аннан соң кычкырыбрак: «Хәйләкәр төлке, син кайда?» – дип сорыйлар һәм бер-берсенә карап торалар.

Өченче тапкыр сораганнан соң, хәйләкәр төлке тиз генә түгәрәк уртасына чыгып баса да, кулларын югарыга күтәреп: «Мин монда!» – ди һәм балаларны куа башлый.

Уен тәмамлангач, балаларны иң күп тоткан төлкене һәм үзләрен бер тапкыр да тоттырмаган уйнаучыларны билгеләп китәргә кирәк.

**Парлашып бас**

Уйнаучылар парлашып басалар һәм мәйданчык буйлап таралалар. Кара-каршы басып, бер-берләренең кулларыннан алалар – «кәрзиннәр» ясыйлар. Бер пар(ике бала) читтәрәк басып тора. Аларның берсе – әбәкче – икенче баланы куа башлый. Качучы бала әбәкчегә тоттырмаска тырышып, парлар арасыннан йөгерә һәм тиз генә берәр баланың исемен әйтә. Исеме әйтелгән бала йөгереп китәргә тиеш, ә качучы аның урынына баса. Әбәкче йөгереп киткән баланы куып тота алса, алар парлашып басалар: «кәрзин» ясыйлар.

Уен дәвам итә.

**Сикергечләр**

Сикергечләр белән төрле уеннар оештырырга була. Мәсәлән, «Кем тизрәк?» уены. Берничә бала сикергечләр тотып, бер-берләреннән ара калдырып, бер рәткә тезелеп басалар һәм тәрбияче сигналыннан соң алдан билгеләнгән урынга кадәр сикергечләр аша сикереп баралар.

«Кем озаграк?» уенында балалар бер урында сикереп торалар. Кем озаграк ялгышмыйча сикерә, шул җиңүче була. «Кем ничек булдыра?» уенында һәр уйнаучы сикергечләр белән хәрәкәтләрне үзе уйлап чыгара һ.б.

Әлеге уеннарны уйнау өчен алдан балаларны сикергечләр аша яхшы итеп, хәрәкәтләрне катлауландырып сикерергә өйрәтергә кирәк.

**Бакалар**

Мәйданчыкның (бүлмәнең) ике башында «сазлык» урыннары билгеләнә (зур түгәрәкләр сызыла яисә бау салына һ.б.). Уйнаучылар бер түгәрәкнең эченә урнашалар.

Алар – сазлыктагы «бакалар», куллары белән җиргә (идәнгә) таянып, чүгәлиләр. Араларыннан берәү «өлкән бака» итеп билгеләнә. Ул калган бакаларны каршы яктагы сазлыкка алып бара (чөнки ансында черкиләр, вак чебеннәр күбрәк). Өлкән бака алдан сикереп бара, калганнары аның артыннан ияреләр. Уен барышында өлкән бака кулларның торышын үзгәртә – куллар тезләрдә, билдә, вак-вак атлап яисә зур адымнар белән сикерә; каршылыклар (мәсәлән, идәнгә салынган таяклар) аша сикереп үтә; идәндә торган кубларга, такталарга сикереп менә; әйберләр арасыннан үтеп йөри һ.б. Барлык бакалар да әлеге хәрәкәтләрне кабатлыйлар.

Икенче сазлыкка килеп җиткәч, бакалар: «Ква-ква», – дип кычкыралар.

Уенны кабатлаганда, өлкән бака итеп икенче бала сайлана.

**Чикерткәләр**

Балалар санамыш ярдәмендә «чикерткә тотучы» сайлап куялар. Калган балалар «чикерткәләр» була. Чикерткә тотучы сыңар аягында уртада басып тора. Калганнары да сынар аякта аның тирәсенә тезеләләр. Чикерткә тотучы ничек тә булса, тыраклап килеп, аларның аягына басарга тырыша. Ә чикерткәләр бастырмаска тырышып читкә тайпылалар. Әгәр тотучы берәрсенең аягына баса алса, чикерткә тотылган санала. Ул уеннан чыга. Уен ахырына кадәр аягына бастырмаган чикерткә җиңүче була.

**Песи һәм чыпчыклар**

Идәндә (яисә уен мәйданчыгында җирдә) зур түгәрәк сызыла. Уйнаучы балалар – «чыпчыклар» – шул түгәрәкнең тышкы ягына тезелеп басалар. Арадан берсе санамыш ярдәмендә «песи» итеп билгеләнә, ул түгәрәк уртасына баса. Сигнал буенча, балалар сикергәләп, түгәрәк эченә кереп-чыгып йөриләр. Песи бу вакытта (балалар түгәрәк эчендә вакытта) кемне дә булса тотарга тырыша. Тотылган бала песи була, ә песи чыпчык булып уенны дәвам итә.

Уенны бер аякта сикереп (түгәрәк эченә кереп-чыгып) катлауландырырга мөмкин.

**Әтәчләр**

Балалар парлашып, бер-берләреннән 3-5 адым ара калдырып басалар. Алар – «әтәчләр», бер аякта сикереп, җилкәләре белән бер-берсен төрткәлиләр. (Куллар белән төрткәләргә ярамый.) Уен бер аякта гына сикереп уйнала. Тигезлекне югалтып, ялгыш ике аягына баскан бала уеннан чыгарыла.

*Искәрмә*

Уен башланганчы балалар кулларын ничек куярга тиешлеге турында үзара килешәләр (билдә, артта, күкрәк алдында чалыштырып яисә тездән бөгелгән аякны тотарга да мөмкин һ.б.).

**Күчмә кошлар**

Балалар мәйданчыкның (бүлмәнең) бер башында таралашып басып торалар. Алар – «кошлар». Мәйданчыкның икенче башында – гимнастика баскычы.

Тәрбияченең «Кошлар оча!» дигән сигналы буенча кошлар канатларын җилпеп очып китәләр (балалар, кулларын як-якка җәеп, мәйданчыкта йөгереп йөриләр). «Давыл!» дигән сигнал булуга кошлар гимнастика баскычына куналар, агачлар арасына качалар. Тәрбияче: «Давыл тынды», – ди, һәм кошлар әкрен генә агачлардан, гимнастика баскычыннан төшәләр һәм тагын оча башлыйлар.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Гимнастика баскычыннан төшкәндә, һәр аратага да басып төшәргә кирәк. Сикереп төшү рөхсәт ителми.

2. Тәрбияче гимнастика баскычы янында басып торырга һәм кирәк чагында балаларга ярдәм итәргә тиеш.

3. Уенны оештыру өчен гимнастика баскычы булмаса, балалар эскәмияләрдән яки бүтән биекләрдән файдалана алалар.

**Кыңгырау шалтыратам**

Уен спорт залында үткәрелә. Гимнастика баскычыннан 5-6 адым ераклыкта сызык сызыла. Балалар, йөзләре белән гимнастика баскычына карап, 3-4 колоннага тезелеп басалар. Һәр колонна каршына гимнастика баскычына бер үк биеклектә кечкенә кыңгыраулар бәйләп куела.

Тәрбияченең «Бер, ике, өч, йөгер!» дигән сигналыннан соң колонналарда беренче булып торучы балалар гимнастика баскычы янына йөгереп киләләр дә үрмәләп югарыга менәләр һәм кыңгырауларны (һәркем үз кыңгыравын) шалтыраталар. Аннан соң алар җайлап кына баскычтан төшәләр һәм һәрберсе үз колоннасының артына барып баса. Кыңгырауны беренче булып шалтыраткан бала билгеләп үтелә. Уенны колоннада икенче (өченче, дүртенче һ.б.) булып торучы балалар дәвам итә. Кыңгырауны беренче булып шалтыраткан балалар саны күбрәк булган колонна җиңгән булып санала.

**Кем беренче?**

Мәйдан уртасына, бер-берсеннән 1-2 адым ара калдырып, кыршаулар салына.

Мәйданчыкның бер башында кыршаулар турысына урындыклар куела һәм аларның һәрберсенә берәр флагчык салына. Мәйданчыкның каршы ягында билгеләнгән сызык артына 4-5 колонна булып балалар баса (һәр төркем бер кыршау турысында басып тора).

Тәрбияченең «Башладык!» дигән сигналы буенча колоннада беренче булып басып торучы балалар кыршаулар янына йөгерәләр, чүгәләп, кыршауны вертикаль рәвештә бастырып тоталар (бер ягы җиргә куела). Шул арада колоннада икенче булып басып торган балалар үз кыршаулары янына йөгереп киләләр, кыршау аша мүкәләп чыгып, флагка таба йөгерәләр, флагларны баш өстенә күтәреп, кире үз урынына куялар. Аннары алар кыршауны тотып торучы балаларны алыштыралар, тегеләре исә үз колонналарының ахырына барып баса.

Уенны колоннаның башында басып торучы дәвам итә

Кайсы команда беренче булып биремне үти, шул җиңүче була.

**Тупны тапшыр**

Уйнаучылар, бер-берсеннән бер адым ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр. Тәрбияче аларның берсенә диаметры 6-8 см лы туп тоттыра. Тәрбиясенең «Башла!» дигән сүзе буенча, балалар тупны бер юнәлештә, бер-берсенә кулдан кулга тапшыра башлыйлар. Бу вакытта барлык уйнаучылар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Бер, ике, өч! Тубым, тизрәк күч!
Дүрт, биш, алты! Туп кемдә калды?
Җиде, сигез, тугыз! Туп миндә калды.

«Миндә» дигән сүзне әйткәндә туп кемдә булса, шул бала түгәрәк уртасына чыга һәм: «Бер, ике, өч, йөгер!» – ди. Бу сүзләрдән соң барлык балалар йөгереп таралалар. Уртада басып торучы, урыныннан кузгалмыйча, аларга туп ыргыта. Туп тигән бала вакытлыча уеннан чыга.

Тәрбиясенең «Тизрәк түгәрәккә йөгер!» дигән сүзләреннән соң балалар тагын түгәрәккә тезеләләр, һәм уен яңадан башлана.

Уенны кабатлаганда, үзләренә туп тигән балалар да түгәрәккә басалар. Бу юлы балалар тупны бер-берсенә икенче юнәлештә тапшыралар.

**Иң төз атучы**

Командалар алдында старт сызыгы (ара 1 м) билгеләнә. Старт сызыгыннан 3,5 метр ара калдырып, һәр команда каршысына идәнгә кыршау яткырып куела. Сигнал буенча командада беренче торучылар ком тутырылган кечкенә капчыкларны (яки мамыктан эшләнгән «кар йомарламнарын») өчәр тапкыр ыргыталар да команданың артына барып басалар. Чираттагы уенчылар шуны кабатлыйлар. Кыршауга капчыкларны күбрәк төшерә алган команда җиңүче була.

**Куянкай**

Залда зур түгәрәк сызыла. Уйнаучылардан берәү «куян» итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасына баса. Калган балалар түгәрәк тышында басып торалар. Алар кара-каршы бер-берләренә туп ыргытышалар (баланың исеме әйтелә), шул ук вакытта тупны куянга тидерергә тырышалар. Куян, тупны тидермәскә тырышып, туптан качып, түгәрәк эчендә йөгереп йөри. Тупны куянга тидерә алган бала куян була, һәм ул түгәрәк уртасына баса.

*Искәрмә*

Куян, теләге булса, тупны тотып ала ала. Бу очракта тупны ыргыткан бала түгәрәк уртасына кереп баса һәм куян ролен башкара.

**Тупны биеккәрәк ыргыт**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы билгеләнә. Ул, туп тотып, уртага баса һәм туп белән төрле күнегүләр эшли. Бу вакытта балалар бишкә кадәр санargyйлар. «Биш» дигәндә төрлесе төрле якка йөгереп китәләр. Туплы бала: «Тукта!» – дип кычкыра, балалар туктап калырга тиешләр. Туплы бала, урыныннан кузгалмыйча, үзенә якынрак торган балага тупны ыргытып тидерергә тырыша. Туп тигән бала уенны алып баручы була. Әгәр дә алып баручы тупны берәүгә дә тидерә алмаса, ул тупны куып тотарга тиеш, ә балалар аннан тагын да ераккарак йөгерергә тырышалар. «Тукта!» дигән сигналга

барлык уенчылар туктап калалар, алып баручы кабат тупны кемгә дә булса тидерергә тырыша. Уен шулай дәвам итә.

Уенның кагыйдәсе

* Әгәр дә кем дә булса «Тукта!» сигналыннан соң да хәрәкәтләнүен дәвам итә икән, ул алып баручыга таба бер адым ара якынаеп басарга тиеш.

**Чыпчык оча**

Уен стена буенда уйнала. Стенадан 1,5 м ара калдырып, уенны алып баручы өчен сызык сызыла. Алып баручыдан 3 м ераклыкта – уйнаучылар сызыгы. Уйнаучылар сызык кырыенда стенага артлары белән басып торалар. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә. Ул, үз сызыгына басып, теннис тубы яисә кечкенә резина тупны көч белән стенага бәрә. Туп, стенага бәрелеп, кире уйнаучылар сызыгы артына төшәрлек булырга тиеш. Алып баручы тупны ыргытканда: «Чыпчык оча!» – ди. Шул сүзләрне ишетүгә, уйнаучылар тиз генә стенага таба борылалар һәм очып килүче тупны җиргә төшкәнче тотып калырга тырышалар. Тупны тотып алган бала уенны алып баручы була.

**Штандер**

Уйнаучылар, бер-берсеннән бер адым ара калдырып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына. туп тотып, уенны алып баручы баса. Ул, тупны биеккә-югарыга ыргытып, бер уенчының исемен әйтә. Исеме әйтелгән бала, тиз генә уртага кереп, тупны тотып алып өлгерергә тырыша. Алып баручы аның урынына йөгерә. Тупны туры итеп, югарырак ыргытырга тырышырга кирәк. Әгәр дә исеме әйтелгән бала тупны тотып ала алса, ул уртага баса һәм бер уйнаучының исемен әйтеп яңадан тупны биеккә чөя. Тупны тота алмаган очракта, барлык уйнаучылар төрле якка йөгереп китәләр, ә тупны тотучы, аны җирдән тиз генә күтәреп алып, түгәрәкнең уртасына йөгереп килә һәм: «Штандер!» – дип кычкыра. Бу сүзне ишетүгә, барлык уйнаучылар туктарга һәм урыннарында басып калырга тиешләр. Алып баручы тупны берәр уйнаучыга тидерергә тырыша. Тидерә алган очракта, уйнаучылар туп тигән баладан ераккарак йөгереп китәргә тырышалар, ә тегесе, үз чиратында, тупны җирдән күтәреп: «Штандер!»- дип кычкыра һәм тупны кайсы да булса балага ыргыта. Уен шулай дәвам итә. Тупны тидерә алмаган очракта, бала вакытлыча уеннан чыгып тора.

**Көнгерә**

Балалар, ике командага бүленеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Командаларда беренче булып басып торган балалар, зур тупны ике тез арасына кыстырып, төшермичә, билгеләнгән урынга кадәр сикереп баралар. Кире килгәндә тупны кулга тотып йөгерәләр. Башка балалар да шуны кабатлыйлар. Биремне үтәп, иң беренче булып тезелгән команда җиңүче була.

**Туплы эстафета**

Ике командага бүленгәч, балалар, аякларын җилкә киңлегендә куеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Колоннада беренче булып басып торучыларга (капитан) туплар (диаметры 15-20 мм) бирелә.

Тәрбияченең «Күтәрдек!» дигән сигналы буенча, балалар кулларын өскә күтәрәләр. Туплы бала үзенең артында басып торучы балага баш аркылы тупны бирә, ә тегесе – үзенең артындагыга. Уен шулай дәвам итә. Соңгы басып торучы балага туп килеп җиткәч, ул йөгереп килеп, капитанның алдына баса һәм туп бирү дәвам итә.

Ярышның икенче варианты. Балалар тупны бер-берләренә аяклар арасыннан бирәләр.

**Кем тизрәк?**

Биш бала старт сызыгына баса. Алардан биш-алты метр читтә биш туп куела. (Башка төрле предметлар куярга да ярый.) Балалар, тәрбияче сигналы буенча, туплар янына йөгереп киләләр дә, тупны кулларына алып, югары күтәрәләр. Тупны беренче булып күтәреп алган бала җиңүче булып исәпләнә. Старт сызыгына икенче балалар чакырыла.

Уен шулай дәвам итә.

**Матур шарлар**

Балалар, парлашып, кара-каршы ике төркемгә бүленеп басалар. Аларга төсле һава шарлары таратыла. Тәрбияче сигнал бирү белән, уенчылар, шарны кул белән тотмыйча гына (шар ике бала арасында кыстырылган), билгеләнгән урынга кадәр йөгерәләр. Уен шулай дәвам итә. Кайсы төркем беренче булып биремне башкарып чыга, шул җиңүче була.

**Поезд**

Балалар командага бүленәләр һәм старт сызыгы артына бер-бер артлы тезелеп басалар. Алар – «вагоннар». Алда команда капитаннары – «локомотивлар». Тәрбияче сигнал биргәч, капитаннар алдан билгеләнгән урынга (флагка) таба йөгерәләр һәм, аны әйләнеп узып, кире командаларына киләләр. Капитаннарга икенче булып басып торган балалар – вагоннар ябышалар (нык итеп капитаннарның биленнән тоталар) һәм икәүләшеп йөгерәләр. Уен барлык вагоннар да беркетелеп беткәнче дәвам итә. Старт сызыгына беренче булып килеп җитүче поезд җиңүче була.

**Кыргаяклар ярышы**

Уйнаучылар 2-3 командага бүленәләр (һәр командада 8-10 бала). Һәр командага озын бау бирелә. Балалар бауның ике ягына басалар, куллары белән (уң һәм сул) бауга тотыналар. Сигнал булгач, бауга тотынган килеш, билгеләнгән урынга (ара 30-40 м) таба йөгерәләр. Йөгергән вакытта кулларны баудан ычкындырырга ярамый.

Кулларны ычкындырмыйча, финишка беренче булып килеп җиткән команда җиңүче була.

# ХАЛЫК УЕННАРЫ

## Чүлмәк сатыш

*(Татар халык уены)*

Балалар җиргә «чүлмәк» булып түгәрәкләнеп утыралар. Артларына һәрберсенең «хуҗа»сы баса.

Берәү чүлмәк алучы була һәм, хуҗа янына килеп:

– Чүлмәк сатасыңмы? – дип сорый.

– Сатам.

– Күпмегә сатасың?

– Өчкә, – дисә, өч мәртәбә (күпме әйтсә, шулкадәр) кул сугышалар. Сатучы белән алучы ничәгә килешсәләр, түгәрәк тышыннан кара-каршы шулчаклы йөгерәләр. Кем алдан килсә, чүлмәк шуныкы була, аның артына баса. Артта калучы чүлмәк алучыга әйләнә.

Уен шулай дәвам итә.

## Күз бәйләш

*(Татар халык уены)*

Балалар түгәрәктә утырып яки басып торалар. Түгәрәк уртасында ике уенны алып баручы басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр.

Кулына кыңгырау тоткан бала, «Йөгер!» дигән сигналны ишетүгә, түгәрәк буйлап йөгереп китә һәм кыңгырауны шалтырата башлый, ә күзе бәйләнгән бала аны тотарга тырыша. Ул кыңгырау тотып йөгерүчене тоткач, уен тәмамлана. Аннан соң балалар үз араларыннан уенны алып баручы итеп бүтән ике баланы сайлыйлар.

Уен яңадан башлана.

## Төенчек

*(Татар халык уены)*

Уен ачык һавада уйнала. Балалар бер-берләреннән ике адым чамасы ара калдырып, түгәрәк ясап тезләнеп утыралар. Бер бала көтүче итеп билгеләнә. Ул кулындагы төенчеген (туп булырга да мөмкин) түгәрәктәге бер иптәшенә бирә дә 2-3 адым артка китә. Шулвакыт түгәрәктәгеләр төенчекне кулдан-кулга җибәрәләр. Ә көтүче, түгәрәк буенча йөгереп, төенчекне кулга төшерергә тырыша. Ул төенчекне кем кулыннан тартып алса, шул кеше көтүче булып, уен яңадан башлана.

Уенга күрсәтмәләр

* Төенчекне бары тик уңда я сулда утыручыга гына бирергә ярый, кеше аша ыргыту тыела.

* Төенчекне йөртү юнәлеше үзгәреп торырга мөмкин.

**Бүкән**

*(Татар халык уены)*

Балалар, бер-берләре белән парлашып, түгәрәк ясыйлар. Берәүләре алга, икенчеләре алар артына баса. Алдагы балалар чүгәлиләр, алар «бүкән» булалар, ә арттa басып торучылар – «бүкәнне саклаучылар». Бер бала так кала. Ул, «сакчыларның» берсе янына килеп, сүз башлый: «Җиз бүкән сатлык микән? Сатып бирмәссез микән?» Тегесе: «Җиз бүкәнемне сатам. Узышып карыйк алдан» – ди. Алар түгәрәк буйлап икесе ике якка йөгереп китәләр. Кем беренче булып килеп җитә, бүкән аныкы була. Так калган бала икенче сакчы янына барып сөйләшә башлый. Уен шулай дәвам итә.

**Почмак алыш**

*(Татар халык уены)*

Балалар мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Алар – «әбиләр». Бер бала, әбиләр янына килеп, мунча сорап йөри:

– Әби, мунча бир әле?

– Мунчам буш түгел әле.

– Әби, мунча бир әле?

– Ташы төшкән.

– Әби, мунча бир әле?

– Мунча салырга агач юк. (Шулай итеп, төрле сәбәпләр әйтелә.)

Аннары тиз генә: «Һоп, һоп!» – дип, берничә мәртәбә кычкыралар. Шушы вакытта балалар урыннарын алмаштыралар. Мунча сораучы бала шушы арада берәрсенең урынын алып өлгерергә тиеш. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.

**Самавыр**

*(Татар халык уены)*

Уйнаучылар арасыннан «самавыр» һәм «әби» сайланып куела. Калганнары читкәрәк тезелешеп утыралар. Әби балаларга чәй эчә торган тәм-том исемнәре әйтеп чыга, аларны «самавыр» ишетмәскә тиеш. Әби, «самавыр»ның колагын тотып: «Чәй эчәргә килә-килә... шикәр!» – ди.

«Шикәр», акрын гына килеп, самавырның аркасына төртә дә үз урынына барып утыра. Самавыр карый: балаларның барысы да баш бармакларын өскә караткан. Самавыр кем төрткәнен әйтергә тиеш. Әгәр белсә, тоткан бала «самавыр» була. Белмәсә, «шикәр»гә икенче исем кушылып, уен дәвам итә. Өч мәртәбә әйтә алмаган «самавыр»га җәза бирелә.

**Без, без, без идек...**

*(татар халык уены)*

Берничә бала түгәрәкләнеп утыралар. Алар, бер кулның баш бармагын өскә күтәртеп, кулларын йодрыклыйлар. Бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куялар һәм, кулларын бергәләп күтәреп-төшереп, түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без-без, без идек,
Без унике кыз идек;
Базга төштек – май ашадык,
Келәткә кердек – бал ашадык;
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык.
Кап та коп, Якуп,
Авызыңны ачма, мин ачмам! –

диләр дә барысы да берьюлы авызларын йомалар.

Моннан соң уенчылар берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш.

Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кыланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем иң элек авызын ачса, йә көлеп җибәрсә, шул балага җәза бирелә.

Уен тагын яңадан башлана.

## Аксак төлке

*(Татар халык уены)*

Санамыш ярдәмендә балаларның берсе – «аксак төлке», икенчесе «өй хуҗасы» – «аю» итеп билгеләнә. Башка балалар «тавыклар» булып, зур бер түгәрәк эченә кереп тулалар. Аксак төлке, «өн»еннән чыгып, аксаклый-аксаклый сикергәләп (бер аягын күтәреп), өй хуҗасы («аю») янына килә. туктый. Алар арасында мондый сөйләшү була:

– Төлке, Төлке, Түләнтәй, төнлә кая барасың?
– Мамай улы Бикчәнтәй, әбиемә барамын.
– Әбиеңдә ниең бар?
– Мич артында туным бар.
– Туның янса, нишләрсең?
– Суга илтеп салырмын.
– Туның акса, нишләрсең?
– Үкереп елап калырмын.
– Төлке, Төлке, Түләнтәй, тунсыз ничек йөрерсең?
– Мамай улы Бикчәнтәй, йөргән чакта күрерсең.

Шулай әйтешкәннән соң, аю тынычланып йокларга ята. Төлке, бер аякта сикергәләп, «тавыклар оясы»на керә дә аларны куа башлый. Куып җиткәненә кулы белән кагыла. Әлеге бала Аксак төлке була.

*Уенга күрсәтмә*

* Аксак төлке, ялгышып, икенче аягы белән дә җиргә басса, хуҗа күреп, аның үзен куа башлый. Әгәр төлке үз оясына җиткәнче тотылса, ул яңадан төлке булып уйнарга тиеш була.

## Зур туп

*(Рус халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртадагы баланың аягы янында – зур туп. Ул аягы белән тупны түгәрәктән тибеп чыгарырга тырыша. Тупны уздырган уенчы түгәрәктән

читкә чыга, ә уртада уйнаган бала аның урынына баса. Бу юлы түгәрәктәге балалар уртада торучы балага барысы да аркалары белән борылып басалар һәм тупны түгәрәк эченә уздырмаска тырышалар. Читтә калган бала исә тупны эчкә уздырырга тиеш.

Уен вакытында балалар тупны бер генә тапкыр да кулларына алмаска тиешләр. Әгәр кем дә булса тупны кулына ялгыш ала икән, ул вакытта уен туктатыла һәм, түгәрәк уртасына яңа уенчы билгеләнеп, уен яңадан башлана.

**Буш урын**

*(Рус халык уены)*

Йөгереклек һәм җитезлекне булдыру өчен булган бу уен җәй көне тышта, кышын киң залларда ир һәм кыз балалар арасында уйнала.

Санамыш ярдәмендә берәүне көтүче итәләр дә, калган балалар бер түгәрәк ясап, бер-берсенең кулларына тотынышып торалар. Көтүче түгәрәк тышында йөри һәм бер баланың аркасына суга да түгәрәк буйлап йөгереп китә. Сугылган бала, урыныннан чыгып, аңар каршы яктан йөгерә. Алдан әйләнеп килеп җиткәне шул буш урынны ала. Урынсыз калганы көтүче була да, уен дәвам итә.

**Качышлы**

*(Рус халык уены)*

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә. Аның кулында тылсымлы таяк. Ул, стена буена (яисә агач янына) басып, күзләрен йома һәм 20 гә кадәр саный. Бу арада уйнаучылар, як-якка таралып, качып өлгерергә тиешләр.

Уенны алып баручы, санап бетергәннән соң: «Таяк тылсымлы микән, кемнәрне табар икән?» – дип, таягы белән сугып ала һәм, таякны калдырып, качучыларны эзләп китә. Әгәр ул кемне дә булса күреп алса (тапса), таяк янына йөгереп килә, һәм күргән баланың исемен әйтеп, таяк белән стенага сугып ала. «Тылсымлы таяк Айгөлне тапты», – ди.

Һәр уенчы, уңайлы вакыт табып (алып баручы күрмәгәндә), качкан урыныннан чыга ала һәм таяк янына йөгереп килеп: «Тылсымлы таяк, мине якла», – ди, таяк белән стенага суга.

Барлык балалар да табылып беткәч, башка алып баручы сайлана, һәм уен кабатлана.

**Лапта**

*(Рус халык уены)*

Уен урамда малайлар һәм кызлар арасында уйнала. Уйнаучылар санамыш ярдәмендә өч төркемгә бүленәләр. Һәр төркем, бер-берсеннән 10 метрлап ара калдырып, тезелеп баса. Уен шарты буенча ике як та, чиратлашып, уртадагыларга туп белән бәрә. Туп тигән кеше отылган була, уеннан чыга. Тупны, уенчыга тигәнче, һавада очканда тота алган кеше очко ала. Шулай итеп, иптәшләренең берәрсен уенга яңадан кертә. Уен уртадагылар чыгып беткәнче дәвам итә. Уенны кабат башлаганда, төркемнәр урыннарын алмашалар.

## Җәнлекләр өйрәтүче

*(Рус халык уены)*

Бүлмә буйлап, идәнгә «агач төпләре» (кечкенә келәмнәр яки катыргыдан ясалган түгәрәкләр) тезеп куела. Агач төпләренең саны балалар санына караганда бергә азрак булырга тиеш. Төп эләкмәгән бала – «җәнлекләр өйрәтүче», барлык башка балалар «җәнлекләр» булалар. Уен башланганчы, балалар үзләре кайсы да булса бер җәнлекне сайлыйлар: кемдер – «куян», кемдер «бүре» һ.б. була. Җәнлекләр агач төпләренә утыралар, өйрәтүче алар тирәсендә йөри һәм берәр җәнлекнең исемен атый. Ул бер-бер артлы берничә җәнлекнең исемен атарга мөмкин. Җәнлекләр аның артыннан ияреләр. Җәнлекләр өйрәтүче: «Игътибар, аучылар!» – дию белән, җәнлекләр дә, өйрәтүче дә агач төпләренә утырып калырга тырышалар. Кемгә урын калмый, шул өйрәтүче була, һәм уен дәвам итә.

## Балык тоту

*(Рус халык уены)*

Уйнаучылар түгәрәкләнеп басалар. Уртада уенны алып баручы – «балык тотучы». Аның кулында бау (сикергеч тә ярый). Алып баручы, иелеп, җирдән якын гына арада бауны үз тирәли әйләндерә башлый. Башка балаларның («балыклар»ның) максаты – бауга тими генә, аның аша сикереп чыгу. Әгәр дә ул аягы белән бауга тия яки баса икән, тотылган булып исәпләнә.

Уенны ике вариантта дәвам итәргә мөмкин.

1 нче вариант. Балык тотучы алышынмый. Кармакка эләккән балыклар уеннан чыга. Уен түгәрәктә иң җитез 2-3 уенчы калганчы дәвам итә.

2 нче вариант. Балык тотучы алмашына. Кармакка эләккән балык әйләнә уртасына керә һәм ул «балык тотучы» була. Ә элеккеге балык тотучы балык була.

Баштарак балык тотучы ролен тәрбияче дә башкарырга мөмкин.

## Әбәк-күбәк

*(Башкорт халык уены)*

Балалар арасыннан «көтүче» сайлана. Калганнар бер-бер артлы тезелеп басалар. Көтүче үз алдындагы баланың кулына кагыла (әкрен генә суга) һәм болай ди:

Әбәк-күбәк, алтын савыт,  
Куып тотсаң – алтын кашык,  
Әгәр тота алмасаң,  
Эзеңә җитмеш көрәк көл.

Бу сүзләрне әйтеп бетергәннән соң, ул йөгереп китә. Кулына кагылган бала аның артыннан куа. Әгәр көтүче, йөгереп барып колоннаның артындагы бала артына басарга өлгерсә, куучы җиңелгән санала һәм ул көтүче була. Әгәр өлгермәсә, уен нәкъ шул тәртиптә кабатлана. Уен балалар арыганчы дәвам итә.

**Энә белән җеп**

*(Башкорт халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп тезеләләр. Бер бала – «энә», икенчесе «җеп» итеп билгеләнә. Тәрбиячененң сигналы буенча, энә балалар арасыннан төрлечә йөгереп йөри, җеп аның артыннан иярә, куып җитәргә тели. Энә җепне бутарга, ә җеп, киресенчә, энәдән калышмаска тырыша. Җеп энәне куып тотканнан соң, рольләр алмашына: җеп булып уйнаучы энә була.

Бу уен игътибарлылыкка, тизлеккә өйрәтә.

**Йөзек салыш**

*(Башкорт халык уены)*

Балалар, бер рәт булып тезелеп, урындыкларга утыралар. Уйнаучылар арасыннан «үгез» билгеләнә. Ул башка балалардан аерым, аларга каршы урындыкта утыра. Санамыш ярдәмендә алып баручы билгеләнә.

Алып баручы куш учына кечерәк бер әйбер (йөзек, кечкенә таш яки вак акча) тота һәм, тезелешеп утырган балаларның һәрберсенең учларына кагылып, йөзек салган кебек хәрәкәт ясый, башкаларга белдерми генә берсенең учына йөзекне сала. Үгез алып баручының хәрәкәтләрен игътибар белән күзәтеп утыра. Алып баручы аннан сорый:

– Үгез, әйт әле, йөзек кем кулында ?

Һәр бала йөзекне үзендә дип күрсәтергә тырыша. Үгез бер баланың исемен атый. Әгәр йөзек чыннан да аның кулында булса, үгез әлеге уйнаучы урынына утыра. Йөзек табылган бала алып баручы итеп билгеләнә, ә элеккеге алып баручы үгез була. Йөзекнең хуҗасы дөрес аталмаган очракта, уен элеккечә дәвам итә. Әгәр берничә тапкыр уйнаганнан соң да үгез йөзек хуҗасын атый алмаса, аңа җәза бирелә (җырларга, биергә, шигырь сөйләргә һ.б.).

Шул рәвештә уенны берничә тапкыр кабатларга мөмкин.

**Исемен әйт!**

*(Башкорт халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртадагы бер баланың күзләрен яулык (тасма) белән бәйлиләр. Аның каршысына икенче бер баланы бастыралар, ә калган балалар болай диләр:

Бик яхшылап уйла әле,
Кем ул каршыңда тора?
Белә алсаң, исемен әйт,
Киемен тотып кара.

Күзләре бәйләнгән уенчы, кулы белән әлеге баланың киемнәрен, гәүдәсен капшап караганнан соң, аның исемен атарга тиеш. Әгәр дә ул аның исемен әйтә алса, исеме дөрес аталган шул баланың күзләрен бәйлиләр. Әгәр исем дөрес аталмаса, күзе бәйләнгән бала каршына икенче бер баланы китереп бастыралар. Уен берәр баланың исеме дөрес аталганчы дәвам итә. Уенны кабатлап уйнаганда, күз бәйләр өчен, икенче бала сайлана.

**Курай**

*(Башкорт халык уены)*

Балалар, кулларын кулга тотынышып, түгәрәккә басалар. Бер бала «курайчы» итеп сайлана. Ул түгәрәк уртасына баса. Уйнаучылар салмак көй астында (башкорт халык көе) түгәрәктә йөриләр. Курайчы, кураенда «уйный-уйный», аларга каршы якка бара. Көй тәмамланугa, балалар туктап калалар һәм йөзләре белән курайчыга таба борылалар. Түбәндәге шигырь юлларын әйтәләр:

Курай моңын ишеттек,
Түгәрәккә җыелдык.
Һей, һей, һей!
Курай көен тыңлый-тыңлый
Төрле якка сибелдек.

Балалар мәйданчык буйлап таралалар һәм, туктап, башкорт халык бию көенә төрле хәрәкәтләр ясыйлар. Көй туктый. Балалар: «Әй, курайчы, күңеллерәк син уйна. Иң яхшы биючене сайла!» –диләр. Курайчы биючеләр арасыннан бер баланы сайлый. Сайланган уенчы курайчы була.

Уен шулай дәва итә.

Уенның кагыйдәсе

* Шигырь тәмамланмыйча таралып китәргә ярамый.

**Әтәчләр сугышы**

*(Мари халык уены)*

Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм, берникадәр ара калдырып, кара-каршы ике рәткә тезеләләр. Алар – «әтәчләр». Һәр уенчы, бер аягын тездән бөгеп, арттан ике кулы белән тота. Уенны алып баручының сигналы булуга әтәчләр, сикерә-сикерә, бер-берләренә якын киләләр, җилкәләре белән бер-берсен төрткәлиләр. Әгәр кайсы да булса уенчы көндәшенең тигезлеген югалттыра алса (ике аягына бастыра алса), аңа очко бирелә. Ул уеннан чыгарыла. Иң күп очко җыйган команда җиңүче була.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Уйнаучыларның саны тигез булырга тиеш.
2. Аякны ике кул белән генә тотарга ярый.
3. Куллар белән төрткәләргә ярамый.

**Тилгән һәм казлар**

*(Мари халык уены)*

Санамыш ярдәмендә «ана каз», «ата каз», «тилгән» сайланып куела. Калган балалар – «каз бәбкәләре».

Балалар бер-бер артлы тезелеп басалар: алда – ата каз, уртада – каз бәбкәләре, артта – ана каз. Казлар, чүгәләп, үлән ашый-ашый, бүлмә буйлап йөриләр. Сигнал булуга торып басалар, берсе-берсенең билләренә тотынышалар. Качып торган җиреннән тилгән килеп чыга, каз бәбкәләрен тотмакчы була. Ата каз бәбкәләрне саклый, тоттырмаска тырыша. Тилгән кайсы да булса бәбкәне тота алса, тотылган бала уеннан чыга. Берничә

бәбкә тотканнан соң, уен туктатыла. Тилгән бер бәбкә дә тота алмаган очракта, ул ял итәргә утыра. Бу вакытта каз бәбкәләре яшел үлән чүплиләр, утырган тилгәнгә дә үлән ыргыталар:

Менә сиңа, Тилгән,
Яшел, сусыл үлән.
Без синнән курыкмыйбыз,
Беребезне дә тоттырмыйбыз.

Уен яңадан башлана.

**Кем тизрәк?**

*(Мари халык уены)*

Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә. Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы түгәрәк тышында кала. Сигнал булуга, алып баручы: «Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун!» – дип, саный-саный, һәр баланың җилкәсенә кагылып бара. «Ун!» дигәндә кемгә кагыла, шул уенчы белән алар икесе ике якка йөгереп китәләр. Буш урынга кем беренче булып йөгереп килеп җитә, ул шул урынга баса. Урынсыз калган бала уенны алып баручы була.

*Уенның кагыйдәсе*

* «Ун!» дигәннән соң гына йөгерә башларга кирәк.

**Тупны тидер!**

*(Мордва халык уены)*

Җирдә зур түгәрәк сызыла. Уйнаучылар ике командага бүленәләр. Команданың берсе – түгәрәк эченә, икенчесе түгәрәкнең тышына урнаша. Түгәрәкнең тышында басып торучы балалар тигез итеп бүленәләр һәм, түгәрәк эчендәге балаларга тидерергә тырышып, туп ыргыталар. Әгәр дә түгәрәк эчендә басып торучы балаларның берәрсе тупны тотып ала икән, ул аны тышта басып торучыларга таба ыргыта. Әгәр дә ул тупны кемгә дә булса тидерә алса, аңа бер очко бирелә; тидерә алмаган очтакта, ул уеннан чыга. Түгәрәк тышында басып торучыларның барсына да туп тидерелгәннән соң, уенчылар урыннары белән алышыналар.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Тупны һавада вакытта тотарга кирәк. Җиргә бәрелгән туп саналмый.
2. Тупны тотып ала һәм кемгә дә булса тидерә алган бала (уртадагы), түгәрәктә кала.
3.Туп тигән балалар уеннан чыга бара

**Ачкычлар**

*(Мордва халык уены)*

Бу уенда биш уйнаучы катнаша. Җирдә (идәндә) квадрат сызыла. Һәр почмакка бер уйнаучы утыра. Бишенче уйнаучы – уенны алып баручы – уртага баса. Ул бер почмактагы бала янына килә һәм сорый: «Абый (апа), ачкыч синдәме?». Тегесе, күршесенә күрсәтеп: «Күрше абыйдан (ападан) сора», – ди. Алып баручы шулай итеп икенче, өченче уенчыдан сорый. Дүртенче почмактагы бала: «Уртадан эзлә», – ди. Алып баручы уртага

килгән арада почмактагылар тиз генә урыннарын алмашалар. Бу вакытта алып баручы уйнаучыларның кайсысы да булса берсенең почмагын алырга тырыша. Ул почмакны ала алмаса, уен яңадан башлана. Әгәр алса, почмаксыз калган бала уенны алып баручы була. Уен яңадан башлана.

**Чүлмәкләр**

*(Мордва халык уены)*

Бу уен төрле яшьтәге балалар белән уйнала. Һәр өлкән уенчы кечерәк яшьтәге кызлар яки малайлар арасыннан үзенә «чүлмәк» сайлый. «Чүлмәкләр» түгәрәк ясап утыралар. Өлкән уенчылар үзләре сайлаган чүлмәкләр артына басалар. Ә бер уенчы чүлмәксез кала. Ул чүлмәкле уенчыларның берсе янына килә дә: «Чүлмәк сатасыңмы?» – ди. «Әйе, сатам», – ди чүлмәк хуҗасы. Шуннан соң икесе дә чүлмәккә куллары белән кагылалар һәм, түгәрәк буенча, икесе ике якка йөгереп китәләр. Кем беренче булып әлеге чүлмәк янына килеп җитә һәм кулы белән аңа кагыла, ул чүлмәкнең хуҗасы була. Чүлмәксез калган уенчы алып баручы ролен ала.

Уен дәвам итә.

**Су анасы**

*(Удмурт халык уены)*

Җиргә (идәнгә) зур түгәрәк – «күл» сызыла. Санамыш ярдәмендә «Су анасы» сайлана. Ул «күл» эчендә утыра.

Уйнаучылар түгәрәк тирәли (сызыкның тышкы ягында) йөгереп йөриләр. Су анасы сызык эчендә йөгерә, «яр»га якынлашкан балаларны тотарга тырыша (кулы белән кагыла). Тотылган бала күл эченә керә.

Уен күпчелек балалар тотылганчы дәвам итә.

Тотылган балалар Су анасына калган балаларны тотарга булышалар.

**Кулъяулык белән уен**

*(Удмурт халык уены)*

Балалар, парлашып, түгәрәккә басалар. Ике алып баручы билгеләнә, берсенә кулъяулык бирелә. Сигнал булгач, кулъяулыклы алып баручы йөгереп китә, ә икенчесе аны куа. Алар түгәрәкнең тышында куышалар. Кулъяулыклы алып баручы парлашып басып торучы балаларның берәрсенә кулъяулыкны тапшыра, үзе аның урынына баса. Шулай итеп, кулъяулыклы алып баручы алмашына. Парсыз калган алып баручы кулъяулыклы баланы куып китә.

**Сукыр тәкә**

*(Удмурт халык уены)*

Санамыш ярдәмендә «сукыр тәкә» билгеләнә. Яулык белән аның күзен бәйлиләр дә өч тапкыр урынында әйләндерәләр. Калган балалар аның тирәсендә йөгереп йөриләр, сукыр тәкәгә якын киләләр. Сукыр тәкә аларны куа. Кемне дә булса тотса, тотылган бала «сукыр тәкә» була.

Уен шулай дәвам итә.

**Атның койрыгын тот**

*(Удмурт халык уены)*

Уйнаучылар бер-бер артлы тезелеп басалар. Һәркем үзенең алдында торган баланың биленнән тота. Колонна башында баскан бала – «баш», ахырында басып торганы «койрык» була. Сигнал булуга «баш», уенчыларны үз артыннан ияртеп, боргалана-боргалана йөгерә башлый, «койрыкны» тотарга тырыша. Тота алса, санамыш ярдәмендә яңа «баш» һәм «койрык» сайланып, уен дәвам итә.

*Уенның кагыйдәсе*

Уйнаучылар бер-берләренең билләренә, уен барышында ычкынып китмәслек итеп, бик ныклап тотынырга тиешләр.

**Бүре һәм куян**

*(Чуваш халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Бер бала әйдәүче итеп билгеләнә. Ул түгәрәк тирәли әйләнеп йөри һәм тиз-тиз әйтә: «Учак яна, самавыр кайный, шулай кирәк. Бабай, син нишлисең?» – ди һәм, бер баланың артында туктап, аның җилкәсенә җиңелчә генә кагыла. Теге бала күзләрен куллары белән каплый. Шул рәвешле, уен түгәрәктәге барлык балаларның күзләре капланып беткәнче дәвам итә. Шуннан соң әйдәүче түгәрәк тирәли икенче якка әйләнеп йөри башлый һәм, берәр баланың җилкәсенә кагылып: «Бүреме, куянмы?» – дип сорый, шул баланы үзенә таба каратып, кулларын йөзләреннән ала. Әгәр баланың йөзе кырыс, усал булса, ул йөзләрен җыерып торса, әйдәүче аны «бүреләр» ягына, киресенчә, юаш булып, елмаеп торса, «куяннар» ягына җибәрә. Шулай итеп, һәр уйнаучы бала теге яки бу якка бүленеп бетә. Иң соңгы бала үз урынына барып җиткәч, бүреләр куяннарны куа башлыйлар. Бүрегә бер дә тотылмаган куян җиңүче дип билгеләнә.

**Җитез тиеннәр**

*(Чуваш халык уены)*

Бер баланы «эт» итеп билгелиләр, калганнары – «тиеннәр». Тиеннәр эскәмияләргә (урындыклар, зур шакмаклар) менеп урнашалар, түбәндәге такмакны сөйлиләр:

Без – тиеннәр – яратабыз
Сикереп-сикереп уйнарга.
Сикерәбез дә качабыз
Агачтагы куышка.

Куышта чикләвек күп,
Ашыйбыз тәмле итеп.
Тешләребез нык безнең,
Кимерәбез күп итеп!

«Күп итеп» сүзләреннән соң, тиеннәр эскәмияләрдән сикереп төшәләр һәм бүлмә буйлап йөгереп китәләр. Эт аларны куа. Тотылган бала эт була һәм уен дәвам итә.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Эт уйнаучыларга кулы белән генә кагылырга тиеш.
2. Эт эскәмиягә басып өлгергән уенчыны тота алмый.

**Ай һәм кояш**

*(Чуваш халык уены)*

Ике бала уенны алып баручы итеп сайлана. Алар, бер читкә барып, калган уенчылар ишетмәслек итеп, берсе – «ай», икенчесе «кояш» итеп билгеләнәләр.

Уенда катнашучылар бер-бер артлы тезелеп басалар, куллары белән алда торучының биленә тотыналар (яисә җилкәсенә куялар). Кояш һәм ай алар янына киләләр. Куллары белән тотынышалар һәм, аларны өскә күтәреп, капка ясыйлар. Балалар, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, капка аша үтәләр:

Без барабаыз-барабыз,
Без барабыз урманга,
Бер-бер артлы тезелеп,
Йөгереп-йөгереп уйнарга.

Ай белән Кояш соңгы булып килгән баланы туктатып, башкалар ишетмәслек итеп: «Син кайсы якка кучәсең: кояшкамы, айгамы?» – дип сорыйлар. Бала шыпырт кына кайсы якка кучәсен әйтә һәм үзе теләгән якка баса. Уен дәвам итә. Ахырдан кайсы якка күбрәк бала күчкәне билгеләнә.

**Инешләр**

*(Чуваш халык уены)*

Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм бүлмәнең кара-каршы якларына басалар. Һәр бала үзенең алдында басып торган уенчының биленнән тота. «Инешләр!» дигән сигнал булуга ике команда да, бер-берләреннән аерылмыйча, төрле юнәлештә йөгереп китәләр. «Зур Идел!» сигналына уенчылар бер колонна булып тезелергә тиешләр.

*Уенның кагыйдәләре*

1. Һәр уенчы алдында торган баланың биленә нык итеп тотынырга тиеш.
2. Йөгергән вакытта, кулларны билдән ычкындырырга, колоннадан чыгарга ярамый.

# II БҮЛЕК

## Без уйныйбыз, уйныйбыз...

Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Кулны кулга чаба-чаба
Куанабыз, җырлыйбыз...

*С. Миңлекәй*

# ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР

Хәрәкәтле уеннар – балаларны эмоциональ яктан баета торган уеннар. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш-гамәл, хәрәкәтләреңне барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша нәниләрдә күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен барышында балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

Хәрәкәтле уеннарның әһәмияте – бала организмын ныгыту, аның хәрәкәтләрен үстерү. Хәрәкәт гәүдә торышын ныгыта, чыныктыра.

## ЙӨГЕРҮЛЕ УЕННАР

*Йөгерүле уеннарның* максаты – балаларда туры һәм төрле юнәлештә йөрү, йөгерү күнекмәләре булдыру, сигнал буенча хәрәкәт башкара белүләрен үстерү, бер-бер артлы тезелеп йөрергә һәм йөгерергә, берсен-берсе куып тотарга өйрәтү, игътибарлылык, җитезлек, өлгерлек сыйфатлары тәрбияләү.

### Куып узарга тырыш!

Идәнгә акбур белән зур бер түгәрәк (яки овал) сызыла. Балалар түгәрәк тирәли басалар. Тәрбияче сигналы булуга, алар барысы да бер бер үк якка йөгерә башлыйлар. Һәр бала үзе алдыннан баручыны куып узарга тырыша. Әгәр берәр бала кемне дә булса уздырса, ул уеннан чыга. Уенда иң озак уйный алган бала җиңүче була.

### Чык, йөгер

Балалар арасыннан уенны алып баручы һәм куучы билгеләнә. Куучы уйнаучыларның тавышлары ишетелмәгән, кыланышлары күренмәгән җиргә читкәрәк китеп тора. Алып баручы һәр балага шыпырт кына берәр кош исеме әйтеп чыга. Исемнәр билгеләнеп, уйнаучылар утырышкач, уенны алып баручы куучыны чакырып: «Сиңа нинди кош кирәк?» – дип сорый. Куучы кош исемен әйтә. Әгәр әйткән кош исемнәре арасында уйнаучылардан берәрсенең исеме булса, ул торып йөгерә, ә куучы аны куып китә. Тота алса, алар үзара рольләрен алмашалар. Әгәр уйнаучы тоттырмыйча яңадан урынына килеп утырса, балаларга башка исемнәр бирелә, һәм уен яңадан башлана.

### Урынсыз калма!

Уен балаларны тиз йөгерергә, йөрергә өйрәтә.

Балалар, бер-берләреннән кул сузымы ара калдырып, түгәрәккә басалар. Һәр уйнаучының урыны берәр уенчык белән (мәсәлән, шакмак, кегля, флаг һ.б.) билгеләнә.

Тәрбияченең «Йөгерегез!» дигән сүзеннән соң балалар, түгәрәктән чыгып, бүлмә буйлап йөгерешә башлыйлар, уйныйлар. Шул арада тәрбияче бер баланың уенчыгын алып куя. «Барыгыз да үз урыннарыгызга!» дигән сигналдан соң, балалар, йөгереп килеп, үз урыннарына басарга тырышалар. Бер бала урынсыз кала.

Уен 5-6 тапкыр кабатлана.
*Искәрмә.*
• Уенны соңгы тапкыр кабатлаганда, барлык балалар да урынлы булсын өчен, тәрбияче бер уенчыкны да алмый.
• Соңрак берьюлы берничә әйберне алырга мөмкин.

**Өйләрегезгә кайтыгыз!**

Балалар өч-дүрт төркемгә бүленәләр. Җирдә төркемнәр санынча түгәрәкләр сызыла. Болар – төркемнәрнең «өйләре». Һәр өйгә берәр төрле билге (кызыл флаг, зәңгәр шакмак, ак куян һ.б. шундый уенчыклар) куела. Һәр баланың кулында үз өе төсендәге билге (мәсәлән, тасмалар) була. Балалар өйләренә кереп урнашалар. Бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул бүлмә буйлап йөри һәм үзе теләгән өйнең янына килеп туктый да: «Әй балалар, әйдәгез, барыгыз да йөрергә чыгыгыз!» – ди. Балалар өйләреннән чыгалар һәм тиз генә алып баручының артына тезеләләр. Аннан соң барысы бергәләп икенче өй янына киләләр һәм алдагы сүзләрне әйтәләр. Шул рәвешле йөртүче барлык балаларны үз янына җыя. Җыйналып беткәч, балаларга үзләре теләгән якта йөгерешеп йөрергә мөмкинлек бирелә. Күпмедер вакыт уйнаганнан соң, уенны алып баручы: «Балалар, барыгыз да өйләрегезгә кайтыгыз!» – ди. Уйнаучылар үзләренең өйләренә таба йөгерәләр. Үзләренең урыннарында алдан җыйналып беткән төркем җиңгән дип санала.

Уен 2-3 тапкыр кабатлана.

**Әйдә, куып кара!**

Мәйданчыкның кара-каршы ике ягына сызыклар сызыла. Болар – уйнаучылар өчен «өйләр». Уенда катнашучылар сызыкларның берсе артына тезелеп басалар. Санамыш ярдәмендә балаларны куучы билгеләнә. Ул ике сызык арасына урнаша. Уйнаучылар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без – балалар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга;
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга!
Тот!

Соңгы сүзләрне әйткәч, балаларның барысы да каршы яктагы сызыкка таба йөгерәләр. Куучы йөгерүчеләрне тотарга (кул белән кагылырга) тырыша. Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгып торалар. Куучы 3-5 баланы тоткач, икенче куучы сайлана. Уен шулай дәвам итә.

**Йоклама!**

Балалар түгәрәк ясап тезеләләр. Һәр баланың алдына берәр төрле уенчык куела. Тәрбияче: «Йөгерегез!» – дигәннән соң, барлык балалар мәйданчык (бүлмә) буйлап үзләре теләгәнчә йөгерешеп йөриләр, сикерәләр, уйныйлар. Бу вакытта тәрбияче балаларга сиздерми генә берәр уенчыкны алып куя (бер бала өйсез кала). Күпмедер вакыт

уйнаганнан соң, тәрбияче «Урыннарга!» дигән сигнал бирә һәм балалар уенчыкларына таба йөгерәләр. һәр бала уенчыкны кулына алып югары күтәрә. Уенчыксыз калган бала «йоклаган» булып санала. Уен 4-5 тапкыр кабатлана.

Уен пространствода ориентлашу, тиз йөгерү һәм предметны тотып алу күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә.

**Урыныңа йөгер**

Уйнаучылар түгәрәкләнеп урындыкларга (яки идәнгә) утыралар. Тәрбияче янәшә утырып торган ике баланы чакырып чыгара. Алар бер-берсенә аркаларын терәп басалар. «Бер, ике, өч – йөгер!» дигән сигнал булуга, түгәрәкнең тышкы ягында икесе ике якка йөгереп китәләр һәм, үз урыннарына килеп җиткәч, урындыкларына утыралар. Тәрбияче һәм уенчылар кайсы баланың буш урынга алданрак килеп утырганын билгелиләр. Аннан соң тәрбияче икенче парны чакырып чыгара, һәм уен яңадан кабатлана.

**Көн һәм төн**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр: «көн» һәм «төн». Бүлмә яки мәйданчыкның ике башында көн өчен «өйләр» билгеләнә – сызык сызыла. Төн булып уйнаучылар – урталыкта, көн булып уйнаучылар сызыкларның берсе янында басып торалар. Көн булып уйнаучылар, сигнал булу белән, билләренә кулъяулык кыстырып, тавыш-тынсыз гына төнне узып, икенче өйгә – бүлмәнең каршы ягындагы сызыкка таба йөгерәләр. Алар төн булып уйнаучыларга кагылмыйча гына узарга тиешләр. Төннәр, урыннарыннан кузгалмый гына, узучыларның яулыкларын алып калырга тырышалар. Яулык ала алучы бала – көн, яулыгын алдыручы төн була.

Уен балаларны тавышсыз гына, җиңел йөгерергә өйрәтә, дикъкатьләрен үстерә.

**Бакча дуслары**

Уйнаучылар үзләренә төрле кош исемнәре сайлыйлар. Алар – «бакча дуслары». Мәйданчыкның бер башында җирдә һәр кош өчен түгәрәк – «кош оясы» сызыла. Каршы якта «бакча» була. Бакча эченә «карчыга» (йөртүче) урнаша.

Карчыга бакча артындагы «оясына» яшеренү белән, кошлар, ояларыннан чыгып, җирдәге «кортларны, бөҗәкләрне» «чүплиләр, төрле юнәлештә очып йөриләр. Тәрбияченең «Карчыга!» дигән сүзен ишетү белән, карчыга үзенең оясыннан чыга һәм кошларны куа башлый. Кошлар үз ояларына очалар. Тотылган кошларны карчыга үзе белән алып китә.

Сигнал булу белән кошлар кабат ояларыннан чыгалар һәм бакчага килеп җимнәр чүплиләр. Берникадәр вакыттан соң (тәрбияченең сигналы буенча) кабат карчыга пәйда була һәм уен алда сурәтләнгәнчә дәвам итә.

Уен берничә тапкыр кабатлана.

**Бер аякта басып кал!**

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасында басып тора. Калган балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк буйлап әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Өлгерлектә, җитезлектә
Безгә тиңнәр юк, дуслар.
Уртада тора куучы,
Көче җитсә, ул тотар!

Соңгы сүзләрне әйтеп бетерү белән, барлык балалар мәйданчыкның төрле ягына йөгереп китәләр. Түгәрәк уртасындагы бала йөгерүчеләрне куа. Куучыдан тоттырмаска теләгән бала, бер аякта басып (уң яки сул аягын күтәреп), туктап калырга тиеш. Ул кулларын үзе теләгәнчә (мәсәлән, як-якка сузып һ.б.) куя ала. Шушы хәлдә торганда, куучы аны тота алмый.

Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгалар. Алып баручы 3-5 баланы тоткач, уен тәмамлана.

Бу уенда балалар гәүдә тигезлеген сакларга өйрәнәләр.

**Өченче – артык**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр һәм түгәрәкләр ясыйлар. Ике түгәрәктә дә балалар саны бертигез булырга тиеш. Тышкы түгәрәктә басып торучылар эчке түгәрәктәгеләрнең артларына туры китереп басалар. Сигнал булу белән тышкы түгәрәктән бер бала алдында басып торучы баланы куа башлый. Куучы һәм йөгерүче түгәрәкнең тышкы ягында йөгерәләр. Йөгерүче, тотылмыйча, түгәрәкнең эченә йөгереп кереп, эчке түгәрәктәге балаларның берсенең алдына килеп баса һәм: «Өченче кеше артык!» – дип әйтә. Ул килеп баскан парның арттагысы: «Икәү җитәр!», – ди һәм түгәрәктән йөгереп чыга. Баштагы куучы йөгерүче була, яңа куучы аны куа китә. Уен алдагы кагыйдә буенча дәвам итә.

Уен балаларның дикъкате үсүгә булышлык итә, оста һәм тиз йөгерү күнекмәләре тәрбияли, өлгерлеккә, җитезлеккә өйрәтә.

**Бүре һәм казлар**

Берничә бала, бер-берсенең билләренә тотынып, колонна булып тезелеп басалар. Болар – «казлар». Аларның алдында бер бала – «ата каз» тора. «Бүре» казларны тотарга тели, әмма ата каз аларны бүрегә бирмәскә тырыша: кулларын җәеп, бүренең каршына чыга, казларны саклый. Бүре казларның бары тик арттагыларын гына тота ала (уртадан да, баш ягыннан да тотарга тиеш түгел). Барлык казлар тотылып беткәч, уен тәмам була.

**Ятьмә**

Уйнаучыларның икесе – «балыкчы», калганнары «балык» булалар. Балыкчылар, кара-каршы басып, җитәкләшәләр дә балыкларны куа китәләр. Берәрсен куып җитеп, кул араларына кертә алсалар, балык «ятьмә»гә кергән булып исәпләнә. Тотылган балык, балыкчыларның арасына кереп, җитәкләшә дә алар белән бергә «ятьмәгә» әйләнә. Хәзер инде болар өчәүләшеп балыкларны куа китәләр. Һәрбер тотылган балык, шул рәвешчә балыкчылар белән кушылып, ятьмәгә әйләнә бара. Ятьмә озынайганнан-озыная. Барлык балыклар да ятьмәгә әйләнеп беткәч, уен тәмам була.

### Күке

Идәнгә (җиргә) түгәрәкләр сызыла. Бу – «кош оялары». Оялар уйнаучылар санына караганда бергә кимрәк булырга тиеш. Санамыш ярдәмендә «күке» сайлана. «Көн» дигән сигнал булганда, барлык кошлар ояларыннан чыгалар һәм очып йөриләр. «Төн» дигән сүзгә, кошлар үз ояларына кереп урнашырга ашыгалар. Күке дә үзенә оя алып калырга тели. Оясыз калган кош күке була. Уен кабатлана.

### Ике һәм өч

Балалар бүлмә (мәйданчык) буйлап таралып йөриләр, йөгерешәләр. Тәрбиянең «Ике!» дигән сигналына уйнаучылар янәшәдәге теләсә-кайсы бала белән парлашырга, җитәкләшеп, алдан билгеләнгән урынга (агач, флаг, урындык һ.б.) йөгереп барырга тиешләр. һәр йөгереп килгән пар бер-бер артлы тезелә бара. Тәрбияче: «Өч!» – дигән очракта, балалар өчәүләшеп басалар һәм тезелү урынына йөгерәләр. Иң җитез парлар бәяләнә.

### Аю, куян

Бүлмәнең бер башына – уенчык аю, ә каршы якка куян утыртыла. Балалар ике төркемгә бүленәләр дә бер төркем – куян ягына, икенчесе аю ягына баса. Сигнал булу белән, барлык балалар бергә түгәрәккә җыелалар һәм җитәкләшеп әйләнәләр. Беркадәр йөргәч, тәрбияче: «Барыгыз да үз урыннарыгызга йөгерегез!» – ди. Балалар ике якка йөгерешәләр. Берәрсе, ялгышып, үз ягына бармаса, ул уеннан чыгарыла яки аңа җәза бирелә. Җәзаны үтәгәннән соң, бу бала уенда кабат катнаша ала.

Уен урында ориентирлашырга өйрәтә, хәтерне яхшырта.

### Тыңлаусыз чебиләр

Уйнаучылар арасыннан бер бала «тавык» итеп билгеләнә, калган балалар – «чебиләр». Тавык бүлмә буйлап сибелгән чебиләрен куа һәм тоткан берсен бүлмә кырыенда тезеп куелган урындыкларга утырта. Әмма чебиләр – тыңлаусызлар. Әниләре яннарыннан китү белән урыннарыннан сикереп торалар һәм кабат йөгерешеп китәләр. Тавык аларны яңадан куа.

Бу уенны аз сандагы балалар белән (4-5) уйнарга кирәк. Бүлмәдә балалар күп булганда, аларны берничә төркемгә бүлеп уйнарга мөмкин.

### Күгәрчен

Балалар тәрбияче белән бергә бүлмә уртасында чүгәләп утыралар. Тәрбияче балаларга түбәндәге сүзләрне әйтә:

Безнең тәрәзә төбенә
Күгәрчен килеп кунды.
Озак кына утырды да
Кинәт, очып, юк булды.

Без дә торыйк урыннан,
Очыйк күгәрчен артыннан!

Шул сүзләрдән соң балалар урыннарыннан торалар һәм бүлмә буйлап йөгерешеп йөриләр. Тәрбияче сигналыннан соң, кабат урыннарына кайталар. Уен кабатлана.

**Бер, ике, өч , безне куып тот!**

Санамыш ярдәмендә бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул бүлмә уртасына баса. Калган балалар бүлмәнең бер ягына тезелеп басалар һәм барысы да берьюлы: «Бер, ике, өч, безне куып тот!» – дип, бүлмәнең икенче ягына таба йөгерәләр. Уенны алып баручы аларны куа башлый. Кемгә дә булса кулы белән кагылса, ул бала тотылган булып санала, һәм ул вакытлыча уеннан чыгып тора. Барлык балалар каршы якка күчеп беткәч, тотылган балалар саны исәпләнә. Икенче алып баручы сайлана һәм уен дәвам итә.

**Бүре белән сарыклар**

Балалар, кулга кул тотынышып, түгәрәк ясап басалар. Бер бала «бүре» итеп сайлана. Ул түгәрәк уртасына керә һәм чүгәләп утыра. Калган балалар – «сарыклар» түгәрәк буйлап йөриләр һәм тавыш-тынсыз гына бүре янына якынлашалар (түгәрәк эченә керәләр). Сарыкларның берсе бүренең иңбашына кагыла. Шуннан соң бүре тиз генә тора да балаларны куа башлый. Тотылган сарык бүре була.

Уен дәвам итә.

**Куркак тычканнар**

Уен башында балалар урындыкларда утырып торалар. Бер бала «мәче» итеп сайлана. Ул урындыкта «йоклап утыра». Калган балалар – «тычканнар» – урыннарыннан торалар да әкрен генә мәче янына баралар, түбәндәге сүзләрне әйтәләр һәм шигырьдәге сүзләргә туры китереп төрле хәрәкәтләр ясыйлар:

| | |
|---|---|
| Тычканнар чыккан карарга | |
| Сәгать ничә икәнен. | *як-якларына караналар* |
| Сизмәгәннәр алар шунда | *йөгереп йөриләр, сикерешәләр* |
| Песи якын икәнен. | |
| | |
| Песи кинәт уянган, | *кулларын як-якка җәяләр, киерeләләр* |
| Бик каты мыраулаган – | |
| Тычканнар курыкканнар, | *иң өсләрен күтәрәләр* |
| Качып юк та булганнар. | *урындыкларына таба йөгерәләр* |

Песи йокысыннан уяна һәм тычканнарны куа башлый. Балалар тиз генә урындыкларына утырып өлгерергә тырышалар. Урындыктагы тычканны песи тота алмый.

**Оядагы кошлар**

Бүлмәнең (яки мәйданчыкның) кара-каршы якларында 3-4 түгәрәк сызыла. Болар – «кош оялары». Балалар – «кошчыклар» – ояларга керeп урнашалар. Тәрбиячeнең сигналы буенча алар ояларыннан чыгалар һәм бүлмә буйлап таралалар. Чүгәләп җим чүплиләр:

бармаклары белән тезләренә яисә идәнгә (җиргә) сугалар. Торып тагын йөгерәләр. «Кошлар, ояларыгызга!» дигән сигналдан соң балалар ояларына йөгереп кайталар.

Уен 4-5 тапкыр кабатлана.

**Бал кортлары**

Бер бала «аю» итеп билгеләнә. Ул «өенендә» (бүлмәнең бер читендә билгеләнгән урында) утыра. Балалар – «бал кортлары» – бүлмә буйлап йөгереп йөриләр һәм жуылдыйлар: «Ж-ж-ж!». Тәрбияченең: «Аю чыга аланга, бик тели бал ашарга», – дигән сүзләреннән соң, аю әкрен генә өененнән чыга, бүлмә буйлап йөри. Бал кортлары: « Бал кирәк үзебезгә, китегез өегезгә! Ж-ж-ж-ж! – диләр һәм, канаталарын җилпи-җилпи, аюны куалар.

**Үз парыңны тап!**

Балалар парлашып басалар. Һәр парга бер үк төсле берәр уенчык (шакмаклар, тасма, шарлар һ.б.) бирелә. Тәрбияченең «Таралыштык!» дигән сүзеннән соң балалар, парларыннан аерылып, бүлмә буйлап йөгерешә башлыйлар. Бераз уйнагач, тәрбияче: «Парлар, кушылыгыз!» – ди. Балалар, йөгерешеп килеп, тиз генә үз парларын эзләп табарга һәм парлашып басарга тиешләр. Бер-берсен иң озак эзләгән пар җиңелгән дип санала.

Уенны уенчыклардан башка да уздырырга мөмкин. Бу вакытта балалар үз парларын истә калдырырга тиеш булалар.

**Тычкан оялары**

Асфальтка яисә идәнгә акбур ярдәмендә түгәрәкләр – «тычкан ояլары» сызыла. Оялар саны уйнаучылар санына караганда бергә ким булырга тиеш. Балалар – «тычканнар» – бер оядан икенчесенә йөгереп, уйнап йөриләр, бер-берләре белән ояларын алмашалар. Сигнал булуга һәр уенчы, буш ояны карап, тиз генә шунда кереп урнашырга тели. Бер тычкан оясыз кала.

Уен дәвам итә.

**Бүре һәм кәҗә бәтиләре**

Уйнаучылар бер-бер артлы тезелеп басалар да алда торган баланың биленә кулларын куеп тотынышалар. Алар – «кәҗә бәтиләре». Беренче булып басып торган бала – «әни кәҗә» була. Аларга каршы «бүре» баса. Ул әниләре артындагы бәтиләрне тотарга тели. Ләкин ул бары тик иң арттагы кәҗә бәтиен генә тота ала. Әни кәҗә бәтиләрен тоттырмаска тырыша. Кәҗә бәтиләре, кулларын ычкындырмый гына, аның артыннан ияреп йөриләр. Әгәр бүре кәҗә бәтиен тотып алса, ул аны үзенең оясына алып китә. Бүре берәм-берәм барлык кәҗә бәтиләрен тотып бетергәннән соң, уен тәмам була.

**Тизрәк түгәрәккә кер!**

Уен мәйданчыгында бер зур түгәрәк (диаметры 4 м) һәм аның эчендә кечерәк түгәрәк (диаметры 2 м) сызыла. Балалар, бер-бер артлы тезелеп, зур түгәрәкнең тышында

йөриләр. Зур һәм кечкенә түгәрәкләр арасында уенны алып баручы йөри. «Тизрәк түгәрәккә кер!» дигән сигнал булуга, балалар кечкенә түгәрәк эченә таба йөгерәләр, ә алып баручы аларны тотарга тырыша.

Тотылган балалар урыннарында басып калырга тиешләр. Уенны кабатлаганда алар яңадан зур түгәрәк тышына басалар.

**Кошчыклар һәм көчек**

Санамыш ярдәмендә «көчек» билгеләнә. Ул бүлмәнең бер читендә утырып тора. Калган балалар – «кошчыклар» – урындыкларда утыралар. Сигнал булуга алар бүлмә буйлап йөгереп китәләр, очып-уйнап йөриләр. «Сак булыгыз, көчек килә» сигналына, көчек урыныннан сикереп тора һәм кошчыкларны куа башлый. Әгәр дә кошчыклар «агач башына» – урындыкларга менеп утырырга өлгерсәләр, көчек аларга тия алмый. Урындыкка менеп өлгермәгән бала тотылган булып санала. Тотылган кошчык көчек була, ә көчек исә кошчык булып, уен дәвам итә.

**СИКЕРҮЛЕ УЕННАР**

*Сикерүле уеннар* ярдәмендә балалар бер урында, ике аякта берьюлы, югарыдан түбәнгә, озынлыкка сикерергә өйрәнәләр; балаларда хәрәкәтләрне күрү сигналы белән яраштыра белү күнекмәләре булдырыла, сигнал буенча хәрәкәт итә белү күнекмәләре үстерелә.

**Оясыз сыерчык**

Бүлмәнең бер башына урындыклар тезелә. Болар – «сыерчык оялары». Балалар – «сыерчыклар». Алар урындыкларга менеп басалар. Тәрбиячененң «Очтылар!» дигән сүзен ишетү белән, балалар урындыкларыннан сикереп төшәләр һәм ирекле рәвештә бүлмә буйлап йөгереп (очып) йөриләр. Шул арада тәрбияче бер урындыкны алып куя. «Сыерчыклар, ояларыгызга!» дигән сигналны ишетүгә, балалар берәр урындык өстенә менеп өлгерергә тырышалар. Сыерчыкларның берсе оясыз кала. Уен 3-5 тапкыр кабатлана.

**Бер, ике, өч – сикер!**

Балалар 4-5 төркемгә бүленәләр. Төркемнәр бер-бер артлы тезелеп басалар. Беренче рәттә басып торучыларның тез араларында кечкенә туп. Уйнаучыларның каршында (3-4 м ераклыкта) җиргә сызык сызыла (сызык урынына җиргә сузылган бау яисә сикергечне дә файдаланырга мөмкин). Тәрбияче: «Бер, ике, өч – сикер!» – дип сигнал биргәч, алдагы рәттә басып торучылар, тупларын тезләре белән кыскан хәлдә, ике аяклап сикереп сызык янына баралар. Тубын төшермичә бау янына кадәр сикереп бара алган бала откан булып санала. Сикергән балалар, тиз-тиз генә кире урыннарына кайтып, тупларын үзләреннән артта торган икенче рәткә бирергә һәм иң артка барып тезелергә тиешләр. Аннан соң икенче рәттәге балалар сикерә һәм алар арасыннан да беренче сикереп килеп җитүчеләр билгеләнә.

Барлык рәтләр сикереп беткәч, уен тәмамлана.

Бу уенда балалар басып торган урыннан ике аяклап сикерергә күнегәләр.

**Түгәрәктән сикерү**

Идәнгә акбур яки җиргә таяк белән сызып түгәрәк ясала. Уйнаучылар барысы да түгәрәкнең тышкы ягына тезеләләр. Бер бала түгәрәк эчендә кала. Ул түгәрәктән чыга алмый, сызык аркылы түгәрәк эченә сикереп кергәннәрне тота. Сигнал буенча уйнаучылар түгәрәккә сикереп керәләр, ә уртадагы бала аларның кайсын да булса тотарга тырыша. Тотылган бала түгәрәк эчендә кала. Уен дәвам итә.

**Әбәкләтмә**

Җирдә зур түгәрәк сызыла. Барлык уйнаучылар, ярты адым калдырып, түгәрәк тирәсенә тезелеп басалар. Тәрбияче уйнаучыларның берсен «әбәкче» итеп билгели, әбәкче түгәрәкнең эченә (теләсә кайсы урынга) кереп баса.

Уйнаучылар, тәрбияче сигналы буенча, сызык аша түгәрәк уртасына ике аякта сикереп керәләр. Әбәкче, балаларны (алар түгәрәк эчендә чакта) әбәкләргә тырышып, түгәрәк эчендә йөгереп йөри. Әбәкче якынайгач, балалар түгәрәктән сикереп чыгалар. Әбәкләнгән уйнаучы җиңелгән булып санала (ләкин ул уенда катнашуын дәвам итә).

30–40 секунд үткәннән соң, тәрбияче уенны туктата һәм тотылган балаларны саный. Аннан соң үзен бер тапкыр да әбәкләтмәгән балалар арасыннан икенче әбәкче сайлана.

**Бау аша сикерү**

2 м чамасы бау ике тотрыклы предметка тарттырып бәйләнә. Бауның биеклеге 12-20 см. Уйнаучылар баудан читкәрәк китеп бер-бер артлы тезеләләр дә, команда булгач, йөгереп килеп, бау аша сикереп чыгалар. Бауга килеп җитеп, сикерә алмый калучы бала вакытлыча уеннан чыга.

*Уенны төрлеләндерергә дә була:*

- парлап йөгереп килеп сикерергә (парыннан калучы уеннан чыга);
- кулларны артка куеп, баш өстенә куеп, билгә таянып һ.б. сикерергә;
- уйнаучыларны ике төркемгә бүлеп, кара-каршы килеп сикерергә була. Балалар тик тора торган (хәрәкәтсез) баудан сикерергә күнегеп беткәч, әйләнеп тора торган баудан йөгереп килеп сикерергә өйрәнәләр. Шул ук озынлыктагы бауны ике кеше бер көйгә әйләндереп тора, балалар югарыда әйтелгән тәртиптә сикерә башлыйлар.

Бу уенда балаларның аяк, корсак мускуллары чыныга; йөгерү, сикерүдә тизлек, җитезлекләре арта.

**Көчле дулкын!**

Уен мәйданчыкта (паркта, урманда, болында) уйнала. Балалар эскәмияләрдә (агач төпләрендә, яссы ташларда һ.б.) басып торалар. Тәрбияче балаларга «суга сикерергә» һәм «йөзәргә» тәкъдим ясый. Балалар басып торган урыннарыннан сикереп төшәләр һәм, суда йөзгән хәрәкәтләр ясап, мәйданчык буйлап йөгереп йөриләр. «Көчле дулкын! Өйгә кайтыгыз!» дигән сигналга балалар кире үз урыннарына менеп урнашалар.

Уен кабатлана.

**Төлке килә!**

Бер уйнаучыны «төлке» итеп билгелиләр һәм аңа бүлмәнең бер читендә «өн» сызып куялар. Башка балалар, кулларына баулар тотып, төрле якка таралалар. Төлкенең дә кулында бау була. Сигнал булуга төлке, оясыннан чыга да бер аякта сикерә-сикерә балаларны куа (балалар да бер аякта сикерәләр) башлый. Кемне дә булса куып җитеп, аңа бау белән кагыла алса, ике аягына басып, тотылган баланы үзенең өенә алып китә. Төлке шул рәвешле ике тапкыр үзенең оясыннан чыга (бер чыгуында уң, икенче чыгуында сул аягы белән аксаклый). Аннан соң икенче төлке сайлана, уен шул рәвешле дәвам итә.

Әгәр дә төлке кемгә дә булса бавын тидергәнче ялгыш ике аягына басса яки бер аягын икенчесе белән алыштырса, уйнаучылар аны өенә куып кертәләр. Бу вакытта төлке ике аяклап йөгерә.

**Челән белән бакалар**

Мәйданчык уртасына як-яклары 4-6 м озынлыгында булган квадрат яки турыпочмаклык сызыла. Бу «бакалар» яши торган «сазлык» була. Квадратның почмакларына 10-15 см биеклегендәге шакмаклар куела, як-якларына бау сузыла. Бауларның очларына ком тутырылган кечкенә капчыклар тагыла; алар шакмаклар өстенә урнаштырылалар.

Мәйданчыкның бер почмагына «челән оясы» сызыла.

Тәрбияче уйнаучыларның берсен «челән» итеп билгели, калганнары «бакалар» булалар; алар сазлык эчендә басып яки сикеренеп торалар.

Уйнаучылар билгеләнгән урыннарына урнашып беткәч, челән, зур-зур атлап, сазлыкка якынлаша, бакаларны тотарга теләп, бау аша квадрат эченә керә. Бакалар челәннән котылу өчен теләсә нинди ысул белән: ике аякта берьюлы яки сынар аякта сикереп, бау аркылы сазлыктан чыгып качалар. Качып өлгерә алмаган бакаларны челән тотып ала һәм үз өенә алып китә. Тотылган балалар вакытлы рәвештә (икенче челән сайланганчы) уеннан чыгалар.

Барлык балалар да сазлыктан чыгып өлгереп, челән беркемне дә тота алмаса, ул үз оясына әйләнеп кайта. 2–3 бала тотылганнан соң, яңа челән сайлана.

**Уенның кагыйдәләре**

1. Челән бакаларны квадрат эчендә генә тота ала.
2. Бакалар бау аркылы сикереп чыгарга тиешләр. Атлап чыгарга рөхсәт ителми.
3. Бау аркылы атлап чыккан бака тотылган булып санала.

**Кул чабыгыз**

Уйнаучылар, бер-берләренә карап, ике рәткә тезелеп басалар. Тәрбияче сигналы буенча, беренче рәттәге балалар кул чаба башлыйлар, икенче рәттәгеләр бер урында ике аякта сикереп торалар (аяклар бергә, аяклар як-якка). 12-16 тапкыр сикергәннән соң, балалар рольләрен алмашалар.

**Аягыңа тидертмә**

Уен өчен ком тутырылган кечкенә капчык кирәк.

Балалар, бер-берсеннән 3-4 адым ара калдырып, түгәрәкләнеп тезеләләр. Бер

уйнаучы капчык бәйләнгән бауның икенче башын тотып, капчык идәнгә өстерәлеп барырлык итеп әйләндерә башлый. Түгәрәктәгеләр, капчыкны аякларына тидермәс өчен, ул якынлашкан чакта сикерергә тиеш булалар. Аягына капчык тигән бала, уртага басып, капчыкны әйләндерә. Уен дәвам итә.

### Куян балалары

Идәнгә балалар санынча кыршаулар куела. Болар – куян балаларының «өйләре». Уйнаучылар – «куян балалары» – ике кулларын күкрәк тирәсенә куеп, бүлмә буйлап йөгереп, сикергәләп йөриләр. Тәрбиячenең: «Бүре килә!» – дигән сүзен ишеткәннән соң, куян балалары үзләренең өйләренә сикереп керәләр.

### Көчтем-көч

Уен мәйданчыгында бер зур түгәрәк, аның эчендә уйнаучылар санынча 30-35 см лы кечкенә түгәрәкләр сызыла. Балалар үз түгәрәкләре эченә кереп басалар. Уртада уенны алып баручы басып тора.

Алып баручы: «Көчтем-көч!» – ди. Балалар, бер аякта сикереп, бер-берләре белән түгәрәкләрен алмашалар. Алып баручы да, бер аягында сикереп йөреп, үзенә берәр урын алып калырга тырыша. Урынсыз (түгәрәксез) калган бала уенны алып баручы була. Уен дәвам итә.

**Уенның кагыйдәләре**

- Түгәрәктән уйнаучыны этеп чыгарырга ярамый.
- Бер түгәрәккә бары тик бер генә бала урнаша ала.
- Түгәрәккә кем беренче сикереп керә, шул түгәрәкнең хуҗасы була.

### Сикергеч мәктәбе

Һәр уйнаучы уенда 7 «баскыч»ны үтәргә тиеш. Үтә алмаган очракта, ул уеннан чыга. Кем иң соңгы баскычка кадәр барып җитә ала, шул – җиңүче.

1 нче баскыч. Сикергечне алга таба әйләндереп ике аяклап 10 тапкыр сикерү.
2 нче баскыч. Сикергечне артка таба әйләндереп ике аяклап 10 тапкыр сикерү.
3 нче баскыч. Сикергечне алга таба әйләндереп, уң аякта 10 тапкыр сикерү.
4 нче баскыч. Сикергечне алга таба әйләндереп, сул аякта 10 тапкыр сикерү.
5 нче баскыч. Сикергечне артка таба әйләндереп, уң аякта 10 тапкыр сикерү.
6 нчы баскыч. Сикергечне артка таба әйләндереп, сул аякта 10 тапкыр сикерү.
7 нче баскыч. Сикергечне алга таба әйләндереп, ике аяклап 10 тапкыр сикерү.

## ҮРМӘЛӘҮЛЕ, ШУЫШУЛЫ УЕННАР

*Үрмәләүле, шуышулы уеннарның* максаты – нәниләргә үрмәләп йөрү, үрмәләп югарыга таба менү, шуышып йөрү күнекмәләре бирү; аларда игътибарлылык, тотнаклылык, түземлелек сыйфатлары тәрбияләү, хәтер сәләтләрен, зиһеннәрен үстерү.

### Нәрсә кайда яши?

Санамыш ярдәмендә бер бала «төлке» итеп билгеләнә. Бер төркем балалар – «куяннар», икенчесе «тиеннәр» була.

Балалар белән алдан ук тиеннәрнең – агачта яшәве, куяннарның куаклар астына яшеренүе искә төшерелә.

Уен өчен гимнастика баскычы – «агачлар» һәм урындыклар – «куаклар»кирәк булачак.

Тәрбияче сигналы буенча куяннар һәм тиеннәр мәйданчыкта йөгереп уйныйлар. Тәрбияче: «Килә хәйләкәр төлке! Әгәр өең табалмасаң, менә булыр көлке», – дигәч, тиеннәр гимнастика баскычына таба йөгерәләр, ә куяннар урындыкларга урнашалар. Ялгышкан балаларны төлке үзе белән алып китә. Уен берничә тапкыр кабатлана.

### Тиеннәр

Уен гимнастика баскычы булган залда яисә мәйданчыкта уйнала. Уен өчен эскәмияләр, такта салынган ике зур куб кирәк булачак.

Санамыш ярдәмендә «аучы» билгеләнә. Ул залның каршы ягында сызылган зур түгәрәк эчендә – «аучы өе»ндә утыра. Башка уенчылар – «тиеннәр» – гимнастика баскычына һәм калган җиһазларга урнашалар. Тәрбияче сигнал биргәч, тиеннәр бер-берләре белән урыннарын алмашалар, бу вакытта аучы аларны тотарга тырыша. Әгәр аучы идәндә вакытта кемгә дә булса кулы белән кагыла икән, бу тиен тотылган санала, һәм аучы аны үз өенә алып китә.

Уен 5-6 тапкыр кабатлана. 1-2 уеннан соң яңа аучы сайлана. Уен ахырында иң җитез һәм кыю тиеннәр билгеләнә.

### Төпсез капчык

Каршыга төпсез капчык куела. Сигнал булгач, балалар бер-бер артлы төпсез капчык эченнән үрмәләп чыгалар, билгеләнгән урынга кадәр йөгереп баралар. Тәрбияче уйнаучыларның баш, кул-аякларын дөрес тотып үрмәләүләрен күзәтә.

### Төшермә!

Балалар идәнгә утыралар, куллары белән арттан идәнгә таяналар. Корсакларына боҗра яки ком тутырылган кечкенә капчык куялар. Аннары куллары һәм аякларына таянып, бөгеләләр. Куелган әйберне төшермәскә тырышып, 2-3 м араны шуышып баралар. Биремне тизрәк башкарган һәм әйберен төшермәгән бала җиңүче була.

**Канат буенча югарыга!**

Уенда катнашучы бала канатның (үрелгән юан бау) бәйләнгән очына баса, канатта «эленеп» тора – куллары терсәктән бөгелгән, бите уч төпләре турысында, аяклары (табан аслары) белән тыгыз итеп канатны кыскан. Яланаяк булган очракта, шуышу уңайлырак. Бала куллары белән өскәрәк тотына һәм, аякларын бөккән хәлдә, өскә таба шуышып тартыла. Аннары аякларын турайта. Бу хәрәкәтләр берничә тапкыр кабатлана.

**Күңелле ярышлар**

Уенда катнашучылар бер озын сызык артына 3-4 колонна булып тезелеп басалар. Һәр колоннаның алдына, 4-5 адым ара калдырып, гимнастика эскәмияләре куела, идәнгә кыршаулар салына. Сигнал булуга колонналарда беренче басып торучылар эскәмияләр янына йөгереп килеп, күрсәтелгән алым белән (корсакка ятып, тезләр һәм уч төпләрендә) эскәмия буйлап шуышалар. Аннан сикереп төшеп, кыршаулар янына йөгереп киләләр һәм аларны күтәреп, эченә керәләр, аннары идәнгә куялар да тиз генә колонналары артына барып басалар. Уенны колонналарда икенче булып басып торучылар дәвам итә. Биремне беренче булып тәмамлаучы команда җиңүче була.

**Читлектәге куяннар**

Бүлмәнең бер ягында идәнгә түгәрәкләр – «куян читлекләре» сызыла. Читлекләр алдына мүкәләп чыгу өчен дугалар куела. Каршы якта – «сакчы өе», анда «сакчы» утыра. Читлекләр белән өй арасында – «болынлык».

Тәрбияче балаларны 3-4 кешелек кечкенә төркемнәргә бүлә. Һәр төркем үзенең читлегенә кереп урнаша.

Тәрбияче: «Куяннар читлекләрендә утыралар», – дип белдерә. Балалар чүгәлиләр. Сакчы берәм-берәм һәр читлек янына килә һәм куяннарны уйнарга чакыра. Куяннар, читлек алдындагы дуга аркылы мүкәләп, болынга чыгалар һәм сикерешеп йөри башлыйлар. Күпмедер вакыттан соң тәрбияче: «Читлекләргә керегез!» – ди. Куяннар, кабат дугалар аркылы мүкәләп узып, үзләренең ояларына керәләр. Сакчы аларны кабат читлекләрдән чыгарганчы, куяннар ял итеп тора (бу вакытта идәнгә утырып торырга мөмкин).

Уен ярдәмендә тәрбияче балаларның үз урыннарын дөрес, тиз таба белү күнекмәләрен үстерә. Балалар мүкәләргә, ике аякта сикерергә, йөгерергә өйрәнәләр.

## ЫРГЫТУ ҺӘМ ТОТЫП АЛУ УЕННАРЫ. ТУПЛЫ УЕННАР

*Туплы, ыргытулы уеннар* ярдәмендә балалар туп тәгәрәтеп уйнарга, бер-берсенә туп тапшырырга, гәүдәне уңга һәм сулга борырга, хәрәкәт итүче бер ноктага атып тидерергә өйрәнәләр.

**Туп уйнау**

*(3-4 яшьлек балалар белән)*

1 нче уен

Балалар ярымтүгәрәк тәртибендә басып торалар, ә тәрбияче аларга чиратлап туп ыргыта. Әгәр бала тупны тотып алса, ул чүгәли һәм тупны киредән тәрбиячегә тәгәрәтә. Әгәр ул тупны тотып ала алмаса, туп артыннан йөгереп барып аны тәрбиячегә китереп бирә.

2 нче уен

Бу уен беренче уен кебек үткәрелә, ләкин балалар тупны тәгәрәтмиләр, бәлки тәрбиячегә ыргыталар. Балалар кулыннан туп ике тапкыр үткәннән соң, тәрбияче тупны ераккарак ыргыта, ә балалар аны барып алалар. Аннан соң балалар тупны тәрбиячегә бирәләр, уен яңадан кабатлана.

3 нче уен

Балалар түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына тартма куела. Балалар зур тупны тартмага ыргыталар. Башта балалар тупны тартмадан 2 адым ераклыктан ыргыталар, соңыннан ара 4-5 адымга кадәр ерагайтыла.

4 нче уен

Балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче түгәрәкнең уртасында торып, зур тупны һәрбер балага чират белән ыргыта, ә бала аны тәрбиячегә кире ыргыта. Ыргытуны 1,5 м ераклыктан алып, аз-азлап 2 – 2,5 м га кадәр җиткерәләр.

**Туп уйнау**

*(5-7 яшьлек балалар белән)*

**Икәүләп, өчәүләп, дүртәрләп уйнау:**

1.Бүлмәнең төрле урыннарына утырып, тупны бер-берләренә тәгәрәтеп уйнау.

2.Төрле урыннарда торып, тупны бер-берләренә ыргытып уйнау.

**Күмәк уеннар (10-15 кеше катнашында):**

*1. Түгәрәктә уйнау.*

Уйнаучылар, бер-берләре белән җитәкләшеп, түгәрәккә тезеләләр. Уртага зур туп куела. Балалар бер-берләренә тупны тәгәрәтеп уйныйлар. Әгәр дә кемнең дә булса тубы түгәрәктән чыгып китә икән, ул бала уеннан чыга, шулай ук тупны югары чөюче дә уеннан төшеп кала.

Уен барышында аерым төр мускуллар, бигрәк тә кул һәм аяк мускуллары чыныга, күз белән чамалау хисе үсә.

*2. Төзәп ыргыту.*

Стенага кәгазьдән түгәрәк (яки квадрат) ясап ябыштыралар. Уйнаучылар стенадан билгеле бер ара калдырып басалар да, түгәрәккә төбәп, тупны тидерергә тырышып, ыргыталар. Һәр уйнаучы үз чиратында өч тапкыр ыргыта. Бер тапкыр да тидерә алмаган бала отылган булып санала.

*3.Туп бирешү.*

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр һәм, бер-берләреннән 2-3 адым ара калдырып, кара-каршы басалар (ике рәткә тезеләләр). Һәр рәттә беренче булып басып торучыларга зур туп бирелә. Алар: «Бер, ике, өч!» – дип саныйлар һәм тупны, бер-берләренә тапшырып, рәт буенча җибәрәләр. Туп ахырда басып торучыга килеп җиткәч, анысы, тиз генә, тупны кире җибәрә. Һәр туп, шулай итеп, рәт буенча 3 тапкыр барып кайта. Кайсы төркем биремне алдан эшләп бетерә, шул җиңүче була.

**Түгәрәктә туп уйнау**

Балалар, бер-берләреннән ике кул сузымы ара калдырып, түгәрәкләнеп тезеләләр. Һәр бала үзе тирәли әйләнә сыза. Тәрбияченең «Башла!» дигән сүзеннән соң, балалар зур тупны бер-берсенә бирә башлыйлар. Әгәр берәр уенчы тупны кулыннан төшереп җибәрсә, ул түгәрәгендә чүгәләп утырырга тиеш була һәм. үзенә яңадан туп килеп җиткәнгә кадәр, утырып тора. Туп түгәрәкне 2-3 кат әйләнеп чыкканнан соң, уен тәмамлана.

Уен гәүдә мускулларын һәм кулларның җитезлеген үстерә.

**Тупны тот!**

Балалар түгәрәк ясап тезеләләр. Тәрбияче түгәрәкнең уртасына баса һәм кулындагы зур тупны чиратлап әле бер, әле икенче балага ыргыта. Балалар, үз чиратларында, тупны тәрбиячегә кире ыргытырга тиешләр. Башта тупны ярты метрдан ыргытып, соңрак, балаларның мөмкинлекләренә карап, 1,5 метрга (зуррак төркемнәрдә 3 метрга) кадәр җиткерергә мөмкин.

**Тупны төшермә!**

Туп 15 – 20 см диаметрлы, йомшак һәм җиңел булырга тиеш.

Балалар түгәрәк ясап басалар. Тәрбияче – уртада, аның кулында туп. Ул тупны чиратлап әле бер, әле икенче балага ыргыта. Балалар тупны тотып алырга һәм кире тәрбиячегә кайтарырга тиешләр. Тупны шулай ук түгәрәк буйлап та җибәрергә була. Бу очракта балалар бер-берсеннән берәр адым ераклыкта басарга тиешләр. Тупны тотып ала алмаган яисә кулыннан төшереп җибәргән бала вакытлыча уеннан чыгып тора.

**Яхшырак тыңла**

Балалар түгәрәкләнеп, бер-берсе арасында бераз урын калдырып, басып торалар. Бер баланың кулында зур туп. Тәрбияче сигналы буенча балалар тупны уңга (яки сулга) җибәрәләр – бер-берсенә тапшыралар. Тупны йөртү юнәлеше һәрвакыт тәрбияче сигналы буенча (кул чабу) үзгәртелә. Сигнал көтелмәгәндә бирелә, шуңа күрә балалар игътибарлы булырга, тупны йөртү юнәлешен бик тиз генә үзгәртергә тиеш булалар.

**Тупны тәгәрәт!**

Уен өчен зур туп кирәк булачак.

Балалар, бер-берләреннән кул сузымы ара калдырып, түгәрәк ясыйлар һәм тезләнеп утыралар. Тәрбиячегең «Башла!» дигән сүзен ишетү белән, алар үзләре теләгән якка бер-берсенә тупны җирдән тәгәрәтәләр. Үзенә туп тәгәгәрәп килгән һәр бала кулы белән тупны этеп җибәрергә тырыша. Әгәр бала тупны этеп җибәрергә өлгермичә, туп аның берәр җиренә тисә яисә түгәрәктән чыкса, ул бала түгәрәктән бер адым читкә чыгып утыра. Әлеге уенчыга туп яңадан килгән очракта, ул тупны кулы белән этеп җибәрә һәм үз урынына килеп утыра ала.

Тәрбияче балаларның тупны ыргытмыйча, бары тик тәгәрәтеп кенә җибәрүләрен һәм аның һаман бер үк балалар арасында (кулында) йөрмәвен күзәтергә тиеш.

**Тупны җибәрмә!**

Балалар бер-берсенә кул сузарлык ара калдырып түгәрәккә җыелалар һәм, кулларын артка куеп, иңбашлары киңлегендә аякларын аерып басалар. Йөртүче түгәрәк уртасына урнаша һәм тупны кайсы да булса бер уйнаучының аяк арасыннан тәгәрәтеп җибәрмәкче була. Үзенә таба туп килгән бала, аягын тиз генә янәшә куеп, тупны аяк арасыннан чыгармаска тиеш. Йөртүче исә, тупны бер балага җибәргән булып кыланырга, ә чынлыкта аны бөтенләй башка балага җибәрергә мөмкин. Тупны аяк арасыннан уздырган бала түгәрәктән бер адым кырыйгарак чигенеп баса, вакытлыча уеннан чыга.

2-3 бала тупны аяк арасыннан уздырса, уен тәмамланган булып исәпләнә.

Башта йөртүче ролен тәрбияче үзе башкарырга тиеш.

**Төклетура** (шмель)

Уенда катнашучылар зур түгәрәк ясыйлар, идәнгә утыралар һәм түгәрәк эчендә бер-берләренә туп тәгәрәтәләр.

Бер бала «төклетура» итеп билгеләнә. Ул, уенчыларның берәрсен «чагарга» (тупны аягына тидерергә) тырышып, тупны ике кул белән үзеннән тәгәрәтеп җибәрә. Берәү дә төклетурадан чактырырга теләми: тупны аягына тидермичә, кул белән тотып алып, башка берәүгә тәгәрәтергә тырыша. Кемнең аягына туп тия (чагылган бала), шул түгәрәк уртасына аркасы белән борылып утыра да башка бала чагылганчы уенда катнашмый. Бүтән бала чагылганнаң соң, ул уенны дәвам итә ала.

*Искәрмә.* Тупны кул белән этеп идәннән тәгәрәтергә кирәк. Ыргытырга ярамый.

**Тупны бау аркылы ыргыт**

Балаларның югары күтәрелгән куллары биеклегендә бау сузыла. Баудан 50 см ераклыкта ике якта да бер-бер артлы 3-5 сызык сызыла. Баудан икешәр адым ераклыкта уйнаучылар тезелеп басалар. Уенның барышы түбәндәгедән гыйбарәт:

Кара-каршы тезелеп баскан балалар бер-берләренә бау аркылы туп бирешәләр. Уен кагыйдәсе буенча туп бирешү билгеле бер тәртип белән алып барыла: беренче рәттәге беренче бала тупны каршы яктагы рәттәге беренче балага ыргыта, ул тупны тотып алып, кире шул ук балага ыргыта, анысы кире беренче балага ыргыта, бу бала аны үзенең

күршесендәге балага бирә; ул исә каршы яктагы рәттәге икенче балага бирә һ.б. Уен шул рәвешле ике рәттәге барлык балалар уйнап бетергәнче дәвам итә.

Тупны оста ыргытучы (бер тапкыр да җиргә төшермәгән) балалар берәр адым артка чигеп басалар, ә тубы кулыннан төшеп киткән балалар уенны элеккеге урыннарыннан дәвам итәләр.

Тупны җиргә төшермичә кара-каршы уйнагаган ике бала (бер пар), иң соңгы сызыкка җиткәннән соң, уен тәмамлана. Әлеге пар уенда җиңгән булып санала.

**Тупны тотып ал**

Балалар мәйданчыкта уйнап йөриләр: йөгерәләр, сикерәләр. Тәрбияче кулында зур туп, ул читтәрәк тотып басып тора. Тәрбияче бер баланың исемен әйтә дә тупны югарыга чөя, ә исеме әйтелгән бала тупны тотып алырга һәм, башка берәүнең исемен әйтеп, аны яңадан чөяргә тиеш. Тупны исеме әйтелгән бала тотып ала, һәм уен шулай дәвам итә. Тупны бер тапкыр да җиргә төшермичә тотып ала алган балалар җиңүче була.

**Тупны тап**

Барлык уйнаучылар, йөзләре белән уртага карап, түгәрәккә тезеләләр. Санамыш ярдәмендә сайланган бер уйнаучы түгәрәк уртасына баса. Ул уенны алып баручы була.

Уйнаучылар кулларын артка куеп торалар. Тәрбияче бер баланың кулына туп тоттыра. Шуннан соң балалар тупны арттан бер-берсенә тапшыра башлыйлар. Түгәрәк уртасында торучы бала тупның кемдә икәнен белергә тырыша. Моның өчен ул теләсә кайсы уйнаучыга: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Бу таләп буенча уйнаучы кулларын (учларын өскә каратып) тиз генә алга суза. Шул вакытта тубы кулында булган (яки аны кулыннан идәнгә төшереп җибәргән) бала уртага баса, ә аның урынын уенны алып баручы ала.

Тупны теләсә кайсы якка – уңга яки сулга, әмма күршеңә генә тапшырырга рөхсәт ителә. Аны бер кеше аша тапшырырга ярамый.

Уйнаучылар саны 18-20 булганда, уен җанлырак, күңеллерәк үтә.

Уен ярдәмендә балаларда күзәтүчәнлек, җитезлек сыйфатлары тәрбияләнә.

**Туп кемдә?**

Уен өчен кечкенә, кызыл төстәге туп кирәк.

Балалар түгәрәк ясап басалар. Араларыннан берсе йөртүче була. Ул – уртада. Йөртүче күзләрен йома һәм түбәндәге шигырь юлларын әйтә. Бу вакытта балалар тупны тиз-тиз генә бер-берләренә бирәләр.

Тубым, тубым, тупкай,
Син бик матур, кызылкай,
Тәгәрәп кулыма кер,
Кулдан-кулга күчеп йөр,
Ә хәзер – тукта!

Шул сүзләрне әйтеп бетергәннән соң, туп бирү туктатыла. Барлык балалар кулларын артка яшерәләр, туп туктап калган бала да кулларын артка куя. Йөртүче күзләрен ача һәм тупның кемдә икәнен әйтә. Исеме әйтелгән бала. кулларын ачып, башка балаларга

күрсәтә. Әгәр туп ул балада булмаса, йөртүче башка балага күрсәтә (3-4 тапкыр күрсәтергә мөмкин). Әгәр инде йөртүче туплы баланы дөрес әйтә алса, ул туплы бала урынына баса, ә тегесе йөртүче була. Әгәр белә алмаса, ул җиңелгән санала, һәм уен кабатлана.

**Туп ыргытыш**

I в а р и а н т. Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр. Алар, бер-берләреннән 3-5 м ара калдырып, кара-каршы басалар. Басасы урын сызык белән билгеләнә. Санамыш яисә җирәбә ярдәмендә уенны башлап җибәрүче билгеләнә. Ул үз төркеменнән бер баланың исемен әйтә һәм тупны аңа ыргыта. Ә тегесе, тупны тотып алып, аны каршы төркемдәге балага (исемен әйтеп) ыргыта. Әгәр дә бу бала тупны тота алмаса, ул уеннан чыгарыла, ә уенны дәвам итү хокукы тупны ыргыткан командада кала. Иң күп уйнаучысы калган төркем җиңүче була.

II в а р и а н т. Балалар ике төркемгә бүленәләр, 3-5 м ара калдырып, кара-каршы басалар. Тупны каршы яктагы балага ыргыталар. Әлеге бала тупны тота алмаса, ул үз командасыннан күрше командага күчә, үзенә туп ыргыткан бала янына баса. Иң күп уйнаучы җыелган команда җиңүче була.

**Тукта!**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы билгеләнә. Ул, туп тотып, уртага баса һәм туп белән төрле күнегүләр эшли. Бу вакытта балалар бишкә кадәр санийлар. «Биш» дигәндә, төрлесе төрле якка йөгереп китәләр. Туплы бала: «Тукта!»- дип кычкыра, бу вакытта уйнаучылар туктап калырга тиешләр. Туплы бала, урыныннан кузгалмыйча, үзенә якынрак торган балага тупны ыргытып тидерергә тырыша. Туп тигән бала уенны алып баручы була. Әгәр дә алып баручы тупны берәүгә дә тидерә алмаса, ул тупны куып тотарга тиеш, ә балалар аннан тагын да ераккарак йөгерергә тырышалар. «Тукта!» дигән сигналга барлык уенчылар туктап калалар, алып баручы кабат тупны кемгә дә булса тидерергә тырыша. Уен шулай дәвам итә.

***Уенның кагыйдәсе***

Әгәр дә берәр бала «Тукта!» сигналыннан соң да хәрәкәтләнүен дәвам итә икән, ул алып баручыга таба бер адым ара якынаеп басарга тиеш.

**Аягыңа тидермә**

Уйнаучылар, түгәрәк ясап, идәнгә (җиргә) тезләнеп утыралар. Тәрбияче, кулына туп алып, аны балаларның берәрсенә таба тәгәрәтеп җибәрә. Бала, тупны аягына тидермәс өчен, аны үз яныннан икенче балага таба төртеп җибәрә. Ул да, үз чиратында, тупны үз яныннан төртеп җибәрә һәм уен шулай дәвам итә. Тупны үз яныннан төртеп җибәрергә өлгермичә, аягына (тәненә) тидергән яки түгәрәк тышына чыгарган бала оттырган булып исәпләнә, һәм ул түгәрәктән бер адым читкә чыгып утыра. Түгәрәк читендә утыручы бала үз ялгышын «акларга» тырыша. Моның өчен ул үзе янына тәгәрәп килә торган тупны уңышлы төртеп җибәрергә тиеш. Шуннан соң ул яңадан үз урынына (түгәрәккә) барып утыра.

Уенның дәвамы 4-5 минут.

Бу уен ярдәмендә балаларда тотнаклылык, игътибарлылык, җитезлек кебек сыйфатлар тәрбияләнә. Балалар тупны тәгәрәтеп уйнарга өйрәнәләр.

*Искәрмә*

* Тупны уң һәм сул кул белән дә, ике кул белән дә тәгәрәтергә ярый, ләкин ыргытырга ярамый.

**Туплы әбәк**

Мәйданчыкта сызык сызып яки флаглар белән чик ясала. Уйнаучылар, бер-берсеннән кул сузымы ара калдырып, мәйданчыкның уртасында түгәрәккә тезеләләр. Уйнаучы балаларның берсе уенны алып баручы була, ул түгәрәкнең уртасына баса. Аның аягы янына кечкенә (диаметры 6-8 см) ике туп куела.

Уенны алып баручы нинди хәрәкәтләр башкарырга кирәклеген әйтә яки аларны сүзсез генә үзе ясап күрсәтә (чүгәли, иелә, кул чаба һ. б.). Уйнаучылар, уенны алып баручының сүзенә яки аның күрсәтүенә карап, тиешле хәрәкәтләрне башкаралар. Тәрбияче, көтмәгәндә: «Йөгердек!», – ди, һәм уйнаучылар, таралышып, мәйданчыкның чикләре эчендә йөгерә башлыйлар. Уенны алып баручы, баскан урыныннан кузгалмыйча гына, бер тубын кулына ала да аны, йөгереп качучыларга ыргытып, тидерергә тырыша. Беренче туп берсенә дә тимәсә, ул икенче тупны алып ыргыта.

Аннан соң балалар, тәрбияченең «Бер, ике, өч! Түгәрәккә тезелдек!» дигән сүзләре буенча, яңадан түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы итеп икенче бала сайлана, уен кабатлана.

Уенны 3-4 тапкыр кабатларга мөмкин. Уенның гомуми дәвамлылыгы 6-8 минуттан артмаска тиеш.

**Кайнар бәрәңге**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уен музыка астында уйнала. Уртача зурлыктагы туп – «кайнар бәрәңге» – кулдан-кулга йөри. Һәркем аны тизрәк иптәшенә бирергә тырыша. Музыка туктаганда ул кем кулында калса, шул бала уеннан чыга. Уенда иң озак калган бала җиңүче була.

**Ашарга ярый – ашарга ярамый**

Балалар бер рәткә тезелеп басалар. Аларның каршысына, берникадәр ара калдырып, тәрбияче баса. Аның кулында туп. Тәрбияче тупны балаларга чиратлап ыргыта һәм берәр предмет исемен атый. Әгәр ул ашарга яраклы ризык булса, бала тупны тотып алырга тиеш, ашарга ярамаса – тотмый. Әлеге шарт үтәлгән очракта, уйнаучы бала бер адым алга баса. Әгәр уен шарты бозылса, ягъни ашарга яраклы ризык исеме аталганда тупны тотмаса яки ашарга яраксыз предмет исемен атаганда тупны тотып алса, бала урынында кала.

Тәрбияче янына кем беренче килеп җитә, шул җиңүче була.

**Мин беләм биш исем**

Уен чиратлап уйнала. Берәү уйнаганда, башкалар карап, күзәтеп торалар. Уен өчен яхшы сикерә торган резина туп кирәк.

Балалар түгәрәкләнеп басалар, бер бала түгәрәк уртасына чыга. Аның кулында туп. Әлеге балага берәр тема тәкъдим итәләр (кызлар, малайлар, шәһәр, авыл исемнәре, агач, чәчәк, уенчыклар һ.б. исемнәр әйтергә). Ул тупны билгеле бер ритм белән җирдә сикертә һәм түбәндәге сүзләрне кабатлый: «Мин беләм биш исем: Алия – бер, Гөлия – ике, Сәвия – өч, Сания – дүрт, Галия – биш!»

Шул сүзләрне әйтеп бетергәнче, уйнаучы тупны ритм белән сикертеп торырга тиеш. Балалар бергәләп санайлар. Әгәр уен ахырына кадәр туп тәгәрәп китсә, яисә бала исемне атый алмый югалып калса, ул уенда җиңелгән санала. Уртага икенче бала чыга, уен дәвам итә.

## АЗ ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР

*Аз хәрәкәтле уеннар* нәниләрнең хәрәкәт үсешенә йогынты ясый, алар балаларның игътибарлылыгын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, дикъкатен арттырырга, тапкырлык, зиһенлелек үстерүгә, күрү, ишетү әгъзаларының камилләшүенә зур ярдәм итә. Әлеге уеннар ярдәмендә балаларда сабырлык, түземлелек, кыюлык, намуслылык кебек әхлакый сыйфатлар да тәрбияләнә. Кайвакытта мондый уеннар күп хәрәкәтле уеннардан соң балаларны тынычландыру, ял иттерү өчен дә кирәк булалар.

**Сүзне әйтеп бетер**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Уртага яулык тоткан йөртүче керә. Ул бер бала янына килә дә берәр кеше исеменең беренче иҗеген әйтә һәм яулыкны бирә. Бала, яулыкны тотып алып, сүзнең ахырын әйтеп бетерергә тиеш була (Фә-рит, Ай-рат, Мәрь-ям һ.б.). Сүзне әйтеп бетерә алмаган бала утыра һәм, дөрес әйткәнче, утырган килеш уйный. Барлык балалар берәр тапкыр җавап биргәч, уен тәмам була.

Уенны төрле вакытта төрле темалар белән бәйләп тә уйнарга мөмкин. Мәсәлән, бер уйнаганда – хайваннарга, икенче вакытта – үсемлекләр, урман, шәһәргә һ.б. бәйле сүзләрне атарга мөмкин.

**Кулларыңны сакла!**

Уйнаучылар, бер-берсеннән бер адым ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр. Тәрбияче уенны алып баручыны билгели; ул түгәрәк уртасына баса. Балалар кулларын, учларын югарыга каратып, алга сузалар. Тәрбияченең «Кулыңны сакла!» дигән сигналы буенча уенны алып баручы берәр баланың учына кагылырга тырыша. Уйнаучы, уенны алып баручының кулына кагылырга җыенуын сизүгә, кулларын артка яшерә.

Уенны алып баручыны учларына кагылдырган балалар оттырган булалар. Оттыручылар саны 2-3 кә җиткәч, уенны алып баручы үзе урынына бүтәнне сайлый (ләкин оттыручылардан түгел) һәм аның белән урынын алмаша.

***Уенның кагыйдәсе***

1. Кулларны һаман артта тотарга ярамый.

**Кемдә калды?**

Уйнаучылар түгәрәк ясап басалар. Өч балага шакмаклар (яисә башка тотарга уңайлы уенчык) бирелә. Музыка уйный башлый. Балалар шакмакларны бер-берләренә бирәләр. Һәркем шакмак үзендә калмасын өчен тырыша. Кинәт кенә музыка туктый. Кулларында шакмак калган балалар җиңелүче була, алар уеннан чыга.

Уен биш бала калганчы дәвам итә. Алар иң җитез балалар дип билгеләнә.

**Нәрсә бар икәнен бел**

Балалар. түгәрәк ясап, идәнгә утыралар һәм кулларын артларына куялар. Тәрбияче балалар тирәсеннән йөри һәм, чиратлап, барысының да кулларына вак уенчыклар (мәсәлән, шакмак, кечкенә шар, туп, карандаш һ.б.) куеп чыга.

Уйнаучыларның максаты – әйберне капшап карап тану һәм аның исемен дөрес әйтү. Тәрбияче бер баланың исемен әйтә, ә ул бала, кулындагы уенчыгын күрсәтми генә аның исемен әйтергә һәм аннан соң гына уенчыкны балаларга күрсәтергә тиеш була. Әйберне ялгыш атаган бала уеннан чыга бара. Түгәрәктә утырып калган балалар – иң сизгерләр һәм игътибарлылар.

**Хәйләкәр төлке**

Уйнаучылар бүлмә буйлап таралып басалар. Бер бала «төлке» итеп билгеләнә. Балалар түбәндәге шигырь юлларын сөйлиләр: «Нечкә билле, көлтә койрыклы, үзе ялагай, үзе хәйләкәр». Бу вакытта төлке ашыкмый гына балалар арасында йөри. Текст бетүгә («хәйләкәр» сүзеннән соң), төлке кайсы да булса бер баланың артына барып чүгәли. Теге бала төлке була.

Уен шулай дәвам итә.

**Тиз әйт!**

Уен балаларның фикер йөртү тизлеген арттырырга, зиһеннәрен үстерергә ярдәм итә.

Уйнаучылар урындыкларда утыралар. Уенны алып баручы аларның каршыларына баса. Уен башлангангач, ул бер бала янына килә дә: «Агач!» – ди. Утырып торган бала тиз генә берәр агач исемен атарга тиеш була. Әгәр әйтә алса, ул алып баручы белән урынын алмаша – уенны алып баручы була. Уен дәвам итә. Инде хәзер алып баручы башка темага караган берәр сүз атый, мәсәлән, «Чәчәк», «Гөмбә», «Кош» һ.б. Сорау бирелгән бала тиз генә җавап бирә алмаса, алып баручы өчкә кадәр саный һәм, җавап алынмаган очракта, башка балага мөрәҗәгать итә. Дөрес җавап алынганчы уен дәвам итә.

**Куян**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала түгәрәк уртасына баса. Ул – «куян».

Куян уйнаучылар каршында уйнап, сикергәләп йөри. Балалар түгәрәк буенча йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Кыш көне ак,
Җәй көне соры.
Урманнан чыгар,
Кыр буйлап чабар.

Куян, шуны гына көтеп торгандай, түгәрәктән сикереп чыкмакчы була. Балалар туктап калалар һәм, куянны чыгармас өчен, куллары белән тотынган хәлдә чүгәлиләр.

**Игътибарлы бул!**

Уйнаучылар, бер-берсеннән кул сузымы ара калдырып, түгәрәккә басалар. Балалар белән бергә түгәрәктә тәрбияче дә басып тора: ул балаларга төрле хәрәкәтләр ясап күрсәтә. Балалар тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне кабатлыйлар. Тәрбияче нинди хәрәкәтләрне кабатларга ярамау турында балалар белән алдан сүз куеша, мәсәлән, кулларны югарыга күтәрмәскә, чүгәләмәскә һ.б. Тыелган хәрәкәтне кабатлаучылар түгәрәктән бер адым читкә чыгалар, ләкин уенда катнашуны дәвам итәләр. Уйнаучы икенче тапкыр ялгышса, түгәрәктән тагын бер адым читкә чыга. Икенче тапкыр күрсәткәндә, уйнаучы ялгышмаса, ул түгәрәк үзәгенә таба бер адым атлый. Уен түгәрәктән 3-5 уйнаучы чыкканнан соң тәмамлана.

Бер тапкыр да ялгышмаучылар җиңүче булып исәпләнәләр.

**Мәзәкчеләр**

Балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче уйнаучыларның берсен «мәзәкче» (уенны алып баручы) итеп билгели. Башта мәзәкче ролен тәрбияче үзе башкара. Ул түгәрәк уртасына барып баса. Тәрбияченең кушуы буенча балалар түгәрәк буйлап уң яки сул якка әйләнеп йөри башлыйлар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Түгәрәккә басабыз,
Уңга, сулга барабыз.
Туктыйбыз да кабатлыйбыз
Күрсәткәнчә апабыз.

Бу сүзләрдән соң түгәрәк киңәя төшә. Балалар түгәрәккә бер-берсеннән кул сузарлык ара калдырып басалар.

«Апабыз» дигән сүздән соң, барысы да туктый: мәзәкче берәр нинди хәрәкәт күрсәтә, түгәрәктә торучылар исә ул хәрәкәтне кабатлыйлар. Аннан соң тәрбияче мәзәкчене алмаштыра яки мәзәкче үзе урынына берәр иптәшен сайлый, һәм уен дәвам итә.

**Артта кем тора?**

Балалар бер-берләренең иңбашларына куллары белән тотынып, колоннага тезелеп басалар. Колоннаның алдына уйнаучыларга арты белән уенны алып баручы баса. Шул вакытта балаларның кайсы да булса берсе шыпырт кына колоннаның артына барып баса да, артта кем торганны алып баручы белмәсен өчен, аңардан яшеренә. Ул бала яшеренгәч, балалар: «Булды!» – дип кычкыралар. Алып баручы колоннага йөзе белән борыла һәм артта кем торганын белергә тырыша. Арттагы баланы алып баручыга күрсәтмәскә тырышып, колонна һаман боргаланып тора.

Әгәр алып баручы артта кем торганны белә алса, яшеренгән бала алып баручы була һәм уен кабатлана.

Уенны 5-6 тапкыр кабатларга мөмкин.

**Ялгышма!**

Барлык уйнаучылар, тәрбияче белән бергә кулларын өстәлгә куеп, өстәл тирәсендә тезелешеп утыралар. Тәрбиячелең «Шакылдатыгыз!» дигән сүзеннән соң, барысы да бармаклары белән өстәлгә шакылдата башлыйлар. «Югарыга!» дигән сүзне ишеткәннән соң, бармакларын югары күтәрәләр. Тәрбияче, төрле хәрәкәтләр әйтеп, уенны балалар белән берничә тапкыр кабатлый. Аннан соң, әйтелгән хәрәкәтләрне ясамыйча, балаларны буташтыра башлый (мәсәлән, «Югарыга!» дигәндә кулларын өстәл астына яшерә һ.б.). Балалар исә, хәрәкәтләрне тәрбияче хәрәкәтләренә ияреп түгел, ә сүзләрне тыңлап ясарга, бик игътибарлы булырга тиешләр. Ялгышкан бала уеннан читләштерелә, өстәл яныннан торып, читтән күзәтеп тора.

**Кайнар кул**

Балалар түгәрәк ясап тезеләләр. Араларыннан берсе «кайнар куллы» йөртүче була. Ул түгәрәк уртасында тора. Барлык балалар уч төпләрен өскә таба каратып, кулларын түгәрәк эченә таба сузалар. Йөртүче түгәрәк буйлап йөри һәм, көтмәгәндә, бер баланың кулына әкрен генә суга. Балалар исә, ул якынайганда, кулларын артка яшерергә тырышалар. Йөртүче берәр баланың кулына суга алса, ул бала түгәрәктән бер адым читкә чигенә яисә аңа җәза бирелә. 2-3 бала отылганнан соң, икенче кайнар куллы йөртүче сайлана һәм уен дәвам итә.

**Бакчада нәрсә үсә?**

Балалар түгәрәккә тезелешеп басалар. Тәрбияче (соңрак берәр бала) уенны алып баручы була. Ул бакчада үсә торган җиләк-җимеш, яшелчәләр һәм башка үсемлекләрнең исемнәрен атый. Балалар белән нинди хәрәкәтләр ясау турында алдан килешенә. Мәсәлән, җиләк-җимеш исеме әйтелгәндә – кул чабарга, яшелчә исеменә кулларны өскә күтәрергә һ.б.

Барлык балалар, алдан билгеләнгән килешү буенча, тиешле хәрәкәтләр ясыйлар. Тәрбияче ара-тирә башка предмет исемнәрен дә әйткәли. Бу вакытта балалар аякларын тыпыртадырга (яисә башка төрле берәр хәрәкәт ясарга) тиеш булалар. Кем дә кем, ялгышып, тиеш булмаган хәрәкәт ясаса, ул уеннан читләштерелә яки аңа җәза бирелә.

**Чишмә**

Уенда балалар саны так булырга тиеш.

Бер бала әйдәүче итеп билгеләнә. Башка балалар, парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар, җитәкләшкән килеш, кулларын өскә күтәрәләр. Әйдәүче иң беренче пар алдына килеп баса, күтәрелгән куллар аша әкрен генә чыга башлый һәм бер баланы үзе белән алып китә. Алар, икәүләп, чишмәнең ахырына кадәр җитәләр һәм, җитәкләшеп, артка басалар. Парсыз калган бала йөртүче була.

Уенны салмак музыка астында уйнарга мөмкин.

**Җиләк, гөмбә, чикләвек**

Балалар үзләрен урманда дип хис итәләр. Алар җиләк, гөмбә, чикләвек җыярга килгәннәр. Җиләк җыю өчен, гәүдәне билдән бөгеп, кулларны җиргә сузарга, гөмбә җыю өчен – чүгәләргә, чикләвек өчен кулларны өскә таба – куакка сузарга кирәк. Тәрбияче аңлатканнан соң, уен башлана. Ул тиз-тиз генә: «Җиләк, гөмбә, чикләвек!» – дип кабатлый. Балалар буталмыйча тиешле хәрәкәтләрне ясыйлар. Беркадәр күнеккәннән соң, тәрбияче сүзләрнең урыннарын алмаштыра. Ялгышкан бала уеннан чыга.

**Нәрсә яшерелгән?**

Уен балаларның игътибарын, күрү хәтерен үстерүгә ярдәм итә.

Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларга (яисә идәнгә) утыралар. Уенны алып баручы түгәрәк уртасына берничә (4-5) уенчык куя һәм аларны истә калдырырга куша. Аннан соң балалар урыннарыннан торалар, уртага артлары белән борылып күзләрен йомалар. Шулвакыт уенны алып баручы түгәрәк уртасындагы бер әйберне яшерә. «Карагыз!» дигән сигналдан соң балалар күзләрен ачалар һәм нинди әйбер яшерелгәнен искә төшерергә тырышалар. Алып баручы һәр баланың янына килә, бала аның колагына нинди уенчык яшерелүен әйтергә тиеш. Берничә бала дөрес җавап биргәч, алып баручы яшерелгән әйбернең исемен барлык балалар да ишетерлек итеп әйтә.

Уен яңадан башлана.

## ЭСТАФЕТА, ЯРЫШ УЕННАРЫ. УЕН-АТТРАКЦИОННАР

Уеннар арасында ярышлы уеннар, уен-эстафеталар аерым урын алып тора. Әлеге уеннарның нәтиҗәсе күз алдында: кемдер җиңә, кемдер җиңелә. Шуңа да мондый уеннарны балалар бик яратып уйныйлар. Уен вакытында бала куелган шартны үтәп чыгарга, максатны күз алдында тотып хәрәкәт итәргә һәм аңа ирешергә, иптәшләре белән бергә җиңү яуларга омтыла. Шулай итеп, бала үзенең ихтыярын чыныктыра, түземле, сабыр булырга өйрәнә.

Ярышлы уенарның максаты – балаларда җитезлек, тизлек, өлгерлек, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү, аларның хәрәкәт координациясен үстерү, бер-берләренә карата ихтирамлы, дустанә мөнәсәбәт булдыру.

Ярышлы уеннарны, эстафеталарны оештырганда, түбәндәге *кагыйдәләрне истә тоту зарур:*

- Старт сызыгыннан сигнал булгач кына йөгереп китәргә кирәк, сигналдан алды йөгереп чыгарга, эстафетаны кабул итәргә ярамый.
- Ярышны беренче команда алдан тәмамласа да, икенче командадагы уенчылар биремне ахырына кадәр үтәми торып, уенны тәмамларга ярамый.
- Биремне беренче булып, хаталарсыз тәмамлаган команда җиңүче була.

**Гөмбә җыябыз**

Идәнгә төрле гөмбә муляжлары (яисә гөмбә рәсеме ясалган карточкалар) куела. Балалар ике төркемгә бүленәләр. Һәр төркемдә әйдәүче билгеләнә, аларга кәрзиннәр

бирелә. Тәрбияче сигналы буенча, һәр ике төркемдәге балалар гөмбә җыя башлыйлар. Алар кәрзингә ашарга яраклы гөмбәләрне генә салырга тиешләр. Ахырдан һәр ике төркемнең кәрзине бергәләп тикшерелә. Гөмбәләрне тиз һәм иң күп җыйган төркем җиңүче итеп билгеләнә.

**Чорналыш**

Балалар 2-3 төркемгә бүленәләр. Һәр төркемдә 5-6 бала. Алар бер рәткә тезелеп басалар. Сигнал булуга, һәр командада беренче басып торган бала тиз генә үз урынында әйләнеп ала, аннары икенче уенчы аның биленә тотына һәм алар икесе бергә әйләнәләр, аннары өченче бала һ.б. Уен шулай дәвам итә. Иң соңгы басып торучы бала белән бергә әйләнгәннән соң, ярыш тәмам була.

**Энә күзе**

Балалар 2-3 командага бүленәләр. Командалар каршысына җиргә бер-берсеннән берникадәр ара калдырып, өч кыршау салына. Сигнал булуга, һәр командадан бер бала беренче кыршауга кадәр йөгереп килә, аны күтәреп, эченә керә (энә күзенә җеп кергән кебек) һәм, тиз генә чыгып, икенче кыршауга таба йөгерә. Икенче, өченче кыршау белән дә шул ук күнегүләр эшләнә. Күнегү кире кайтканда да кабатлана. Беренче уенчы үз командасы янына йөгереп кайткач, уенны икенче (өченче һ.б.) бала дәвам итә. Биремне иң тиз башкарган команда җиңүче була.

**Яңа урын**

Ике команда колоннага тезеләләр. Алардан 15-20 м ераклыкта сызык сызыла. Сигнал булуга, колоннада беренче һәм икенче булып басып торган балалар, җитәкләшеп, каршы якка йөгерәләр. Беренче уенчы сызык артында басып кала, икенчесе йөгереп кире кайта һәм, өченче бала белән җитәкләшеп, ярышны дәвам итә. Каршы якка беренче булып күчеп беткән команда җиңүче була.

**Игезәкләр**

Балалар, парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Аннары бер-берләренә артлары белән борылалар һәм, җилкәләрен нык итеп терәп, куллары белән тотынышалар. Сигнал булгач, уенчылар ян яклары белән билгеләнгән урынга таба йөгерә башлыйлар. Җилкәләр уен ахырына кадәр бер-берләреннән аерылырга тиеш түгел. Билгеләнгән урынга беренче булып килгән команда җиңүче була.

**Бакалар сикерешә**

Барлык уйнаучылар бер рәткә (алдан сызылган сызык артына) тезелеп басалар һәм, чүгәләп, куллары белән тезләрен кочаклыйлар. Алар – «бакалар«. «Сикерергә!» дигән команда булу белән, барысы да каршы яктагы сызыкка таба сикерешә башлыйлар. Кем беренче булып финишка барып җитә, шул җиңүче була.

Уенны бераз катлауландырырга да була. Мәсәлән, бишәр кешедән торган берничә төркем билгеләп, кайсы төркемнең барысы бергә беренче булып финишка барып җитүен билгеләргә мөмкин. Бу очракта җиңүче – финишка беренче булып килеп җиткән төркем.

**Сазлык**

Командаларга икешәр кыршау бирелә. Һәр командада өч бала бер төркем булып берләшә. Алар кыршаулар ярдәмендә сазлык аша үтәргә тиешләр. Сигнал булуга, төркемнән бер бала кыршауны җиргә ташлый. Өч уйнаучы да аның эченә сикереп керәләр. Хәзер инде алар икенче кыршауны аның эченә сикереп керерлек ераклыкка ыргытырга һәм икенче кыршаудан чыкмый гына беренче кыршауны үрелеп алып, аны тагын җиргә ыргытырга тиешләр. Шулай итеп, кыршауларны әле җиргә ташлап, әле алар эченә сикереп кереп, төркем билгеләнгән урынга – борылышка кадәр барып җитә. Кире кайтканда, уйнаучылар «күпер» аша кайталар: кыршауларны җирдән тәгәрәтеп баралар. Старт сызыгына килеп җиткәч, кыршаулар икенче төркемгә бирелә. Уенны алар дәвам итә. Иң җитез команда җиңүче була.

***Уенның кагыйдәсе***

* Кыршауның кырыена басарга ярамый: сазлыкта батуың ихтимал.

**Сазлык аша чыгу**

Ике төркемнән берәр балага аяк табаны зурлыгындагы картон бирелә. Шул картонга баса-баса, билгеләнгән урынга барып җитәргә һәм, кире йөгереп килеп, иптәшеңә бирергә кирәк. Ул уенны дәвам итә. Иң беренче тәмамлаган команда җиңүче була.

**Сикеркеч белән йөгер**

Балалар, бер-бер артлы басып, ике колоннага тезеләләр. Алда басып торучыга кыска сикергеч бирелә. Старт сызыгы сызыла.

Сигнал булуга, беренче булып басып торган бала алдан әйтелгән алым белән (ике адымга сикергечне бер әйләндереп, һәр адым саен әйләндереп, ике аякта сикереп барып һ.б.) сикереп китә. Ул билгеләнгән урынга кадәр (урындык, зур уенчык, флаг һ.б.) сикереп килә, аны урап узып, кире команда янына сикереп (яисә йөгереп) килә һәм сикергечне икенче булып басып торган балага бирә дә, үзе колонна артына барып баса. Уенны сикергеч белән икенче бала дәвам итә. Сикерү барышында сикергеч кимендә 10-12 тапкыр әйләндерелергә тиеш. Биремне иң беренче булып һәм хаталарсыз башкарган команда җиңүче була.

**Пингвиннар**

Балалар, ике командага бүленеп, старт сызыгы артына бер-бер артлы тезелеп басалар. Аларның кулларында комлы янчыклар. Тәрбияче сигнал бирүгә, уйнаучылар янчыкларын ике тез арасына кыстыралар да билгеләнгән урынга кадәр ике аякта сикереп китәләр. Кайсы команда беренче булып җыела һәм бер-бер артлы тезелеп баса, шул җиңүче була.

**Туп йөртү**

Залның бер башыннан икенче башына ике сызык сызыла. Алар өстенә, бер-берләреннән 1 м ара калдырып, 6-8 уенчык (шакмаклар, туплар, кеглялар һ.б.) куела.

Уенчылар, ике колоннага бүленеп, старт сызыгы артына басалар. Һәрберсенең кулында кечкенә туплар. Сигнал булуга, беренче булып басып торучылар, тупны идәнгә

бәрә-бәрә, һәрбер уенчыкны әйләнеп узып, финиш сызыгына (шнур, бау) таба баралар. Аннары, кире килеп, үз колоннасының артына басалар. Беренче бала финиш сызыгына басуга, уенны икенче уенчы дәвам итә. Җиңүче колонна билгеләнә.

**Кара-каршы**

Мәйданчыкның ике башындагы старт сызыгы артына ике команда тезелеп баса. Тәрбияченең сигналы буенча, ике командадан да берәр бала (беренче булып басып торучылар), идәннән туп алып, сул һәм уң кулларын чиратлаштырып, тупларны бәрә-бәрә, каршы як командасына таба бара. Колоннаның артыннан узып, колонна башына килә һәм тупларны алда басып торучы балага тапшыра, үзе каршы як колоннаның ахырына барып баса. Тупларны алган бала күнегүне кабатлый. Ярыш шулай дәвам итә. Уйнаучылары тизрәк алышынып беткән команда җиңүче була.

**Кайсы команда беренче?**

Балалар, ике командага бүленеп, бер-бер артлы тезелешеп басалар. Һәр командадан беренче булып басып торучы уенчы (кулларында туп), каршыда куелган кәрзингә кадәр йөгереп барып, тупны кәрзингә сала; кире йөгереп килеп, икенче басып торган уенчыга кулы белән кагыла – эстафетаны тапшыра. Икенче уенчы, йөгереп барып, тупны кәрзиннән ала һәм чираттагы уенчыга тапшыра.

Ярыш шулай дәвам итә.

**Тупны төшермә**

Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм, парлашып, кара-каршы басалар. Алар, кулларын бер-берсенең җилкәсенә куеп, маңгайлары белән туп кыстырып, билгеләнгән урынга кадәр йөгереп барырга, кире килеп, тупны икенче парга тапшырырга тиешләр. Барган вакытта туп төшсә, балалар аны күтәреп алалар, яңадан маңгай араларына кыстырып, ярышны шул урыннан дәвам итәләр.

Эстафета вариантлары:

- туп эчләре белән кыстырыла, куллар җилкәләргә куела;
- кулларны терсәкләр белән беркетеп, туп аркалар белән тотыла һ.б.

**Футбол**

Уен өчен зур туп, дуга, 2 кәрзин, чикләвекләр кирәк булачак.

Балалар колоннага басалар. Алар каршында киңлеге 60-65 см булган капка куела. Капканың икенче ягында «куян» тора. Балалар капка аша куянга тупны тәгәрәтәләр. Кемнең тубы, капкага бәрелмичә, куянга барып җитә, аңа чикләвек бирелә. Куян да тупны балаларга тәгәрәтә. Әгәр аның тубы да капкага бәрелмичә балаларга барып җитсә, аның кәрзиненә дә чикләвек салына. Уен ахырында, ике кәрзиндәге чикләвекләрне санап, җиңүчене билгелиләр.

**Тапшыр да торып бас**

Уйнаучылар, бер-берсеннән кул сузымы ара калдырып, ике колоннага тезеләләр. Колонналар арасы ике адым була. Колонналар алдыннан сызык сызыла. Тәрбияче

колонналарда беренче булып торучы балалар алдына (сызык өстенә) ике туп куя. Тәрбияченең «Утыр!» дигән сигналы буенча балалар барысы да, аякларын бөкләп, идәнгә утыралар. «Тапшыр!» дигән сигнал буенча колоннада беренче булып утыручы, идәннән тупны ала да җилкә аша артта утыручыга тапшыра, шуннан соң, торып басып, йөзе белән колоннага таба борыла. Тупны алучы, үз чиратында, тупны шулай ук җилкә аша арттагы иптәшенә тапшыра һәм, аякларына басып, йөзе белән колоннага таба борыла. Туп колоннада соңгы булып торучы балага барып җиткәнче уен дәвам иттерелә.

Тупны ахырга кадәр идәнгә төшермичә тапшыра алган һәм туп соңгы уйнаучыга беренче булып килеп җиткән команда җиңгән булып исәпләнә.

Уен 3-4 тапкыр кабатлана. Тәрбияче кайсы колоннаның ничә мәртәбә җиңүче булуын билгели.

Бу уен ярдәмендә балаларда бер-берсенә ярдәмләшү хисе, җитезлек һәм игътибарлылык тәрбияләнә. Балаларның җилкә һәм арка мускуллары ныгый.

*Уенга күрсәтмәләр*

1. Уенны кабатлаганда, тәрбияче һәрвакыт колонналар алдында басып торырга тиеш.

2. Тупны җилкә аша гына түгел, бәлки, гәүдәне борып, уң яки сул яктан да тапшырырга мөмкин.

**Тупны ал**

Уйнаучылар 3-4 командага бүленәләр. Һәр командада 5-6 бала. Алар, бер-бер артлы тезелеп, идәндә сызылган сызык артына басалар. Һәр команда каршысына, 1,5-2 м ара калдырып, әйдәүче баса. Әйдәүчеләрнең кулларында зур туплар. Әйдәүчеләр, тәрбияче сигналы буенча, тупларын командада беренче булып басып торучы балаларга ыргыталар. Алары үз чиратында тупны тотып алырга, шунда ук аны кире әйдәүчегә ыргытырга һәм тиз генә идәнгә утырырга тиешләр. Аннары тупны әйдәүче командада икенче булып басып торган балага ыргыта, һәм уен шулай дәвам итә. Әйдәүче, тупны командада иң соңгы булып басып торучы баладан алуга, ике кулына тотып, аны баш өстенә күтәрә. Бу моментта командадагы балалар барысы да тиз генә идәннән торып басарга тиешләр. Биремне дөрес һәм иң тиз үтәгән команда җиңүче була. Уен кабатланганда икенче әйдәүчеләр билгеләнә.

**Күбәләк корты (гусеница)**

Мәйданчыкта старт сызыгы сызыла. Балалар ике командага бүленеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Алар каршысына, бер-берләреннән берникадәр ара калдырып, 5-6 предмет (уенчыклар, флаглар яки башка әйбер) куела. Һәр уенчы үз алдында торган иптәшенең җилкәсенә кулларын куя да, балалар барысы бергә чүгәлиләр. Сигнал булганнан соң, һәр команда, каршылыкларны әйләнеп уза-уза, билгеләнгән урынга барып җитәргә һәм кире үз урынына килергә тиеш. Хәрәкәт вакытында кулларны ычкындырырга яисә торып басарга ярамый.

**Кайсыгыз тизрәк тасманы ала?**

Мәйданчыкта сызык сызып куела. Балалар сызык артына 4-5 кешелек бернichә колоннага тезеләләр. Колонналарга каршы, 10-15 адым ераклыкта, бау тартырыла. Бау кулларын югары күтәреп торган балаларның бармак очларыннан 10-15 см биеклектә булырга тиеш.

Һәр колонна каршысына шул бауга тасмалар эленә.

Тәрбиячедән «Йөгер!» дигән сигналыннан соң колонналарда беренче булып торучы балалар бау янына йөгереп баралар һәм, югарыга сикереп, баудан үз тасмаларын тартып алалар. Тасманы иң алдан тартып алган бала откан булып санала. Тәрбияче тасмаларны яңадан бауга элә. Бау янына чираттагы балалар йөгерәләр.

Барлык балалар да берәр тапкыр тасманы алгач, уен тәмамлана. Һәр колоннадагы отышлар санала.

**Кем тизрәк кегляны ала?**

Урындыкка кегля куела. Урындыктан 8-10 адым ераклыкта аның ике ягына каракаршы ике уенчы баса. Сигнал булгач та, алар, йөгереп килеп, кегляны алырга тырышалар. Кем беренче алып өлгерә, шул җиңүче була.

**Коткару түгәрәге**

Мәйданчыкның бер башында старт сызыгы сызыла, икенче башына флаг беркетелә (яисә берәр уенчык куела). Болар – «елга ярлары». Уйнаучыларга ике кыршау – «коткару түгәрәге» («спасательный круг») бирелә. Балалар ике төркемгә бүленәләр, һәр төркемнән капитаннар билгеләнә. Аларның максаты – үз командасындагы уенчыларны тизрәк бер «ярдан» икенче «ярга» күчерү.

Капитаннар коткару түгәрәкләрен кияләр – кыршауның уртасына кереп басып, аны ике кул белән бил турысында тоталар һәм, сигнал булгач, билгеләнгән урынга йөгереп китәләр. Ике команданың да капитаны, флагны әйләнеп узып, старт сызыгына кире килә һәм командадан бер уенчы кыршау эченә баса да алар каршы якка бергә йөгерәләр. Капитан, аны ярда калдырып, икенче уенчы артыннан килә. Уен команданың барлык уенчылары да каршы як ярга күчеп беткәнче дәвам итә. Беренче булып күченеп беткән төркем җиңүче була.

**Бәрәңге утырту һәм җыю**

Каршыга, ара калдырып, кыршаулар тезелә. Болар – «бәрәңге салу өчен чокырлар». Кәрзингә кыршау санынча «бәрәңге» салына һәм беренче уенчыга тапшырыла. Сигнал булгач, беренче уенчы, кәрзиннән бәрәңгене алып, чокырга салып бара. Аннары йөгереп килеп кәрзинне икенче уенчыга тапшыра. Икенче уенчы кәрзингә бәрәңгеләрне җыя.

**Өлгер бала**

Уенда дүрт бала катнаша. Тәрбияче: «Әти-әниләрегезгә, әби-бабайларыгызга булышканда, сез һәрвакыт башыгызга яулык бәйлисез, алдыгызга алъяпкыч ябасыз. Шул эшне кем тизрәк башкарыр икән, сынап карыйк әле», – ди. Ике балага берәр алъяпкыч

һәм косынка бирә. Алар, күзләре бәйләнгән килеш, каршыда торган балага алъяпкыч белән косынканы бәйләргә тиешләр. Кайсы пар биремне беренче булып тәгәлли, шул җиңүче була.

**Кыршаулар белән уеннар**

*1. Кыршауларны түгәрәктә тәгәрәтү.*

Тәрбияче, түгәрәк уртасына баскан хәлдә, балаларга таба кыршауны тәгәрәтә. Балалар чиратлап кыршауны кире тәрбиячегә таба тәгәрәтәләр.

Уенны катлауландыру өчен бер-бер артлы ике кыршауны тәгәрәтергә мөмкин.

2. Балалар ике төркемгә бүленәләр, арада зур гына буш урын калдырып кара-каршы басалар. Бер төркем балаларның кулында кыршаулар. Тәрбияченең «Бер, ике, өч» диюенә яки башка берәр сигнал буенча, балалар кулларыңдагы кыршауларны үзләренә каршы баскан балаларга тәгәрәтәләр. Уен шул рәвештә берничә тапкыр кабатлана.

*3. Кыршауларны алмашу.*

Бу уен югарыда күрсәтелгән уен шикелле үк үткәрелә, тик монда уенда катнашучыларның һәрберсенә кыршау бирелә һәм һәр бала кыршауны үзенең каршысындагы балага (парына) тәгәрәтеп җибәрә. Кара-каршы баскан ике бала бер үк вакытта кыршауларын бер-берсенә тәгәрәтәләр. Кыршаулар каршы килеп бәрелмәсеннәр өчен һәр бала үз кулындагы кыршауны уң кулы белән тәгәрәтергә тиеш.

*4. Кыршауны кем ераграк тәгәрәтер?*

Уенга катнашучылар барысы да бер сызык өстенә басалар һәм, тәрбияче сигнал биргүгә, кулларындагы кыршауларны тәгәрәтәләр. Кемнең кыршавы ераграк тәгәрәсә, тәрбияче шул баланы искә ала.

*5. Куышып узышу*

Ике станция билгеләнә. Тәрбияче сигналы буенча бер станциядән «велосипедлар» (кыршау тәгәрәтүче балалар) чыгалар һәм, куышып, тизрәк икенче станциягә җитәргә тырышалар. Бу куышу 2-3 бала һәм шулай ук 10-12 бала арасында да булуы мөмкин. Шул ук уенны уйнаучыларны бер рәткә тезеп тә үткәрергә була.

*6. Тимер юл.*

Озын туры сызык – «тимер юл» сызыла. Бу юлдан «поездлар» йөриләр. Тәгәрәтеп җибәрелгән кыршау шушы сызыктан гына барырга тиеш. Сызыктан читкә чыккан кыршау «ремонтка» бирелә – юлдан кире кайтарыла.

*7. Юлда барганда шалтырат!*

1 нче в а р и а н т. Уенга катнашучы балаларның һәрберсе җиргә сызылган түгәрәккә бер-берсеннән 1 метр чамасы ераклыкта ара калдырып басалар. Алда 2-3 метр чамасы ераклыкта бауга тагылган кыңгырау була. Кыршауны тәгәрәтеп баручы һәр бала, бу бау астыннан үткәндә кулы белән бауга тотынып, кыңгырауны шалтыратып үтә. Бу шалтырату артта баскан балага кыршавын тәгәрәтеп йөрергә мөмкинлекне белдергән сигнал була – балалар бер-бер артлы кыршауларын тәгәрәтеп, кыңгыраулы бау астыннан чыгалар.

Балаларга төрле төстәге тасмалар тагылган матур кыршаулар бирелә. Тасмаларга кечкенә кыңгыраулар тагылса бигрәк тә яхшы.

Уенда катнашучы барлык балалар зур түгәрәк ясыйлар – басалар да кыршауларын җиргә бастырып куялар (кабыргасы белән). Тәрбияче сигнал биргүгә, барлык балалар, баскан урыннарыннан кузгалмыйча, кыршауларын бергә әйләндереп җибәрәләр. Кемнең кыршавы аумыйча озак әйләнеп барса, шул бала искә алына һәм ул. уенны яңадан кабатлаганда, сигнал бирүче була.

*Уенның кагыйдәсе*

• Уенны башлап җибәргәнче, тәрбияче балаларга кыршауны ничек итеп әйләндереп җибәрергә (бер урында бөтергеч шикелле) кирәклекне күрсәтә.

2 нче в а р и а н т. Югарыда күрсәтелгәнчә бизәкләнгән бер зур кыршау алына. Балалар түгәрәкләнеп басалар, ә тәрбияче, кыршауны тоткан хәлдә, түгәрәк уртасына баса. Тәрбияче кыршауны бөтергеч шикелле әйләндереп җибәрә дә шул вакытта түгәрәккә баскан балалардан берсенең исемен әйтә. Чакырылган бала түгәрәкне йөгереп әйләнә һәм, әйләнүдән туктап, кыршау ауганчы аны тотып өлгерергә тиеш. Әгәр бала кыршау ауганчы аны тотып өлгерсә, уенны кабатлаганда бу бала, кыршауны тотып алу өчен, үзе теләгән баланы сайлый. Әгәр бала кыршау ауганчы тотып өлгермәсә, яңадан үз урынына барып баса, һәм түгәрәктән икенче баланы тәрбияче үзе чакырып чыгара.

## СПОРТ УЕННАРЫ

### КЫШКЫ УЕННАР

Хәрәкәтле уеннарны кыш көннәрендә урамда үткәрү бик мөһим. Кышкы саф һава һәм һавада хәрәкәтләнү баланың авырулар белән көрәшүчәнлеген һәм ныклыгын арттыра, аның организмына уңай тәэсир итә. Кыш көнендә һавада хәрәкәтләнү сулыш алуны көчәйтә, матдәләр алмашуын яхшырта.

Кыш көне чаңгы, чана шуарга, алар белән төрле уеннар оештырырга мөмкин. Биредә үтәлергә тиешле иң мөһим шартларның берсе – балалар һава торышына карап киенгән булырга, аларның киемнәре хәрәкәтләнергә комачауламаска тиеш. Шулай ук артык тиз хәрәкәтләнеп тирләү, яисә аз хәрәкәтләнү нәтиҗәсендә туңудан сакланырга кирәк.

Кышкы уеннарны сайлаганда аларның күмәк, барлык балалар да берьюлы катнаша алырлыкларына игътибар итәргә кирәк. Чөнки уенда үз чиратын көтеп яисә уеннан вакытлыча читләштерелеп торган бала туңарга һәм уен белән кызыксынмаска мөмкин.

**Кыш көнендә саф һавада уйнау, күңел ачулар**

1. Чана тартышып уйнау.
2. Чана белән таудан шуу.
3. Чаңгыда йөрү.
4. Кардан төрле сыннар ясау.
5. Кар бабай әвәләү.
6. Бозлы юлчыктан шуу.
7. Кар атышып уйнау һ.б.

**Йөгереп кит!**

Уйнаучылар арасыннан уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәк ясап басалар. 2-3 бала түгәрәкнең уртасына урнаша. Аларның аяк очларында икешәр кар йомарламы ята.

Уенны алып баручы берничә хәрәкәт ясый (чүгәли, кулларын өскә күтәрә, сикерә һ.б.), ә түгәрәктә басып торучылар әлеге хәрәкәтләрне кабатлыйлар. Тәрбияче: «Йөгереп кит!» – дип сигнал биргәч, балалар алдан сөйләшеп билгеләнгән чиккә кадәр төрле якка йөгереп китәләр. Бу вакытта түгәрәкнең эчендә басып торучы балалар аларны куалар һәм кар йомарламнары белән аталар. Кар йомарламы тигән балалар уеннан чыга баралар. Тәрбиячевнең сигналы булуга уйнаучылар яңадан түгәрәккә җыелалар. Кемгә күпме кар йомарламы тидерелгәне ачыклана. Бер кар йомарламы да тидертмәгән балалар арасыннан яңа алып баручы сайлана. Уен 5-6 тапкыр кабатлана.

*Уенның кагыйдәсе*

Карны йөгереп китүчеләрнең аякларына гына да атарга мөмкин.

**Ыргыт!**

Уен җепшек көндә уйнала.

Балалар кар шарчыклары әвәлиләр. Аннары ике төркемгә бүленәләр дә ике түгәрәк ясап басалар. Түгәрәкләрнең бер-берсеннән арасы – 2-3 адым. Эчке түгәрәктәге балаларның һәрберсенең аяк очында кар шарчыклары була. Тәрбиячевнең сигналы булуга, тышкы түгәрәктәге балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк буйлап йөри башлыйлар, эчке түгәрәктәге уйнаучылар тик торалар. Тәрбиячевнең «Ыргыт!» дигән сүзен ишетү белән, тышкы түгәрәктәге балалар төрле якка йөгереп китәләр, ә эчке түгәрәктәгеләр аларга кар белән аталар. Сигнал булуга, кар ату тәмамлана һәм ничә балага кар йомарламы тидерелгәнлеге исәпләнә. Шуннан соң уйнаучылар урыннарын алмашалар, һәм уен кабатлана. Кар шарчыкларын күбрәк балага тидергән төркем җиңүче була.

**Кыш бабай**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Уйнаучылар арасыннан Кыш бабай сайлана. Кыш бабай, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, акрын гына түгәрәк уртасында йөри:

Ап-ак озын сакаллы
Бу менә мин – Кыш бабай.
Эзләп сезне урманда,
Йөрим инде ничә ай.

Тиз йөгереп килсеннәр
Миңа кирәк җәнлекләр!

Түгәрәктә торучы балалар: «Син нинди җәнлекне эзлисең соң? – дип сорыйлар. Кыш бабай: «Куяннарны эзлим», – ди.

Түгәрәктә торучы балалар куяннар кебек сикерешәләр. Бераз сикергәч, Кыш бабай: «Хәзер мин сезне тотам!» – ди. Куяннар йөгерешеп китәләр, ә Кыш бабай аларның берсен куып тота.

Уен яңадан башлана. Бу юлы Кыш бабай башка бер җәнлекне (мәсәлән, тиеннәрне, аюларны, боланнарны һ.б.) эзләвен дәвам итә. Балалар шул җәнлекләрнең хәрәкәтләрен (мәсәлән, аюлар алпан-тилпән йөри, тиеннәр вак-вак сикерешеп йөриләр, боланнар бик тиз йөгерәләр һ.б.ны) күрсәтәләр.

Тотылган җәнлекләрне Кыш бабай бер читкә алып китә, уен кабатланганда, алар яңадан түгәрәккә тезеләләр.

**Кыш бабай белән Җәй кызы**

Санамыш ярдәмендә Кыш бабай һәм Җәй кызы сайлана. Балалар мәйданчык буйлап таралышып, уйнап йөриләр (бию хәрәкәтләре ясыйлар, сикерәләр һ.б.). Сигнал булуга, Кыш бабай аларны куа башлый һәм тоткан баланы «туңдыра». Туңдырылган бала туктаган хәлендә хәрәкәтсез калырга тиеш. Берничә бала туңдырылганнан соң, сигнал буенча Җәй кызы чыга. Ул хәрәкәтсез торган балалар янына килеп, аларга кулы белән кагылганнан соң, алар «җанланалар» – хәрәкәткә киләләр. Әгәр дә Кыш бабай Җәй кызын да тотса, ул да туңа. Уен барлык балалар туңдырылып беткәннән соң тәмам була.

**Чаналарга!**

Чаналарны мәйданчыкның бер ягына урнаштыралар. Аларның саны уйнаучылардан бергә кимрәк булырга тиеш. Мәйданчыкның икенче каршында балалар йөгереп йөриләр, әйләнәләр, сикергәлиләр. Тәрбияче «Чаналарга!» дип сигнал бирүгә, балалар чаналарга таба йөгерәләр һәм тиз генә берәр чанага утырырга тырышалар. Иң соңгы булып килгән бала урынсыз кала һәм отылган булып санала.

**Чаналар белән ярыш**

Ярышта 2-3 команда катнаша. Һәр командадан ике уенчы, бер-берләренә аркаларын терәп, чанага утыралар. Чананы аяклары белән этә-этә, алар тизрәк финишка барып җитәргә тырышалар. Аннары. йөгереп, стартка кайталар һәм чаналарын икенче пар уйнаучыларга тапшыралар. Эстафета өчен иң аз вакыт сарыф иткән команда җиңүче итеп билгеләнә

**Һөҗүмнән саклан!**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр һәм, бер-берсеннән 30-40 адым ара калдырып, кара-каршы ике рәт булып тезеләләр. Һәр баланың аяк очында кар йомарламы ята. Рәтләр алдына ике адым ераклыкта җиргә бау сузып салына. Һәр төркем үзенә җитәкче сайлый. Кайсы төркемнең алдан һөҗүм итүе, кайсы төркемнең кар атуы санамыш ярдәмендә билгеләнә.

Кар белән атарга тиеш булган төркем арты белән борылып баса да, икенче төркем аларга һөҗүм итәргә әзерләнә. Бу төркем сызык янына килеп җиткәч, төркемнең җитәкчесе арты белән торган төркем янына килә дә, йомшак кына итеп, шундагы бер баланың җилкәсенә орына. Бу бала «Ыргыт!» дип кычкыра, һөҗүм итүчеләр кире үз өйләренә йөгерә башлыйлар. Артлары белән торучы балалар, тиз генә әйләнеп, карларын алалар да качучыларга ыргыталар. Һөҗүм итүчеләр үз сызыклары артына кайтып беткәч,

кар тигән балалар саны исәпләнә. Аннан соң һөҗүмне икенче төркем башлый. Кайсы төркем кар шарчыкларын күбрәк тидерә, шул төркем откан булып санала.

Уенны 4-6 тапкыр кабатларга мөмкин.

**Кар шарчыклары**

Әлеге уен-ярыш өчен ике кәрзин кирәк булачак. Кәрзиннәр. уйнаучылардан берникадәр ара калдырып, җиргә куела. Балалар ике командага бүленәләр һәм бер үк санда (әйтик, һәр бала саен өчәр итеп) кар шарчыклары әзерлиләр. Ике команда да, бер-бер артлы тезелеп, кәрзиннәр каршына старт сызыгы артына басалар. Кар шарчыкларын старт сызыгы кырыена өеп куялар. Сигнал булу белән, чиратлап, шарчыкларны үзләренең кәрзиннәренә кертергә тырышып аталар. Кәрзиненә иң күп кар шарчыкларын керткән команда җиңүче була.

**Кар йомарламнары ташу**

Уен спорт мәйданчыгында уйнала.

Мәйданчык уртасына зур кыршау салына яисә түгәрәк сызыла (алдан төсле су катырып ясарга мөмкин). Дүрт почмакка диаметры 50 см булган кечерәк кыршаулар, ә аларның эченә уенчылар санынча кар йомарламнары салына. Уйнаучылар, дүрт төркемгә бүленеп, кечкенә кыршаулар янында билгеләнгән сызык артына килеп басалар. Сигнал булгач, һәр төркемнән бер бала кыршау эченнән кар йомарламын (берне) ала да уртадагы зур кыршауга таба йөгерә. Кар йомарламын кыршау эченә куйгач, тиз генә үз төркеме янына йөгереп килә. Ул килеп җитүгә, кар йомарламын алып, төркемнән икенче бала йөгереп китә. Уен шулай дәвам итә. Кар йомарламнарын иң беренче булып зур кыршауга ташып бетергән төркем җиңүче була.

**Кар йомарламын тидертмә!**

Мәйданчык уртасында бер-берсеннән 4-5 м ара белән ике параллель сызык сызыла. Уйнаучылар арасыннан бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул «коридор»га – сызыклар арасына баса. Аның кулында тоткалы кәрзин, кәрзингә берничә кар йомарламы салынган. Калган уенчылар бер сызыкның артына, уенны алып баручыга карап басалар. Тәрбияче сигналы буенча балалар, коридор аша үтеп, икенче сызыкка таба йөгерәләр, ә уенны алып баручы, аларга тидерергә тырышып, кар йомарламнары ата. Кар йомарламы тигән бала алып баручы ярдәмчесе була, һәм ул калган балаларга кар ата. Уен балаларның күпчелеге алып баручы ярдәмчесенә әйләнгәч, тәмам була. Бер тапкыр да кар йомарламы тидертмәгән балалар билгеләп үтелә.

**Кем төзрәк ыргытыр?**

Уен өчен алдан кар йомарламнары (яисә нарат күркәләре) әзерләнә. Уенны башлар алдыннан алып баручы балаларга кар йомарламнарын ничек тотарга һәм ыргытырга кирәклеген аңлата.

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртага кыршау салына яисә очларын бәйләгән баудан түгәрәк ясала. Аның диаметры – 1.5-2 м. Балалар бу түгәрәктән 1-2 адым ераклыкта

басып торалар. Аларның кулларында – кар йомарламнары. Уенны оештыручының «Ыргыт!» сүзеннән соң, барлык балалар да кар йомарламнарын түгәрәккә ыргыталар. Кар йомарламы түгәрәк уртасына төшкән бала төз атучы була. Уенны кабатлаганда, балалар кар йомарламнарын икенче кул белән ыргыталар.

Уенда балалар сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнәләр, уң һәм сул куллары белән ыргытырга күнегәләр.

**Бозларны тизрәк керт!**

Балалар 3-4 төркемгә бүленәләр. Төркем санына карап, мәйданчыкта түгәрәкләр сызыла. Төркемнәр үз түгәрәкләреннән 20-30 адым ераклыкта ярымтүгәрәк булып тезеләләр. Һәр баланың кулында кәшәкә (хоккей таягы) һәм берәр төсле боз кисәге (яки төрле төстәге шайба) була.

Тәрбиясенең сигналыннан соң балалар кәшәкәләре белән бозларын түгәрәкләренә кертергә тырышалар. Барлык бозларын үз түгәрәкләренә алдан кертеп бетергән төркем җиңүче була.

*Уенга күрсәтмә*

Һәр төркемнең бозлары билгеле бер төскә буялган булырга тиеш.

**Бозлы юл буйлап**

Берничә бала бозлы юл кырыена бер-бер артлы тезелеп баса. Аларның кулларында кәшәкә һәм төсле боз кисәге була. Балалар үзләренең боз кисәкләрен таяклары белән бозлы юл буйлап шудырып баралар. Максатлары – боз кисәген, юлдан читкә чыгарып җибәрмичә, бозлы юлның очына кадәр китереп җиткерү. Боз кисәген юлның очына кадәр уңышлы алып килә алган бала откан булып санала.

Уен кул җитезлеген үстерә.

**Шайбаны үткәрмә**

Балалар, бер-берләреннән кул сузымы ара калдырып, түгәрәк ясап басалар. Түгәрәк уртасына уенны алып баручы урнаша, аның аяк очында «шайба» – төсле боз кисәге ята. Алып баручы, балаларның аяк арасыннан үткәрергә тырышып, боз кисәген көч белән этеп җибәрә. Уйнаучылар шайбаны үткәрмәскә, ә аяклары белән бозны тотып калырга һәм кире алып баручыга этеп җибәрергә тырышалар. Әгәр дә боз кисәге кемнең дә булса аяк астыннан яисә ике бала арасыннан чыгып китсә, аларның берсе уртага керә, ә уенны алып баручы түгәрәккә баса.

Уенны кәшәкә белән уйнарга була.

**Алтынтау патшалыгы**

Уен өчен алдан, кар өеп, тау ясалган була. Тау артык биек һәм бозлы булмаска тиеш. Берничә бала, берсен-берсе этә-төртә, тауга менәргә тырышалар. Тау башына беренче менгән бала «патша» була. Ул башкаларны тауга менгермәскә тырыша, менгәннәрен төртеп төшерә бара. Кайсы да булса бала патшаның үзен таудан төшерә алса, ул патша була һәм уен дәвам итә.

**Чаңгычылар**

Уйнаучылар ике командага бүленәләр. Команда капитаннары чаңгыларга басалар һәм, сигнал булуга, билгеләнгән урынга кадәр баралар. Анда, чаңгыларын калдырып, стартка кайталар һәм эстафетаны икенче уенчыга тапшыралар (уенчының иң өстенә кагылалар). Икенче уенчы билгеләнгән урынга йөгереп бара, чаңгыларны кия һәм стартка кайта. Чаңгыларны өченче уенчы кия. Эстафета шулай дәвам итә. Эстафетаны иң аз вакытта тәмамлаган команда җиңүче итеп билгеләнә.

**Чаналар ярышы**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр. Ярыш өчен 5 м лы дистанция билгеләнә. Һәр төркемгә берәр чана бирелә. Чаналар старт сызыгы артына куела. Һәр төркемнән бер бала чанага утыра. Тәрбияче сигналы буенча чанада утырып торучы балалар, ике аяк белән кардан этелә-этелә, финишка таба хәрәкәтләнәләр. Финишка беренче килеп җиткән бала җиңүче була.

Уен төркемдәге башка балалар белән дәвам итә.

## КЕЧЕ САБАНТУЙ УЕННАРЫ

*Сабантуй уеннары* – балалар яратып уйный торган спорт уеннарының милли варианты. Әлеге уеннарны җылы яз көннәрендә яисә җәй башында үткәрергә мөмкин.

Сабантуйга әзерлек алдан ук башлана. Тәрбиячеләр, бакчаның башка хезмәткәрләре яулыклар, кулъяулыклар, сөлгеләр чигәләр. Балалар белән сабантуй турында җырлар, шигырьләр, төрле уеннар өйрәнелә. Бәйрәм вакытында үткәреләсе уеннар өчен кирәкле җиһазлар, мәсәлән, сөлгеләр, чүлмәк, капчыклар, агач кашыклар, бизәлгән агач йомыркалар һ.б. әзерләнә. Һәр уенны оештыру өчен җаваплы кеше (тәрбиячеләр) билгеләнә.

Сабантуй буласы мәйданчык бәйрәмчә бизәлә. Капкага «Сабантуй котлы булсын!» дигән язу, озын колгага чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар, төрле төстәге шарлар эленә.

Сабантуй бәйрәмендә татар халкының гомер-гомергә уйналынып килгән милли уеннары – көрәш, капчык киеп йөгерү, агач кашыкка йомырка салып йөгерү, кашык белән су ташу, тизлеккә йөгерү, аркан тартышу, капчык сугыштыру кебек ярыш төрләрен кертергә мөмкин.

**Татарча көрәш**

Көрәштә катнашырга теләгән малайлар, алдан ук парлашып, мәйданчыкның бер читенә барып басалар. Көрәш башланыр алдыннан хөкемдар (тәрбияче) беренче парны мәйдан уртасына чакыра. Ул көрәшчеләрнең исемнәрен атый һәм аларга билбаулар – сөлгеләр бирә. Сөлге, бер ягы озынрак калдырылып, уң кулның беләзегенә салына. Кыска башы аста кала. Сөлгенең озын ягы баш бармак белән имән бармак арасына кысып тотыла. Болай иткәндә, ул кулдан берничек тә шуып чыкмый.

Хөкемдар ике якның да әзерлеген тикшерә һәм, сыбызгысын икенче тапкыр сызгыртып, көрәшә башларга боера. Көрәшнең дәвамлылыгы – ике минут. Җиңгән бала билгеләп үтелә. Аннан соң икенче пар көрәш мәйданына чыга.  Уен дәвам итә.

*Искәрмә.*

Көрәш башланыр алдыннан түбәндәге шигырьләрне сөйләргә мөмкин:

* Көрәшәсем килә минем,
Сөлге тотып кулыма.
Әти әйтә: « Батыр булу
Килешер, – ди, – улыма.

* Билгә сөлге салабыз да
Көрәшергә чыгабыз.
Әле батыр булмасак та,
Үскәч, чынлап егарбыз!

*Нигә безгә көрәшмәскә,
Мәйдан тотмаска әле?
Көрәшик, әйдә, бергәләп,
Бүген бит яз бәйрәме.

* Сабантуенда уеннар
Төрле була, күп була.
Ә көрәшсез Сабантуе
Булмаган да күк була.

**Чүлмәк вату**

*Чүлмәк ватам, чүлмәк ватам,
Ватып булырмы икән?
Бүләккә бер чиккән яулык
Алып булырмы икән?

*Мактана дип уйламагыз,
Мин урынлы мактанам.
Чөнки менә бу чүлмәкне
Күз бәйләп тә вата алам.

Мәйданчык уртасында чүлмәк тора. Бәйгегә чыгучы бала чүлмәк янына килеп, аңа арты белән баса. Уенчының күзләрен бәйләп, кулына таяк тоттыралар. Аннан соң, бер кулыннан җитәкләп, 3-4 адым ясаталар да чүлмәккә таба борып бастыралар. Сигнал булгач, чүлмәк ватучы, килгәндәге 3-4 адымны санап, чүлмәккә таба бара һәм, туктап, чүлмәккә суга. Әгәр ул таягын чүлмәккә тидерә алса, чүлмәк ватылган дип санала. Чират буенча тагын берничә бала чүлмәк вату бәйгесендә катнаша. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырыла.

**Йомырка салынган кашык кабып йөгерү**

* Кашыкка салып күкәйне
Йөгерегез тизрәк.
Күрик әле, бу ярышта
Кайсыгыз җитезрәк?

* Кашык кабып йөгерәм дип,
Мактанырга ашыкма.
Ә син менә йөгереп кара
Күкәй салып кашыкка.

Җирдә старт сызыгы билгеләнә. Уенда катнашучылар сызык артына тезелеп басалар. Аларга агач кашыклар һәм агачтан, пластмассадан яки башка ватылмый торган материалдан ясалган йомыркалар (өстәл теннисы шарын да файдаланырга мөмкин) бирелә. Уйнаучылар, сигнал булу белән, кашыкның сабыннан гына тоткан килеш, йомырканы төшермәскә тырышып, алдан билгеләнгән урынга кадәр йөгерәләр. Кашыктан йомырканы төшермичә, старт сызыгына беренче булып килгән уенчы җиңүче була.

*Искәрмә.*

Юлда кашыктан йомырканы төшереп җибәргән бала старт сызыгына кире әйләнеп килә һәм йөгерүне яңадан башлый.

**Кашык белән су ташу**

* Менә сиңа агач кашык,
Су салырсың эченә.
Йөгер тизрәк, иң алдан кил,
Егыла гына күрмә!

* Иң җитезләр көч сынаша,
Бүләкләр – күбебезгә.
Кашык белән су ташыйк,
Сабантуй бүген бездә!

Уенда катнашучыларга кашыклар бирелә. Алар бер рәткә тезелеп басалар. Яннарында – сулы савыт. Һәрберсенең каршысына (билгеле бер арада) стакан куела. Уйнаучылар сигнал буенча стаканнарына су ташый башлыйлар. Кем тизрәк ташый һәм стаканын беренче булып тутыра, шул җиңүче була.

**Капчык сугышы**

* Ягез әле, икегезгә
Ике капчык тотыгыз.
Сабан туенда ярышып,
Сез дә бүләк отыгыз.

Җиргә алдан ук биеклеге 0,5, ә озынлыгы 1,5 м булган бүрәнә утыртыла. Бүрәнә астына гимнастика келәмнәре җәелә.

Ике уенчы, икесе ике яктан, бүрәнәгә атланып утыралар. Аларның кулларына паралон (яисә йомшак чүпрәк) тутырылган капчыклар бирелә. Сигнал булуга, уенчылар, капчык белән сугып, бер-берсен бүрәнәдән бәреп төшерергә тырышалар. Көндәшен бәреп төшереп, үзе егылмыйча калган бала җиңүче була.

**Капчык киеп йөгерү**

* Кемнәр өлгер, кемнәр җитез,
Минем янга килегез.
Әйдә карыйк ярышып,
Капчык киеп чабышып.

Балалар ике колоннага тезеләләр. Колонналар алдына старт сызыгы сызыла. Беренче булып басып торган балалар капчык эченә кереп басалар. Алар, сигнал булуга, капчыкларын ике яктан бил турысында тотып, билгеләнгән урынга кадәр (берәр уенчык яки флаг куелган) йөгерәләр. Аны әйләнеп үтеп, кире колонналарына кайталар һәм капчыкны икенче булып басып торучыга тапшыралар. Ярыш шулай дәвам итә. Биремне беренче булып төгәлләгән команда җиңүче була.

**Аркан тартыш**

* Бу ярыш та бик күңелле,
Тизрәк басыгыз әле!
Бауның ике башыннан
Йәгез, тартыгыз әле.

Ярышны ике бала яисә ике балалар төркеме арасында уздырырга мөмкин. Ике төркемдә дә катнашучылар саны бертигез булырга тиеш.

Мәйданчык уртасында сызык сызыла. Шул сызыкның ике ягына ике бала (ике төркем) урнаша. Аларның кулларында аркан (бау). Сигнал булу белән, һәр төркем бауны үз ягына таба тарта башлый. Уртадагы сызыктан кем ераграк китә, шул җиңүче дип санала.

**Таяк тартышу**

* Сабантуй елга бер килә,
Күңелле, олы бәйрәм!
Көчебезне сынап карыйк,
Таяк тартышып, әйдә!

Ике бала җирдә кара-каршы утыра һәм аяк табаннарын бер-берсенә тери. Аннан соң алар, кулларын алга сузып, озынлыгы 1 м, калынлыгы 2 см булган таякка тотыналар. Сигнал булу белән, уенчылар бер-берсен тартып торгызырга тырышалар. Җирдән күтәрелүче оттырган була.

*Искәрмә.*

Тартышканда кулларны таяктан ычкындырмаска кирәк. Ычкындыручы бала оттырган булып санала.

**Кем иң тиз йөгерә?**

* Кемдә нинди һөнәр бар?
Йөгерергә кемнәр бар?
Кызганмый табаннарны
Урагыз мәйданнарны.

4-5 бала старт сызыгы артына тезелеп басалар һәм, сигнал булу белән, мәйданчыкның икенче башында билгеләнгән финишка таба йөгерә башлыйлар (дистанция ераклыгы 10- 12 м тәшкил итә). Кем беренче финиш сызыгына барып җитә, шул төп җиңүче була. Шулай ук икенче, өченче килүчеләрне дә билгеләп үтәргә кирәк.

Уенны берничә төркем белән кабатларга мөмкин.

**Бүләк кисеп алу**

Бүләкләрне җеп белән ике колга арасына тартылган баугa элеп куялар. Уйнаучыларның күзләрен бәйлиләр дә кулларына тупас очлы кайчылар тоттыралар. Алар, күзләре бәйләнгән килеш, бау янына кадәр (бүләкләрдән ераклык 2-3 адым) барырга һәм бауга куелган бүләкне кайчы белән кисеп алырга (җепне кайчы телләре арасына кертергә) тиеш. Кул белән җепкә һәм бүләкләргә кагылырга рөхсәт ителми.

Бу уенны оештырганда идәннең (җирнең) тигез булуы шарт.

Уен төз хәрәкәт итү, урында ориентлашу күнекмәләре булдырырга ярдәм итә.

**Кул көрәше**

Мәйданчык уртасында кечкенә өстәл һәм аның капма-каршы якларында ике урындык куела. Шул урындыкларга ике бала утыра. Алар уң кулларының терсәкләре

белән өстәлгә таяналар. Сигнал булу белән, кулларын ярыштыра башлыйлар. Кемнең кулы иптәшенең кулын ега, шул җиңүче була.

*Искәрмә.*

Ярышкан вакытта икенче кул белән ярдәм итү тыела.

**Ат чабышы**

* Малайлар алып килгәннәр
Иң җитез юртакларны.
Кем беренче килер икән?
Бик тырыша атлары.

Берничә бала, уенчык ат башы беркетелгән таякларга атланып, старт сызыгына тезеләләр. Хөкемдарның сигналы буенча алар алдан билгеләнгән дистанция буенча йөгерә башлыйлар. Финишка иң алдан килгән «атка» һәм иң соңгы килгәненә истәлекле бүләкләр тапшырыла.

## ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫ

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында иң яратып уйнала торган уеннар – халык уеннары. Халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан бу уеннар балаларда өлгерлек, тапкырлык, кумәклек, ярдәмләшү, шулай ук кешелеклелек, шәфкатьлелек, сабырлык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли. Уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Уен вакытында балаларның иҗат мөмкинлекләре ачыла, мөстәкыйльлекләре арта, оештыру сәләтләре үсә. Кечкенә вакыттан алынган хәрәкәт күнекмәләре нәниләргә тышкы дөнья белән тирәнрәк танышырга ярдәм итә. Халык уеннары – җитезлеккә, көчкә, зирәклеккә сынау ул.

**Тургай, чыпчыклар**

Бер бала күзен йомып тора. Ул – «тургай». Калган балалар – «чыпчыклар» -бергәләп:

Тор, тор, тургай,
Таң ата бугай,
Тургай, кил, чыпчык, чык,
Чык-чырык, чык-чырык! –

диләр дә, төрлесе төрле җиргә качып бетәләр. Сигнал булуга, тургай «уяна» һәм чыпчыкларны эзләп китә. Кемне беренче булып тапса, шул күзен йома, һәм уен яңадан башлана.

**Мәче һәм тычкан**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Бер бала – «песи», икенчесе «тычкан» була.

П е с и. Мин атаклы песимен!
Тычкан, кусе эзлимен.
Т ы ч к а н. Ә мин – тычкан, кечкенә,
Табалмассың һич кенә.
П е с и. Минем күзләрем үткен,
Аякларым бик өлгер.
Борыным да бик сизгер.
Хәзер барып тотармын,
Тоткач кабып йотармын!
Т ы ч к а н. Әйдәле, куып кара,
Әйдәле, тотып кара!

Тычкан кача. Балалар, кулларын күтәреп, аны үткәреп җибәрәләр, ә мәчене үткәрмиләр, ул узачак капканы куллары белән ябалар. Мәче, тычканны эләктергәч, икенче балалар аларны алыштыра.

**Читекче**

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Уртада «читекче» куллары белән читек теккән сыман итеп көйләп утыра, хәрәкәтләр ясый һәм сөйли:

Итек, читек, энә, без,
Матур итеп тегәбез.
Кирәкмиме, алмыйсызмы,
Әллә киеп карыйсыз?

Түгәрәктәгеләр бар да беравыздан: «Кая, бир!» – диләр һәм бер якка таба түгәрәк буенча йөгерә башлыйлар. Тегүче утырган урыныннан тормыйча гына йөгерүчеләрнең аягына кулы белән тиеп калырга тиеш. Тия алса, аны урынына утыртып, үзе түгәрәккә керә, тидерә алмаса, яңадан «читекче» булып кала. Уен дәвам итә.

**Гөрләмеш, яки кача-кача**

Бер бала «гөрләүче» итеп билгеләнә. Аны берәр койма, яки өй почмагына, өйдә булса, почмакка илтеп гөрләтәләр. Бу урын барлык уйнаучыларга да «оя» була. Гөрләүче йөзе белән коймага яки почмакка карап баса һәм йөзен каплап болай ди:

Гөр-гөр гөрлимен,
Вакыт кубен белмимен,
Вакыт кубен белер идем,
Мин бит сезне күрмимен.
Инде озак гөрләдем,
Моннан ары түзмимен.

Әлеге сүзләр әйтелеп беткәнче, балалар качып өлгерергә тиеш. Алардан бер дә тавыш-тын килмәсә, гөрләүче эзли башлый. Ул кемне дә булса, берәр уйнаучыны күрсә, исеме белән кычкыра. Шуннан ул гөрләгән ояга кем алданрак килеп кулы белән кагылса, ул бала тотылмаган була. Әгәр дә гөрләүче ояга качучыдан алдан килеп баскан булса, йә качканда аркасына сугып өлгерсә, ул качучы отылган була да гөрләүче урынына баса. Гөрләүче барлык качучыларны да табып чыгаргач, уен тагын башлана.

**Ал кирәк, гөл кирәк**

Бу уен балаларның сөйләм телен үстерергә ярдәм итә, аларда иптәшлек, дуслык хисләре тәрбияли, кечкенәләрне туры юнәлештә йөрергә өйрәтә.

Балалар, ике төркемгә бүленеп, кулга-кул тотынышалар һәм кара-каршы басалар. (Ара ераклыгын үзләре билгелиләр.)

Бер якның балалары каршы яктагыларга түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Кабыргалы камчылар,
Ага торган тамчылар.
Ак кирәк, күк кирәк,
Бездән сезгә кем кирәк?

Каршы яктагы балалар, тиз генә бергә җыйналып, кемне чакырачакларын сөйләшеп алалар. Аннары, яңадан тезелеп, болай диләр:

Кабыргалы камчылар,
Ага торган тамчылар.
Ак кирәк, күк кирәк,
Кара кашлы, кара күзле,
Безгә Галия кирәк.
(Яки берәр малай исеме әйтелә.)

Чакырылган бала, каршы якка йөгереп барып, ике бала арасыннан үтәргә, аларның кулларын «өзәргә» тырыша. Өзеп чыга алса, ике баланың берсен җитәкләп алып, кире үз ягына кайта. Әгәр өзә алмаса, үзе шул якта кала.

Уен шулай дәвам итә.

**Тозак**

Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр. Бер төркемдә балалар саны икенчесеннән күбрәк булырга тиеш. Кечерәк төркем балалары түгәрәк ясыйлар. Бу – «тычканнар өчен тозак». Калган балалар – «тычканнар» булалар. Алар түгәрәкнең тышына басалар.

Тозак ясап баскан балалар түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, кулга-кул тотынышып, түгәрәк буйлап (әле уңга, әле сулга) йөриләр:

Аптыратты бу тычканнар,
Гел ишәя баралар.
Сиздерми тозак куярбыз,
Һәммәсен дә тотарбыз.

Бу сүзләрдән соң балалар туктыйлар һәм тотынышып торган хәлдә кулларын өскә күтәрәләр. Тычканнар тозак эченә кереп-чыгып йөгереп йөриләр. «Шап!» дигән сигналны ишетүгә, түгәрәктә басып торучылар тиз генә кулларын аска төшерәләр һәм чүгәлиләр. Димәк, тозак ябылды. Түгәрәктән чыгып өлгермәгән тычканнар тотылган булып санала. Алар түгәрәккә басалар (түгәрәк зурая). Тычканнарның күбрәк өлеше тотылып беткәч уйнаучылар рольләрен алмашалар. Уен кабатлана.

Уен ахырында тозакка бер дә эләкмәгән балалар билгеләнә.

### Әбәк

Балалар бер төркем булып басалар. Шунда бер бала: «Әбәк-чәбәк, тити суат, килеп юат!» – дип, иптәшләренең берсенә сугып китә. Шулай дигәч, барлык балалар әбәк бирелгән куучы янынннан йөгереп качалар. Куучы, аларның кайсын да булса тотып, әбәкне аларга бирергә тырыша. Әгәр бирә алса, әбәк бирелгән бала үз чиратында башкаларны куып китә.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

### Песи белән тычканнар

Бу да почмак алыш уеннарының бер төре. Уенда биш бала катнаша. Уйнаучыларның берсе «песи» була. Калган дүртесе, «тычкан» булып, почмакта урын алалар. Песи уртада тора. Тычканнар үз почмакларында торганда, ул аларга тимәскә тиеш. Тычканнар, йөгерә-йөгерә, урыннарын алмашып торалар. Шул чагында песи аларның берсен тотарга тырыша. Шуңа күрә урыннарын алмашырга теләгән тычканнар элек бер-берсенә күз белән яки кул белән ымлап, йә булмаса йөткереп, «Әйдә, урыннарны алмашабыз» дигән серне белдерәләр. Шулвакыт песи, башын аска игән, күзен йомган булып, астан гына аларны күзәтеп тора. Тычканнар, аннан көлеп, як-яктан такмаклыйлар:

Мияу-мияу мышнаган,
Мич башында кышлаган,
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде йоклаган.

Песи-песи поскан,
Ике күзен кыскан,
Кысса безне тоталмый,
Тотар иде, җиталмый...

Шулай дип җырлашкан арада, алдан ымлашкан буенча, берсе икенчесенең почмагына таба чаба башлыйлар. Шул чагында песинең күзләре ачыла, почмакка җиткәнче бер тычканны тотып ала. Кулына төшкән тычкан песи була да, элгәреге песи, буш почмакны алып, тычкан була. Уен шулай дәвам итә.

### Әбәкләтмә

Җирдә зур түгәрәк сызыла. Барлык уйнаучылар, ярты адым ара калдырып, түгәрәк тирәсенә тезелеп басалар. Уйнаучылар арасыннан бер бала «әбәкче» итеп билгеләнә. Әбәкче түгәрәкнең эченә (теләсә кайсы урынга) кереп баса.

Сигнал буенча уйнаучылар, ике аякта сикерә-сикерә, сызык аша түгәрәк уртасына керәләр. Әбәкче, балаларны (алар түгәрәк эчендә чакта) әбәкләргә тырышып, түгәрәк эчендә йөгереп йөри. Әбәкче якынайгач, балалар түгәрәктән сикереп чыгалар. Әбәкләнгән уйнаучы җиңелгән булып санала (ләкин ул уенда катнашуын дәвам итә).

Үзең бер тапкыр да әбәкләтмәгән балалар арасыннан икенче әбәкче сайлана.

Уен шулай дәвам итә.

**Алырмын, кош!**

Балалар арасыннан «тилгән» һәм «ана кош» сайлап куела. Калган балалар «бәбкәләр» була. Алар «ана кош» артына бер-бер артлы булып тезеләләр, бер-берсенә ныклап ябышалар. Тилгән ана кошка ташлана: «Алырмын, кош!» «Ана кош», кулларын җәеп, балаларын саклый, тилгән кайсы якка ташланса, шунда тилгәнгә каршы чыга: «Бирмәмен, кош!» Тилгән иң арттагы баланы тартып ала алса, үз оясына алып китә һәм уенны дәвам иттерә. Уен вакытында балалар чылбырны ычкындырмаска, ана коштан ераклашмаска тырышалар.

**Ватык телефон**

Балалар бер рәткә тезелеп утыралар. Бер бала уенны алып баручы була. Ул иң беренче утырган балалның колагына тиз генә бер сүз әйтә. Анысы үз чиратында янындагы иптәшенә, ә ул – күршесенә... Шулай итеп, бу сүз, колактан-колакка әйтелеп, рәтнең икенче башына барып җитә. Шуннан соң уенны алып баручы сүз барып тукталган соңгы баладан: «Нинди сүз?» – дип сорый. Тегесе әйтә. Әгәр сүз дөрес барып җитмәсә, ул рәт буенча сүзнең кемдә «бозылганлыгын» эзләп китә. Сүзне бозган бала артка барып утыра, һәм уен яңадан башлана. Әгәр сүз дөрес килеп җитсә, уенны алып баручы үзе артка барып утыра. Аның алдындагы бала уенны алып баручы була.

**Майламыйча купмый**

Уйнаучылар урындыкларда утырып торалар. Уч төпләрен өскә каратып, кулларын тезләренә куялар. Өлкәннәрдән берәү «тәңкә салучы» була. Аның кулында – тәңкә (зуррак төймә, йөзек һ.б. булырга мөмкин). Ул, тәңкәне уч төпләрендә яшереп, тәңкә салып йөри: һәрбер уйнаучының уч төбенә кагылып ала, тәңкәне сиздермичә генә берсенең учында калдырып китә. Бөтен кешегә салып бетергәч, ул: «Тәңкә батыр, сикереп чык», – ди. Тәңкәле бала: «Майламыйча купмый», – ди. Шуннан соң тәңкә салучы йә бер җыр башкара яки шигырь сөйли, аннан соң болар урыннарын алмашалар: җырлаган кеше утыра, икенчесе тәңкә салучы була.

**Мәкаль әйтеш**

Балалар түгәрәкләнеп утыралар. Берәүнең кулында төйнәлгән кулъяулык була. Ул алар алдына чыгып баса да әйтә:

– Мин мәкаль әйтүче булам. Мәкальнең беренче яртысы минем телемдә, икенче яртысы шушы төендә. Хәзер мин, сезгә бер мәкальнең яртысын әйтеп, бу яулыкны кайсыгызга булса да ыргытырмын да, «бер, ике, өч...» дип, алтыга хәтле санармын. Мин шулай санаганчы, яулык тигән кеше тиз генә шул мәкальнең икенче яртысын әйтеп өлгерергә тиеш. Әйтә алган бала мәкаль төенен чишкән дип санала, әйтә алмаучыга җәза бирелә.

Шулай ди дә, уен башлана. Әйтик, уртадагы бала: «Ни чәчсәң, ...» – дип, яулыгын берәүгә ыргыта. Яулык тигәне аңа: «Шуны урырсың» – дип җавап бирә. Тагын моңа мисаллар:

Ы р г ы т у ч ы: Кем эшләми, ...

Я у л ы к т и г ә н б а л а: шул ашамый.

* Эш беткәч, уйнарга ярый.
* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
* Сүзең белән мактанма – эшең белән мактан.
* Кош – канаты белән, кеше дуслары белән көчле.
* Үзеңне үзең мактама, кеше сине мактасын.
* Ата-ананы тыңлаган – адәм булган, тыңламаган – әрәм булган.
* Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.
* Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.
* Иң татлы тел – туган тел, анам сөйләп торган тел.
* Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
* Аз сөйлә, күп тыңла.
* Китап – белем чишмәсе.
* Тормышка юл мәктәптән башлана.

Ыргытучы алтыга хәтле санаганчы җавап таба алмаган кешегә җәза бирәләр. Яулыкны алган соңгы кеше, тагын берәр мәкальнең беренче яртысын әйтеп, яулыгын икенче кешегә ыргыта. Уен шулай дәвам итә.

**Кәбестә**

Балалар үз араларыннан «әби» сайлап куялар. Калганнары бер сафка тезелеп чирәмгә утыралар. Алар «кәбестәләр» була. Әби: «Кәбестә алырга килгән идем, яхшыларын сайлап алыйм әле», – дип, кәбестәләрнең иңбашларына басып-басып йөри. Кем егылып китә, ул «черек кәбестә» була һәм уеннан чыгарыла. Әби моны кабат-кабат эшли. Иң ахыргача нык утырган бала яхшы (таза, нык) кәбестә була. Шуны үзенә алып китә.

**Бакалар**

Берничә бала «бака» итеп билгеләнә. Бакалар түгәрәкләп тезеп куелган урындыкларга утыралар. Уртада түгәрәк сызыла – ул «күл» була. Бакалар түгәрәк күл янында ике аяклап сикереп-сикереп уйныйлар. Калган балалар, тәрбияче белән бергәләп, түбәндәге шигырь юлларын әйтәләр:

Юл буенда бакалар,
Сикерә-сикерә чабалар.
Куа-куа-куа, куа-куа-куа,
Сикерә-сикерә чабалар.

Шигырьнең ахырында балалар кул чабалар – бакаларны куркыталар. Бакалар «күлгә сикерәләр» – тын гына чүгәләп утыралар.

Яңа бакалар сайлана, уен яңадан башлана.

**Әбәкне кайтар!**

Бу уен балалар арасында киң таралган. Ул, йөгереклек, җитезлек һәм уяулыкны үстерү өчен тышта, ачык һавада уйнала.

Уенны бер төркем балалар белән уйнарга мөмкин. Ул ике бала арасында да уйнала. Бер бала икенче бала янына килә дә: «Әбәк!» – дип тиз генә аның аркасына сугып (йомшак кына) ала һәм бер якка йөгереп китә. Сугылучы аны куып җитеп әбәкне кайтарырга тырыша.

Уенны такмак әйтеп тә уйнарга мөмкин. Мәсәлән,

| | |
|---|---|
| * Әбәк-Әбәк,<br>Алтын кабак.<br>Сиңа үрдәк,<br>Миңа каз! | * Саескандай чикаклап,<br>Мин йөримен өй саклап.<br>Казлар буйлап кыйгаклап,<br>Сиңа тиям, син – әбәк! |

**Так каравыл**

Уйнаучылар арасыннан санамыш ярдәмендә «каравылчы» билгеләнә. Калган балалар каравылчының артына парлап тезеләләр. Арадан бер бала болай ди:

Әлчи, бәлчи, әни күлмәк үлчи.
Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

Бу сүзләрне әйтү белән, артта басып торучы парлар, кулларын ычкындырып, як-якка йөгереп китәләр, ә каравылчы аларны куа. Әгәр алар каравылчыга тоттырмыйча килеп җитәкләшә алсалар, каравылчы үз урынында кала. Әгәр каравылчы берәрсен тота алса, парсыз калганы каравылчы була. Уен баштагыча кабатлана: арттагы пар йөгереп китә, тотылмаган парлар каравылчының артына баса баралар. Шул рәвешле уен чираты билгеләнә.

**Чүлмәк сатам**

Балалар ике төркемгә бүленәләр. Бер төркем – «чүлмәкләр», ә икенче төркем «чүлмәк хуҗалары» була. Чүлмәкләр чирәмгә (келәмгә) тезләнеп, түгәрәкләнеп утыралар. Һәр чүлмәкнең артында аның хуҗасы басып тора. Уенны алып баручы түгәрәктән читкәрәк баса.

Сигнал булуга, алып баручы бер чүлмәк хуҗасы янына килә. Алар үзара сөйләшәләр:

– Дустым, чүлмәгеңне сат әле.
– Әйдә, сатам.
– Ничә сум тора соң?
– Өч (ике, биш) сум.

Алып баручы өч тапкыр хуҗаның кулына җиңелчә генә сугып ала – аңа «акча» бирә. Шуннан соң алар түгәрәк буенча бер-берсенә каршы йөгерә башлыйлар. Буш урынга кем беренче булып килеп җитә, шул чүлмәкнең хуҗасы була. Ә урынсыз калган бала алып баручы булып, уен дәвам итә.

**Кара һәм ак**

Уйнаучылар бер рәткә тезелешеп утыралар. Уенны алып баручы уйнаучыларның барысына да түбәндәге сүзләрне әйтеп әйләнеп чыга:

– Менә сезгә йөз сүз. Ни теләсәгез, шуны алыгыз. «Бар», «әйе», «юк» дип әйтмәгез. Акны, караны алмагыз.

Шуннан соң ул, үзенә җавап бирә торган кешедән берәр әйтергә ярамый торган сүзне әйттерер өчен, төрлечә сөйләштерә. Ә җавап бирүче исә андый сүзне әйтүдән саклана. Әгәр дә ул ялгышып берәр сүз әйтеп куйса, фант түли.

Бу уен балаларның игътибарлылыгын арттыра, тапкырлыкка өйрәтә.

**Куян**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала түгәрәк уртасына баса. Ул – «куян».

Куян уйнаучылар каршында уйнап, сикергәләп йөри. Балалар түгәрәк буенча йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Куян, куян, куянкай,
Әйдә уйна, күңелең ач,
Алдыңны, яныңны күрсәт,
Кача алсаң бездән, кач!

Куян, шуны гына көтеп torгандай, түгәрәктән сикереп чыкмакчы була. Балалар туктап калалар һәм, куянны чыгармас өчен, куллары белән тотынган хәлдә чүгәлиләр.

**Яулык алыш**

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

– Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык, –

дип, такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

**Әйт, күгәрчен**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Санамыш ярдәмендә «күгәрчен» билгеләнә. Ул уртада басып тора һәм, шигырьдәге сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләрне башкара. Балалар хәрәкәтләрне кабатлыйлар:

| | |
|---|---|
| Әйт, күгәрчен, син генә, | |
| Яшь кызлар ничек йөри? | *балалар «яулык очларын»* |
| Ул шулай да, ул болай, | *тотып йөриләр* |
| Яшь кызлар йөри шулай. | |
| Әйт, күгәрчен, син генә, | |
| Куяннар ничек йөри? | *куян кебек* |
| Ул болай да, ул шулай, | *сикереп йөриләр* |
| Куяннар шулай йөри. | |
| | |
| Әйт, күгәрчен, син генә, | *әле бер якка,* |
| Үрдәкләр ничек йөри? | *әле икенче якка янтаеп,* |
| Ул болай да, ул шулай, | *алпан-тилпән йөриләр* |
| Үрдәкләр шулай йөри. | |

**Такыя үрәм**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы билгеләнә. Берничә балага чәчәк исеме кушыла һәм аларга шул чәчәктән ясалган башлык бирелә. Балалар түгәрәк буйлап йөриләр:

Без йөрибез болында,
Чәчәкләр бик күп монда.
Матур чәчәк җыябыз,
Такыялар үрәбез. *Туктыйлар*

А л ы п б а р у ч ы.

Ал кирәк, гөл кирәк,
Безгә нәфис гөл кирәк.
Энҗе чәчәк, кил әле,
Бер елмаеп көл әле.

Э н җ е ч ә ч ә к.

Энҗедәй чәчәк атам мин
Яз көнендә урманда.
Миңа берни дә кирәкми
Күләгәлек булганда.

Б а л а л а р.

Энҗе чәчәк, күр әле!
Такыя итеп үр әле.

Энҗе чәчәк чүгәләп утыра. Уен башка чәчәкләр исемен кушып дәвам итә. Исеме аталган һәр «чәчәк» уртага чыгып утыра бара. Шулай итеп, такыя үрелә.

«Такыя» үрелеп беткәч, «такыя» бер якка, түгәрәктәге балалар икенче якква әйләнеп йөриләр.

Без йөрибез болында,
Чәчәкләр бик күп монда.
Матур чәчәк җыйдык без,
Такыялар үрдек без.

**Тизрәк атла!**

Мәйданчык чигеннән 10-15 адым ераклыкта туры сызык сызып куела. Балалар, бер-берсе белән янәшә басып, сызык өстенә тезеләләр. Мәйданчыкның каршы ягына уенны алып баручы өчен 2-3 адым диаметрлы түгәрәк сызыла. Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы билгеләнә.

Уенны алып баручы уйнаучыларга арты белән борыла да, кычкырып: «Тизрәк атла, авызыңны ачып калма! Тукта», – ди. Бу сүзләрне әйткәндә барлык уйнаучылар уенны алып баручыга таба баралар, һәр сүзе саен бер адым алга атлыйлар. Уенны алып баручы «тукта» диюгә, барысы да туктыйлар, ә уенны алып баручы тиз генә аларга таба борылып карый. «Тукта» дип әйткәннән соң туктарга өлгермичә, артык хәрәкәт ясаучыларны уенны алып баручы мәйданчык чигендәге сызык янына кире кайтара. Аннан соң ул, уйнаучыларга яңадан арты белән борылып: «Тизрәк атла, авызыңны ачып калма! Тукта»

дип кабатлый. Барысы да беренче тапкыр «тукта» дигәндә туктап калган урыннарыннан кузгалып, алга баруны (хәрәкәтне) дәвам иттерәләр.

Сызык янына кире кайтарылган балалар хәрәкәтне шул сызыктан башлыйлар. Уен шулай дәвам итә. Балаларның һәрберсе, уенны алып баручыга якынлашып, ул «тукта» дип әйткәнче, түгәрәк эченә керергә тырыша. Түгәрәк эченә керә алган бала үзе уенны алып баручы була, һәм уен яңадан башлана.

**Ашханә**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уенны алып баручы уртага чыгып баса һәм түгәрәктәге балаларның һәммәсен ризык исемнәре белән атап чыга. Аннан соң ашханәдә булган берәр вакыйга турында ирекле хикәя сөйли башлый. Хикәягә балаларга кушылган ризык исемнәре керү мәҗбүри.

Хикәя барышында исеме чыккан бала әйләнеп алырга тиеш. Әгәр моны эшләмәсә, ул уеннан чыгарыла. «Ашханә» дигән сүз чыкканда барлык балалар да әйләнәләр. Уен түгәрәктә бер генә бала калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.

**Без дә !**

Уенны алып баручы билгеләнә. Ул салмак кына берәр вакыйга сөйли. Әгәр аның сөйләмендә балалар башкара ала торган хәрәкәт-шөгыль телгә алынса, уенчылар хор белән: «Без дә!» – дип кычкыралар. Аларның хәленнән килми торган эшләр турында сөйләнелсә, дәшми калырга тиешләр. Кем дә кем булдыра алмас шөгыль, хәрәкәт турында сүз барганда, ялгышып: «Без дә!» – ди икән, ул бала уеннан чыгарыла. Мәсәлән, уенны алып баручы шундый хикәя сөйли:

– Мин урманга киттем (уенчылар: «Без дә!» – диләр). Урманда мин җиләк җыя башладым («Без дә!»). Миңа көчле җил чыкты (дәшмиләр). Яңгыр ява башлады, күк күкрәде (дәшмиләр). Мин печән куышы астына кереп утырдым («Без дә!») һ. б.

Уен җавап бирүчеләрнең берсе генә калганчы дәвам итә. Ул җиңүче булып санала. Икенче уенда ул бала уенны алып баручы була.

**Моңа нишләргә?**

Уен башында һәр уйнаучыдан берәр әйбер (кулъяулык, йөзек, карандаш, конфет һ.б.) алына. Алар тартмага (яисә бер уйнаучының баш киеме эченә) салына.

Ике бала уенны алып баручылар итеп билгеләнә. Аларның берсе уйнаучыларга арты белән борылып, урындыкка утыра. Икенчесе тартмадан бер әйберне ала да, аны уйнаучыларга күрсәтә һәм беренче алып баручыдан (ул әйберне күрми): «Моңа нишләргә?»- дип сорый. Беренче алып баручы төрле биремнәр әйтә: биергә, шигырь сөйләргә, җырларга, бер аякта 5 тапкыр сикерергә, өстәл астында әтәч булып кычкырырга һ.б. Һәр уйнаучы үз әйберен әйтелгән биремне үтәгәннән соң гына ала.

## Җырлы-биюле, җырлы уеннар

Җырлы-биюле уеннарның максаты – балаларда җыр һәм музыканың характерына туры китереп хәрәкәт итү күнекмәләре формалаштыру; җыр һәм биюләрне мөстәкыйль рәвештә башкарырга омтылыш булдыру; халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну һәм аларга карата мәхәббәт тәрбияләү.

Уен вакытында балалар көйгә карап хәрәкәтләнәләр, дәртләнеп җырлыйлар, бииләр. Әлеге уеннар музыкаль авазларны тоемларга ярдәм итәләр, балаларның күңелләрендә нәфислек, матурлык тойгысы уяталар.

**Уенга җыю җыры**

Балалар төрлесе төрле шөгыль белән мәшгуль вакытта тәрбияче «Уенга җыю» җырын җырлый. Балалар әкрен-әкрен генә уенчыкларын җыеп, иптәшләре янына бергә уенга җыелалар, җырга кушылып җырлыйлар.

Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,
Җитәкләшеп тезелик.
Түгәрәктә бергәләп
Күңелле уйныйк, көлик!

Зурлар безгә соклансын,
Читтән карап торсыннар,
Безнең дуслыкка сөенеп,
Бертуган дип белсеннәр.

**Айгөл бии**

Балалар бүлмәнең бер ягында, тәрбиячегә карап, урындыкларда утыралар. Тәрбияче алардан 2-3 м ераклыкта басып тора, бию көе башлангач, кулларын матур итеп алга сузып, биергә чакырыласы баланың исемен әйтеп, җырлый-җырлый аның каршысына биеп бара:

Айгөл, сиңа киләм мин,
Кулларымны сузам мин,
Икәү бергә биергә
Сине дә чакырам мин.
Икәү бергә биергә
Сине дә чакырам мин.

Соңгы ике юлны җырлаганда, тәрбияче Айгөлнең кулларыннан тотып, бии-бии артка чигенә, кызчык аңа каршы биеп бара. Уртага чыккач, куллар җибәрелә, түбәндәге сүзләргә Айгөл үзе генә бии:

Тыпыр-тыпыр Айгөл бии,
Аягы җиргә тими.
«Тагы да матур биермен
Иртәгә әле мин» – ди.

Аннары биюгә башка балалар да чакырыла. Гади генә бию хәрәкәтләрен тәрбияче күрсәтә, бала аны кабатлый.

**Ак калач**

(II ва р и а н т)

Балалар, кулга-кул тотынышып, бер түгәрәк ясыйлар. Берсе уртага чыгып баса. Түгәрәктәге балалар, җырлый-жырлый, калач ничек пешүен, җәелү-кысылуларын кул хәрәкәтләре белән күрсәтәләр:

| | |
|---|---|
| Булатның туган көненә<br>Без пешердек ак калач; | *түгәрәк буйлап йөриләр* |
| Менә шулай ул биек,<br>Менә шулай тәбәнәк;<br>Менә шундый киңлеге;<br>Менә шундый тарлыгы; | *туктап тиешле хәрәкәтләрне ясыйлар* |
| Ак калач, ак калач,<br>Теләгәнеңне сайлап кач! | *кырыйдагы балалар кул чабып торалар, уртадагы бала түгәрәк буйлап йөри* |

Ул үз урынына берәүне сайлап чыгара да, үзе түгәрәктәгеләргә кушыла һәм уен-җыр шулай дәвам итә.

**Без яулыклар юабыз**

Балалар тезелешеп басалар, кулларында – кулъяулыклар. Җырның сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар:

Без яулыклар юабыз,
Без керләр дә уабыз,
Менә ничек, менә ничек
Без яулыклар юабыз!

Без яхшы чайкаучылар,
Без керләрне чайкыйбыз –
Менә ничек, менә ничек
Без керләрне чайкыйбыз.

Киптерергә кирәк бит!
Керне бауга эләбез,
Менә ничек, менә ничек
Керне бауга эләбез!

Керләребез киптеләр,
Хәзер җыеп алабыз,
Менә ничек, менә ничек
Баудан җыеп алабыз.

Кипкән ап-ак керләрне
Үтүклибез, төрәбез.
Менә ничек, менә ничек
Матур итеп төрәбез.

**Ачык авыз**

Балалар, аллы-артлы парлашып, түгәрәк ясап басалар. Бер бала парсыз кала. Ул уртада басып тора. Бию көе уйнала. Шул вакытта эчке якта торган балалар түгәрәк ясап җитәкләшәләр һәм бию көенә әйләнәләр. Шулай бераз әйләнгәннән соң, көй кинәт кенә туктала, һәм эчке яктагылар тышкы якта басып калган балалар белән парлашалар. Бер бала тагын парсыз кала. Ул, уртага чыгып: «Мин кем?» – дип кычкыра. Иптәшләре аңа: «Ачык авыз син!» – дип җавап бирәләр. Аннан соң «ачык авыз»ның бер әйбере алына. Уен шулай кабат-кабат уйнала, һәм «ачык авыз»лар биш-алтыга җиткәч, аларга җәза бирелә.

**Бармакларны биетәбез**

Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларга утыралар; уч төпләрен өскә каратып, кулларын алга сузалар, җырлый-җырлый бармакларын «биетәләр» (бөгәләр, турайталар):

Менә минем бармаклар,
Шаян алар, шук алар.
Бармаклар гел уйныйлар,
Уйный-уйный туймыйлар.

Җырлап бетергәч, кулларын элеккечә алга сузалар. Сул куллары белән, баш бармактан башлап, уң кулдагы һәр бармакның исемен әйтеп, бөкләп чыгалар. Балалар, җырның соңгы юлын җырлаганда, сул кул бармакларын уң кулныкы белән кушып, кулларын йомарлыйлар.

Менә минем бармаклар,
Баш бармак, имән бармак,
Урта, атсыз һәм чәнчә –
Бик дус алар, гел бергә.

Икенче куплет беткәч, балалар кулларын яңадан турайталар һәм беренче куплет сүзләренә, беләзектән бора-бора, биетеп, салмак кына өскә күтәрәләр, аннары, җырлый-җырлый, аска төшерәләр. Уен шулай тәмамлана.

**Башмакчы**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (башмак уйнаучы балаларның аяк размерыннан зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез;
Асыл төсле җепләр белән
Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы,
Үзең оста такмакчы.
Син җырлама такмагың,
Бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны ике бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. Ике бала ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана.

**Бир, дускаем, кулыңны**

Балалар, парлашып, бер-бер артлы басалар. Бер бала парсыз кала, ул алга чыга. Кушымтаны җырлаганда, балалар кулларын тотынган килеш өскә күтәрәләр (күпер ясыйлар). Шул вакытта парсыз бала күпер аркылы чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә.

Агыйделнең суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Безнең яклар күңелле.

Зәңгәр чәчәк җыя-җыя,
Зәңгәрләттем кулымны.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир, дускаем, кулыңны.

**Болында**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала (Халидә) уртада кала. Түгәрәктәгеләр, әйләнә буенча бер якка хәрәкәт итеп, җыр җырлыйлар:

Чәчәкләр үскән болында
Җырлыйбыз әйлән-бәйлән.
Халидә, Халидә,
Әйләнәсең кем белән?
*(Уртадагы кешенең исеме атала.)*

Халидә бер иптәшен уртага ала. Мәсәлән, Әминәне, ди. Җыр тагын кабатлана:

Әминә, Әминә,
Әйләнәсең кем белән?

Шул рәвешчә уртага 5-6 бала җыелгач, уртадагылар түгәрәкләнеп басалар да, кырыйдагыларга капма-каршы юнәлештә хәрәкәт итеп, барысы бергә җырлыйлар:

Гөлнара, Гөлнара,
Син каласын уртада.

Хәрәкәт туктала. Уртадагылар күмәк рәвештә бер яраткан җырларын башкаралар. Аннан соң, Гөлнарадан башкалары кырый түгәрәккә басалар, һәм уен яңадан башлана.

**Бу дустың белән көреш**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар һәм, җырның эчтәлегендә әйтелгән хәрәкәтләрне ясап,

«Сандугач-күгәрчен» көенә җырлап әйләнәләр:

Аякларың тыпырдат, *балалар аякларын тыпырдаталар,*

| | |
|---|---|
| Кулларыңны чәбәклә, | *кул чәбәклиләр,* |
| Бер монда, бер монда, | *кулларын бер уңга, бер сулга* |
| Кыен эш түгел бер дә. | *чәбәклиләр* |
| | |
| Башың аска иеп ал, | *башларын аска иеп алалар* |
| Кул бармагың янап ал, | *бармак яныйлар* |
| Бер монда, бер монда, | *уңга, сулга бармак яныйлар* |
| Кыен эш түгел бер дә. | *әйләнеп алалар* |
| | |
| Бу дустың белән күреш, | *уң яктагы дусты белән күрешәләр* |
| Бу дустың белән күреш, | *сулдагы дусты белән күрешәләр* |
| Йә, иптәш, йә, әйлән, | *әйләнәләр* |
| Бик кыен түгел бу эш. | *баш ияләр* |
| Уен шуның белән бетә. | |

**Бүген кемнең туган көне?**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала (туган көне булган бала) уртага чыга. Уйнаучылар, җырлый-җырлый, бер якка таба әйләнәләр, ә уртадагы бала түгәрәк эчендә каршы якка йөри. Тәрбияче балалар белән бергә җырлый:

– Бүген кемнең туган көне?
Нигә кояш елмая?
– Белдек, белдек, Гөлсинәгә
Бүген җиде (3, 4, 5, 6) яшь тула.

Гөлсинәгә карагыз:
Ничек матур киенгән!
Сәламәтлек, бәхет, шатлык
Телибез чын күңелдән.
Икенче куплетка балалар туктап, кул чабып торалар, ә Гөлсинә бии.

**Туганым**

Балалар кара-каршы тезелеп басалар һәм, әйтелгән сүзләргә яраклаштырып, төрле хәрәкәтләр ясыйлар. «Бер, ике, бер, ике» дигәндә, кулларын тотынышып, әле бер якка, әле икенче якка берәр адым ясыйлар. Аннан соң үз тирәләре буйлап әйләнеп куялар. «Тук, тук» дигәндә, аякларын тыпырдаталар; «шап, шап» дигәндә, кул чабалар; «тик, тик» дигәндә, бармакларын селкетәләр; «мик, мик» дигәндә, башларны ияләр.

Өйрән биергә, туганым,
Менә бирәм кулымны.
Бер, ике, бер, ике,
Әйләнеп куй, бер, ике!
Аяк белән тук, тук, тук!
Кулың белән шап, шап, шап!

Бер, ике, бер, ике,
Әйләнеп куй, бер, ике!
Бармагың белән тик, тик!
Башың белән мик, мик, мик!
Бер, ике, бер, ике,
Әйләнеп куй, бер, ике!
Инде әйтә аламын,
Син бик матур биисең!
Бер, ике, бер, ике,
Әйләнеп куй, бер, ике!

**Габдулла**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала уртада тора. Түгәрәктәгеләр, җырлый-җырлый, бер якка хәрәкәт итәләр:

Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез, Габдулла.
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Шуны эшләргә була.

Җыр туктагач, уртадагы бала берәр төрле хәрәкәт ясый, башкалар аның хәрәкәтләрен кабатлыйлар. Әгәр бу хәрәкәтне дөрес ясамаучылар булса, аның берәр әйберен алалар. «Гаепләнүчеләр» саны өч-дүрткә җиткәнче, уен шулай кабатлана. Соңыннан аларга берәр төрле җәза бирелә (җырларга, биергә, әкият сөйләргә, мәкаль әйтергә һ.б.).

**Зәңгәр чәчәк**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри.

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр –
Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.

**Капкалы**

Ике бала «капка» ясап кулларын өскә күтәреп басалар. Башка балалар түгәрәктә «Әнисә» көенә (татар халык бию көе) бии-бии, капка аша узалар. Кинәт кенә капка ябыла

(ике бала кулларын төшерәләр). Капкага эләгүчегә «җәза» бирелә (шигырь сөйләргә, мәкаль әйтергә һ.б.).

**Кәрия-Зәкәрия**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың җырбиюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:

Бу бик яхшы биюче,
Бу бик яхшы биюче,
Аның биюе матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:

Кәрия, Зәкәрия, коммая,
Кәрия, Зәкәрия, коммая:
Кәри комма, Зәкәр комма, *ике тапкыр*
Зәкәрия коммая...

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана.

Бу бик яхшы җырлаучы,
Бу бик яхшы җырлаучы.
Аның җырлавы матур – *ике тапкыр*
Аннан үрнәк алыгыз. һ. б.

Шулай йөзүче, укучы һ.б. дип төрлечә әйтеп, җырлап-биеп уенны дәвам итәләр.

**Кем яулыгы?**

Балалар түгәрәк ясап басалар, кулларында кульяулыклар. Бер бала уртада басып тора. Ул «яулык җыючы» була. Күңелле көй астында бала кулъяулыкларны җыеп йөри. Кинәт кенә көй туктый. Бу вакытта яулык җыючы кемнең яулыгын ала, шул яулык хуҗасына җәза бирелә (такмаклар җырларга, биергә һ.б.).

**Кунаклар**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар;
Кунакларны сыйларга,
Салдык майлы коймаклар,

Чыж-пыж итеп коймаклар
Җәелде, әй җәелде. *кулларын як-якка җәяләр*
Менә тагын кечкенә
Булып калды, җыелды *кысылалар*

Җыелды, әй, җыелды,
Аннан ары кабарды. *кулларын югары күтәрәләр*
Кабарды, әй, кабарды,
Шинде, юп-юка калды. *чүгәлиләр*

پеште инде коймаклар,
Сыйландылар кунаклар.
Тордылар, баш иделәр,
Таралдылар, әй шатлар. *баш иялəр*
Бииләр, ай-яй, шатлар. *бииләр*

**Куянкай**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына кереп, бер бала чүгәли. Ул – «куян». Куян, бер кулын иягенә куеп, моңаеп тора. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:

Ак куянга ни булган,
Әллә инде авырган?
Иптәшен дә табалмый,
Урыннан да торалмый,
Куян, куян, син сикер,
Иптәшең табып китер!

«Куян» биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып әйләнәләр дә, чакырылган бала куян булып кала. Уен яңадан башлана.

**Куяным**

Тәрбияче балаларны зур түгәрәк ясарга чакыра. Түгәрәк уртасына зур уенчык куян утыртыла.

Тәрбияче җырлый, ә балалар җыр көенә төрле бию хәрәкәтләре ясыйлар, тәрбиячегә кушылып җырлыйлар:

Яшь куянчык шаян була,
Ул уйнарга ярата.
Күрегез, ничек ярата!
Күрегез, ничек ярата!

Я, куяным, якын кил!
Матур итеп сикер син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек сикер син!

Билләреңә кулың куй,
Матур итеп бие син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек бие син!

**Күрсәт әле, үскәнем**

Балалар түгәрәк ясап басалар һәм бер баланы уртага чыгаралар. Күмәк җырлап әйләнеп, уртадагы балага төрле эшләр кушалар. Уртадагы бала кушылган эшне башкара. Кырыйдагылар да: «Менә шулай, менә шулай», – дип, ул эшләгән эшне кабатлыйлар. Эш кушу өчен түбәндәге җыр-такмаклар файдаланыла:

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек кошлар очалар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай кошлар очалар.

– Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек йөри аюлар,
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай йөри аюлар.

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек чаба поездлар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай чаба поездлар.

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек сикерә куяннар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай сикерә куяннар.

**Миңлебай**

Балалар түгәрәк уртасына бер баланы сайлап чыгаралар. Үзләре кулга-кул тотынышып, түгәрәк буйлап җырлап йөриләр:

Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада, Миңлебай,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Без кыланырбыз шулай.

Кырыйдагы балалар туктап калалар, уртадагы бала, җырлый-җырлый, нинди дә булса хәрәкәт күрсәтә.

Бер болай, бер болай,
Йә, кыланыгыз шулай.

Балалар аның җырын, ул ясаган хәрәкәтләрне кабатлыйлар.

Бер болай, бер болай,
Моны эшләү бик уңай.

Уртадагы бала түгәрәктән берәүне уртага чыгара да, бергә әйләнеп, үзе аның урынына баса.

Уртага кыз бала чыгарылса, түбәндәгечә әйтәләр:

Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада, матуркай,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Без кыланырбыз шулай.
Уен шулай дәвам итә.

**Наза**

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала парсыз, ул уенчыларның каршына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр:

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән;
«Наза» дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.

К у ш ы м т а:

Наза, Наза,
Наза матур кыз бала.
Наза тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бапла.

Кушымталарны җырлаганда, парсыз бала каршыдагы уенчылар арасыннан биеп үтә, үзенә пар сайлый, һәм алар икенче башка барып басалар. Парсыз калган бала уенны дәвам итә.

Уенны башка җырлар белән дә дәвам итәргә мөмкин:

Роза, Роза,
Роза гөлләре матур.
Кызларыбыз бигрәк уңган,
Егетләребез батыр.

**Нардуган**

Бер бала уртага чыга. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, шушы нардуган җырын җырлап әйләнәләр. Ул үзенә бер көйгә җырлана:

Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез нардуган,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Мин да шуны булдырам!

Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар да шул хәрәкәтне кабатларга тиешләр. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара да, уен баштагыча дәвам итә.

**Парсыз калма**

Балалар түгәрәккә басып, җырлап йөриләр:

Сандугачлар, былбыллар,
Тургайлар парлы була.
Кем уенда парсыз кала,
Шундук җәзасын ала.

Җыр бетүгә, бию көе башлана. Балалар бииләр. Бию көе туктагач, тиз генә парлашып басалар (балалар саны так булырга тиеш). Так калган балага җәза бирелә (җырлый, бии һ.б.).

**Су анасы**

Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала «су анасы» итеп билгеләнә. Ул күзләре бәйләнгән килеш түгәрәк уртасында утыра.

Уйнаучылар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр:

Су анасы, су анасы,
Су анасын күр әле.
Каршыңда кем басып тора –
Ялгышмыйча әйт әле.

Җыр ахырында балалар туктап калалар. Су анасы урыныннан тора, бармагы белән берәр уенчыга төртеп күрсәтә. Әлеге бала су анасы янына килә. Су анасы, капшап карап, аның кем икәнлеген әйтергә тиеш. Әгәр дөрес әйтсә, шул уенчы су анасы була. Дөрес әйтмәсә, су анасы кире үз урынына утыра.

**Там, там, тамчы, там!**

Уенчылар, пар-пар булып, кулга-кул тотынышып, бер-бер артлы басалар. Алар бергәләп түбәндәге җырларны җырлыйлар һәм бию хәрәкәтләре ясыйлар:

Там, там, тамчы, там, — *алга баралар*
Тамганыңны яратам. — *артка таба чигәләр*
Тамган тамчыларга карап, — *кара-каршы басып кул чабалар*
Мин җырларга яратам.

Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме?
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме?

Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Кулны-кулга чаба-чаба
Көләбез дә җырлыйбыз.

**Төймә-төймә**

Балалар, түбәндәге сүзләрне җырлап, түгәрәктә йөриләр һәм, туктап, кушымтасында бииләр:

Яңгыр ява сибәләп,
Төймә-төймә төймәләп.

К у ш ы м т а:

Их төймә, төймә, төймә,
Төймә була егерме.
Бергә җырлыйк, бергә уйныйк,
Бергә яшәү күңелле.

Җепкә тезгән төймә кебек,
Без дә яшик бергәләп.

К у ш ы м т а:

Их төймә, төймә, төймә,
Төймә була бер җептә.
Җепкә тезгән төймәләрнең
Матурлыгы берлектә.

**Түбәтәй**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатырыйм, дигәнсең.

К у ш ы м т а:

Түп-түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында түбәтәй кемдә булып кала, шуңа «җәза» бирелә (бии, җырлый, шигырь сөйли, әтәч булып кычкыра һ.б.).

Уен шулай дәвам итә.

**Түбәтәй белән уен**

Уртада 5-6 урындык тора, урындыкларга түбәтәйләр куела. Балалар урындыклар тирәли түгәрәкләнеп басалар һәм, көй башлануга, җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, түбәтәйләрен кияләр, шул арада урындыкларга утырып өлгерергә тиешләр. Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уенны кабатлаганда уртада өч урындык кала, уйнаучылар саны артыграк була. Соңга таба бер урындык калдыралар. Шулай итеп, иң игътибарлы, җитез бала билгеләнә.

**Түгәрәк алан**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә йөриләр һәм такмак әйтәләр:

Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.
Әминә, Гөлфия,
Әйдә әле биергә.

Бу аланда чәчәкләр күп,
Без аларга тимибез,
Лилия, Гөлия,
Әйдә бергә биибез.

Исеме әйтелгән балалар, уртага чыгып, бергәләп әйләнәләр һәм икесе дә кырыйдагы балалар арасыннан берәр баланың каршына килеп башларын ияләр. Уен әлеге балаларның исемен әйтеп дәвам итә.

**Тычканнар әйлән-бәйлән уйный**

Балалар – «тычканнар» – җырлый-җырлый әйлән-бәйлән әйләнәләр. Уртада «песи» йоклап утыра.

Әйлән-бәйлән уйныйбыз,
Матур итеп җырлыйбыз.
Уртада песи утыра –
Балалар, тын булыгыз.

Туктап, түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Песине уятмагыз.
Бик сак кына атлагыз!

Соңгы сүзләрне әйткәннән соң, песи уяна һәм тычканнарны куа башлый. Балалар үзләренең урындыкларына утырып өлгерсәләр, песи аларны тота алмый. Ә тотылган тычканны песи үз өенә алып китә (алдан билгеләнгән урындыкка алып барып утырта). Уен 5-6 тычкан тотылганга кадәр дәвам итә.

**Утыр-утыр, Мәликә**

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасына утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр:

Утыр, утыр, Мәликә, алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа, әйтеп бирче тиз генә.

Берәү аның янына килеп утыра. Уртадагы бала аны капшап танып исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

**Чума үрдәк, чума каз**

Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр дә, парлашып, кулга-кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Әлфия үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата.
Сәвияне ярата шул, ярата.
*(Һәр юлы ике мәртәбә кабатлана.)*

Уйнаучылар җыр ритмына туры китереп, кулларын хәрәкәтләндереп торалар. Ялгыз бала (Әлфия), рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны (Сәвияне) җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы исә рәт башына китә. Җыр яңадан башлангач, ул да үзенә шул тәртиптә иптәш сайлый.

Уен шулай дәвам итә.

**Яшерәм яулык**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кулъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың үч төбенә кулъяулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыкны бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салганны сизмәсә, аңа «җәза» бирелә.

# III БҮЛЕК

## Әйдәгез, дуслар, җыелыйк...

Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,
Җитәкләшеп тезелик.
Дуслар белән бергәләп
Күңелле уйныйк, көлик.

*С. Миңлекәй*

## САНАМЫШЛАР

Йөгерешле, качышлы һәм башка күмәк уеннарда балаларга арадан берәрсен уенны алып баручы, әйдәүче итеп сайларга туры килә. Алар, гадәттә, санамыш ярдәмендә сайлана.

Балалар шаян, күңелле такмак-санамышларны бик яраталар. Аларны тиз отып алалар.

Санамышлар болай әйтелә: барлык уенчылар да түгәрәк ясап яисә бер рәткә тезелеп басалар. Арадан берәү уртага чыгып баса һәм сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп, кычкырып такмазаны әйтә. Ул һәр сүз саен бер баланың күкрәгенә кулын тидереп ала, үзен дә шул исәпкә кертеп саный. Соңгы сүзгә кем туры килә, шул әйдәүче (уенны алып баручы) була.

* Бер, ике, өч,
Әнә тегендә күч.

* Бер, ике, өч,
Сиңа көч,
Син моннан күч.

* Җепсез орчык,
Чәукә, чыпчык,
Кара балчык,
Син, кал, бу чык!

* Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Җирдә – елан,
Һавада –кош,
Бар син дә оч!

* Кулда уймак,
Табада коймак,
Мичтә бәлеш,
Ал да ябыш.

* Саесканның койрыгы
Саный китсәң – унике.
Сыңар аяк, сыңар чык,
Син калып тор,
Ә син чык.

* Ипи, тоз,
Матур кыз.

* Карга, чыпчык,
Берең кал да
Берең чык.

* Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык,
– Чык әле, – ди,
Чык!

* Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи.
Үлчи торгач, җитмәде,
Кисә торгач, бетмәде.
Чәукә, чыпчык, син, кал, бу чык,

* Әке, бәке, кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Ә син чык.

* Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи,
Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң очып чык!

* Җыелганнар кошкайлар –
Безнең нәни дускайлар:
Песнәк, чәүкә, саескан,
Күгәрчен артка поскан.
Син, карга, син, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык!

* Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
Байлар кия төлке тун,
Төлке тунның бәясе
Йөз дә кырык сигез сум.

* Чәйнеккә акча салдым.
- Ничә булды? –Йөз булды.
Әтәлчек, мәтәлчек,
Сиңа туры килде, чык!

* Өйгә кергән бер чыпчык,
Очып йөри чык-чырык.
- Чыпчык, чыпчык, син, чыпчык!
Атлап түгел, очып чык!

* Саескандай чикаклап,
Мин йөримен өй саклап.
Син йокыңнан уян,
Озын колаклы куян.

* Аладай, каладай
Чистай, Чикәнәй,
Алабуга – ак балык,
Син кал – бу чык.

* Берәү, икәү,
Өчәү, дүртәү,
Бишенчесе булган көтүче,
Көтү көт инде!

* Тор, тор, тургай,
Таң ата бугай.
Тургай түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!

* Ун, тугыз, сигез,
Әй симез үгез.
Җиде, алты, биш,
Бүре килә ич.
Дүрт, өч, ике, бер -
Тиз качып өлгер!

* Алачык, салачык,
Салачыкта калачык,
Калачыкта балачык,
Балачык – малайчык,
Качма алай, малай чык!

* Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

* Тор, тор, тургай,
Таң ата бугай.
Тургай, чыпчык,
Син кал, бу чык!

* Чистай – чигәнәк,
Алабуга – бигәнәк.
Мин йөримен күзаллап,
Шап!

* Бер тай, ике тай,
Өч тай, дүрт тай,
Монда торма,
Чыгып тай.

* Саескандай чыйкаклап,
Мин йөримен өй саклап,
Казлар булып кыйгаклап,
Сиңа тиям, син – әбәк!

* Ыргадан, мыгырдан,
Песи бара елгадан.
Песи түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!

* Мин барамын базарга
Алтын-көмеш сайларга.
Ал чук, зәңгәр чук,
Монда торма, тизрәк чык.

* Ялкау, чытык, мактанчык,
Мактанчыкка – буш капчык.
Буш капчык, уеннан чык!

* Алма, шикәр,
Бавыр, агач,
Тик торма, син,
Ал да кач.

* Ары алачык, бире алачык,
Кыр капкасы шар ачык;
Ары чык, бире чык,
Монда торма, йөгереп чык.

* Алатыр, булатыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Эремчек, биремчек,
Син кал, бу чык.

* Елгада бар бер басма,
Син анда ялгыш басма,
Әгәр бассаң китереп,
Кырыйга чык, сикереп.

* Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Сайрыйлар тургайлар,
Моңая сыерчык,
Жыр жырлый чыпчык,
Син кал, бу чык!

* Арыш-бодай игәбез,
Аны болай бүләбез
Тигез, уңган, таза, нык,
Таза, ныкка – биш капчык.

* Кырма чыбык, сары янчык,
Карчык, кызчык,
Син кал, бу чык.

* Уйдык, уйдык, урман,
Урманда тормам;
Типтәр, мишәр, башкорт,
Сиңа житте, бар чык.

* Ыргада, Мургада,
Мәче йөри колгада,
Умырык, томырык,
Монда торма, йөгереп чык.

* Алатыр, булатыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Аны көтеп торганчы
Алга таба бара тор.

* Чут-чут, сандугач,
Тәрәзәдә карлыгач.
Чырык-чырык чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык!

* Сулга карый ун агай,
Унга карый ун агай.
Бар, чыгып кит син, агай!
* Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

# ФИЗКУЛЬТМИНУТЛАР

Физкульминутларның максаты – төрле эшчәнлек вакытында нәниләргә кыска вакытлы ял итү мөмкинлеге булдыру; ишетү, күрү органнарын, гәүдә мускулларын, кул чукларын ял иттерү. Аяк-кул, бармак, муен, гәүдә өчен хәрәкәтләрне эченә алган гимнастик күнегүләр күңелле, файдалы узсын өчен, аларны төрле җыр, такмаклар белән башкарырга мөмкин. Шигъри юллар белән яисә көй ярдәмендә (фортепьяно, аудиоязма, бубен) үткәрелә торган ял минутларын балалар бигрәк тә ярата.

## Кечкенәләр төркеме

**Үсәм**

| | |
|---|---|
| Мин әле бик кечкенә, | *балалар алга таба иеләләр* |
| Миңа бары өч кенә. | *күтәреләләр* |
| Үсә, үсә зур булам, | *ике кулның да имән бармакларын бит* |
| Бик матур малай (кыз) булам. | *урталарына куеп, башларын чайкыйлар* |

**Чәбәк-чәбәк**

| | |
|---|---|
| Чәп-чәп, чәбәкәй, | *нәниләр кулларын күтәреп* |
| Кулларыбыз бәләкәй, | *чәбәклиләр* |
| Ә хәзер тизрәк-тизрәк | *кулларын җиңелчә генә* |
| Чәбәклик күңеллерәк, | *тезләренә сугалар* |
| Уен берничә тапкыр кабатлана. | |

**Үсеп китте**

| | |
|---|---|
| Үчтеки, үчтеки, | *чүгәлиләр* |
| Үсмәгәнгә кечтеки. | |
| | |
| Үсә-үсә зур булыр, | *акрын гына күтәреләләр* |
| Бигрәк матур кыз булыр. | *бармакларын бит уртасына куеп,* |
| Бик батыр егет булыр. | *башларын як-якка чайкыйлар* |
| | |
| Үчти, үчти, үчтеки, | *аяк очларына басып,* |
| Үсте китте кечтеки. | *кулларын өскә күтәрәләр* |

**Кошлар булып очабыз**

| | |
|---|---|
| Кошлар булып очабыз, | *кулларын як-якка җәеп,* |
| Аннан җиргә кунабыз. | *очалар* |
| | |
| Бераз ял итәбез дә | *чүгәлиләр* |
| Тагын очып китәбез. | *очалар* |

**Алма җыябыз**

| | |
|---|---|
| Барабыз, барабыз, | *атлап баралар* |
| Алма күреп алабыз. | *як-якларына карыйлар* |
| Үреләбез, алабыз | *кулларын өскә күтәрәләр* |
| Һәм кәрзингә салабыз. | *кулларын аска төшерәләр* |
| Тагын атлап барабыз. | *атлап баралар* |

**Тигез юл буйлап...**

| | |
|---|---|
| Нәниләр бара | |
| Тигез юл буйлап, | *атлап баралар* |
| Тигез юл буйлап | |
| Ашыкмый атлап. | |
| | |
| Зур-зур ташларны | *алга таба ике аякта* |
| Сикереп үтәләр. | *сикереп баралар* |
| Һәм көтмәгәндә | |
| Егылып китәләр... | *туктап калалар,* |
| Бух! | *чүгәлиләр* |

**Яңгыр**

| | |
|---|---|
| Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу! | *бер урында сикерәләр* |
| Яңгыр безгә бик кирәк. | |
| Яңгырдан соң агачлар, | *кулларын як-якка җәяләр* |
| Чәчәкләр үсә тизрәк. | *кулларын өскә күтәрәләр* |

**Матур тубым**

| | |
|---|---|
| Минем тубым бигрәк житез: | *кулларын чәбәклиләр* |
| Матур итеп сикерә. | *сикерәләр* |
| Әгәр тотып өлгермәсәң, | *кулларын өскә күтәрәләр* |
| Әллә кая йөгерә. | *бер урында йөгерәләр* |

**Куянкай**

| | |
|---|---|
| Әй, куян, куян, кечкенә генә, | *чүгәләп утыралар* |
| | |
| Бик йомшак кына, бик куркак кына. | *басып, куллары белән гәүдәләрен сыпыралар* |
| | |
| Ике колагы озынкай гына, | *кулларын баш өстенә куеп селкетәләр* |
| Аягы җиңел – мамыктай гына. | *ике аякта сикерәләр* |

**Тәмле йокы**

Көн киткә дә, төн җиткән, *әкрен генә чүгәлиләр*
Кояш йокыга киткән. *күзләрен йомалар*
Син аңа комачаулама, *бармак яныйлар*
Йокла, куян, шаулама!
Тәмле йокылар сиңа! *чүгәлиләр*

**Нәниләр**

Балалар бер рәткә тезелеп, чүгәләп утыралар. Тәрбияче балалар каршында чүгәләгән һәм сөйли:

Әй, нәниләр, нәниләр
Ардык без,–дип әйтмиләр. *әкрен генә торалар*
Аякларын күтәреп,
Матур итеп атлыйлар. *йөрү хәрәкәтләре ясала*

Хәзер барабыз артка,
Егылмыйча син атла. *артка таба йөрү хәрәкәтләре*
Бер, ике, бер, ике!
Егылмыйча син атла. *алга таба киләләр*

**Песи балалары**

Нәни песи балалары *иелеп, куллары белән*
Тәпиләрен юалар. *аякларын сыйпыйлар*
Менә шулай, менә шулай
Тәпиләрен юалар.

Колакларын, корсакларын *ике кул белән колакларын ышкыйлар*
Ышкып-ышкып алалар.
Менә шулай, менә шулай *уң кул белән корсакларын ышкыйлар*
Ышкып-ышкып алалар.

Эшләгәч, бик арыйлар *әкрен генә келәмгә яталар*
Тәмләп йоклыйлар алар, *күзләрен йомалар*
Менә шулай, менә шулай *йоклаган булып кыланалар*
Тәмләп йоклыйлар алар.

**Аю**

Аю бик арыган икән, *чүгәлиләр*
Тәмләп йокыга киткән. *күзләрен йомалар*
Әйдә, Аю, тор инде - *әкрен генә торалар*
Бергәләп уйныйк инде. *урыннарында атлап торалар*

### Кошлар

Уен башында балалар чүгәләп утырып торалар.

| | |
|---|---|
| Нәни кошлар уяндылар, | *әкрен генә торалар* |
| Канатларын кагындылар. | *кулларын як-якка җәеп селкиләр* |
| Чырык-чырык чыркылдап | *төрле якка йөгерешеп китәләр* |
| Төрле якка таралдылар. | |

### Уңган балалар

| | |
|---|---|
| Безнең нәни аяклар | *балалар йөгерү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Шәп итеп йөгерәләр. | |
| | |
| Куллар да калышмыйлар, | |
| Чәп-чәп итеп бииләр. | *кулларны чәбәклиләр* |
| | |
| Шушы нәни балалар | *чүгәләп, уенчык җыю хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Уенчыкларны җыя. | |
| | |
| Уенчыкларны җыя да | *басып, «уенчыкларны куялар»* |
| Урыннарына куя. | |
| | |
| Апа әйткәч, балалар | |
| Беркая да бармыйлар. | |
| Тыныч кына утырып, | |
| Әкиятләр тыңлыйлар. | *әкрен генә урыннарга утыралар* |

### Җил

| | |
|---|---|
| Җил исә, исә-исә, | *кулларын өскә күтәреп, як-якка селкиләр* |
| Агачларны селкетә. | *кулларын алга таба селкиләр* |
| Җил тына-тына, тына, | *кулларын әкрен генә аска төшерәләр* |
| Ә агачлар үсә дә үсә, | *кулларны өскә күтәрәләр* |
| үсә дә, үсә. | |

### Аю, куян

| | |
|---|---|
| Аю бара урманнан, | *бер урында атлап торалар* |
| Утын җыя учакка. | *алга таба иеләләр* |
| Усак артында куян - | *чүгәлиләр* |
| Курка икән аюдан. | *башларын яшерәләр* |
| Куян, куян, курыкма, | *сикерәләр* |
| Аю тими ул сиңа! | *кул чабалар* |

**Сәгать**

Сәгать йөри «келт-келт», *башны як-якка чайкыйлар*
Ул уяна иртүк: тук-тук. *баш кагу хәрәкәте*
Ялкауларны яратмый: юк-юк. *баш чайкау хәрәкәте*

**Чебиләр**

Өй алдында чебиләр: *кулларны артка җәеп, як-якка борылалар*
«Чип-чип-чип!»–дип йөриләр.
Кечкенә канатлары, *кулларын як-якка җәяләр, бармаклар бии*
Муеннары сап-сары. *башларын чайкыйлар*

**Соры куян юына**

Соры куян юына, *ике кул белән битләрен сыпыралар*
Ул кунакка җыена. *кулларны як-якка җәяләр*
Юды борынын, юды авызын *борын, авыз кырыйларын сөртәләр*
Юды колагын, сөртте корытып! *колакларын ышкыйлар*

**Нәни аяклар**

Безнең нәни аяклар
Шәп итеп йөгерәләр. *балалар йөгерәләр*
Юлдагы ташлар өстеннән
Сикерә-сикерә үтәләр. *ике аякта сикереп баралар*
Озак сикерә торгач,
Зур чокырга төшәләр. Бух! *«бух!» сүзеннән соң чүгәлиләр*
Чокырдан чыгалар! Ух! *торып басалар*

**Курчагымны йоклатам**

Курчагымны юам мин, *баланың өстенә су сибү хәрәкәтләре*
Күлмәкләрен уам мин. *куллары белән «кер уалар»*

Зинһар өчен берегез *кулларын алга сузып, уч төпләрен өскә*
Булышырга килегез. *каратып, бармаклары белән чакыралар*

Юындыргач без аңа
Тәмле мәми ашатыйк. *кашык белән ашату хәрәкәтләре*

Көне буе арыгандыр, *баш алдында кулларны бергә куеп,*
Инде аны йоклатыйк. *башны шул кулларга салып, әкрен генә*
Бәлли-бәлли-бәү! *чайкалалар*

**Куянкай**

Т ә р б и я ч е. Ак куянкай утырган, колакларын селкетә.
Б ал а л а р. Менә шулай, менә шулай колакларын селкетә.
*(баш өстенә куеп, кулларын селкетәләр)*
Т ә р б и я ч е. Куян, туңа башлагач, аякларын җылыта.
Б а л а л а р. Менә шулай, менә шулай аякларын җылыта.
*(әле бер, әле икенче куллары белән кул аркаларын сыйпыйлар)*

Т ә р б и я ч е. Куян тагы да туңа, сикергәләп тә куя.
Б а л а л а р. Менә шулай, менә шулай сикергәләп тә куя.
*(куяннар кебек сикерәләр)*

## Уртанчылар төркеме

**Кояш нурлары**

Иртән кояш күренә, *балалар урыннарыннан торалар*
Менеп китә үренә, *аяк очларына басалар*
Сокланабыз эшенә - *кулларын як-якка җәяләр*
Нур сибә бар кешегә! *кулларын өскә күтәрәләр*

**Яшел бакча**

Балалар түгәрәкләнеп басалар.
Безнең яшел бакчага *бер урында атлап бару хәрәкәтләре*
Әйдә, бергәләп барыйк. *ясыйлар*

Гөлләр ничек үсә икән, *иеләләр*
Әйдәгез, бергә карыйк.

Инде безнең гөлләребез *күтәреләләр*
Менә шулай үскәндер.

Безнең матур гөлләребез *кулларын өскә күтәреп,*
Менә шулай үскәндер. *аяк очларына басалар*

**Яңгыр**

Җил чыкты. балалар, җил тавышы чыгарып, «ж-ж-ж» диләр
Яңгыр ява. куллар белән яңгыр яву хәрәкәтләре ясыйлар
Кояш чыкты. кулларын як-якка сузалар
Төн җитте. күзләрен йомалар һәм чүгәлиләр

| | |
|---|---|
| Торыгыз, торыгыз! | *күзләрен ачалар, басалар һәм кулларын өскә* |
| Нинди матур көн туды! | *күтәрәләр* |

**Черки**

| | |
|---|---|
| Яфракка черки кунган, | *як-якка чайкалалар* |
| Ял итәргә уйлаган. | *чүгәлиләр* |
| Аякларын селки-селки, | *торып, аякларын селкиләр* |
| Аннан «качыш» уйнаган. | *куллары белән күзләрен каплыйлар* |

**Без рәсем ясадык**

| | |
|---|---|
| Без рәсемнәр ясадык, | *йодрыктагы бармаклар* |
| Безнең бармаклар арды. | *бер ачыла, бер ябыла* |
| | |
| Без хәзер ял итәбез, | *кулларны аска төшереп,* |
| | *бармакларын селкетәләр* |
| Аннан тагын ясыйбыз. | *рәсем ясау хәрәкәтләре ясыйлар* |

**Чебиләр зарядкасы**

| | |
|---|---|
| Нәни чебиләр барсы да | *урыннарыннан торалар,* |
| Сары майка кигәннәр. | *иңнәрен сикертәләр* |
| Зарядка ясарга диеп | *кулларын өскә күтәәләр* |
| Бер урынга килгәннәр. | *тыпырдыйлар* |
| | |
| Тавык аңлата: «Корт-корт». – дип, | *кулларын билгә куялар,* |
| Үз телендә аларга. | *башларын чайкыйлар* |
| Зарядка ясаган чакта | *кулларын терсәктән бөгеп,* |
| Ничек канат кагарга. | *канат кагу хәрәкәтләре ясыйлар* |

**Аюны уятмагыз**

| | |
|---|---|
| Тау башында ята кар, | *балалар, кулларын җәеп,* |
| Тау башында бик күп кар! | *әкрен генә өскә күтәрәләр* |
| | |
| Урманда чыршы төбендә | *гәүдәне алга таба ия төшеп,* |
| Йокыга талган аю бар. | *әкрен генә алга баралар* |
| | |
| Шыпырт, тавышланмагыз. | *бармак яныйлар, «йоклыйлар»* |
| Аюны уятмагыз! | |

**Кар бабай**

| | |
|---|---|
| Без урамда уйныйбыз, | *бер урында йөгерәләр* |
| Без Кар бабай ясыйбыз. | *куллары белән түгәрәк ясыйлар* |
| Кар бабай миннән биек, | *кулларын өскә күтәрәләр* |

Кар бабай миннән юан, *кулларын як-якка җәяләр*
Ә Кар әби тәбәнәк, *чүгәлиләр*
Киттек менә тәгәрәп. *идәнгә ятып тәгәриләр*

**Түгәрәктә**

Балалар урындыкларга утырып торалар.
Бергәләп басыйк әле, *басалар түгәрәк ясыйлар*
Түгәрәк ясыйк әле.
Менә нинди түгәрәк! *уртага керәләр*
Бик кечкенә түгәрәк!

Кулга кулны тотынып, *артка чигенәләр*
Артка таба барабыз.
Менә нинди түгәрәк. *зур түгәрәк ясап, басып торалар*
Бик зур түгәрәк!

Уңга таба барабыз, *уңга баралар*
Тырышабыз барыбыз!
Ә хәзер сулга китик, *сулга баралар*
Йөрүне дәвам итик.

Түгәрәктә йөрибез, *туктап, бер урында тыпырдап торалар*
Бик тырышып биибез.
Менә шулай ял иттек,
Вакыт күңелле үтте. *урыннарына утыралар*

**Курчагым**

Балалар, шигырьдәге сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар: күзләрен, борынын һ.б. күрсәтәләр.

Менә минем курчагым,
Ике күзе бар аның.
Ә менә бу – борыны,
Бу, билгеле – муены.
Колакларын күрсәтим,
Чәчен сыйпап иркәлим.
Бигрәк матур битләре,
Авызында тешләре.
Теле дә бардыр әле.
Ә менә болар – куллар, *кулларын чәбәклиләр*
Чәбәк-чәбәк уйныйлар.
Кечкенә аяклары
Бик матур тыпырдыйлар. *тыпырдыйлар*
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр!

**Карагыз!**

Менә минем уң кулым, — *уң кулын күрсәтә*
Менә минем сул кулым, — *сул кулын күрсәтә*
Менә идән, менә түшәм, — *өскә-аска карый*
Менә шулай зур үсәм. — *аяк очларында күтәрелә*

**Без атлап барабыз**

Без атлап барабыз, — *атлап баралар*
Йөгереп тә барабыз, — *йөгерәләр*
Арып китсәк, утырып, — *туктап, бер урында*
Аякларны язабыз. — *тыпырдыйлар*

**Кар бөртеге**

Кар бөртеге өйгә керде, — *бер урында кулларын җилпеп*
Өй эчендә очып йөрде — *әйләнәләр*

Менә шулай, менә шулай, — *очып йөрү хәрәкәтләре*
Өй эчендә очып йөрде.

Кар бөртеге бик аз очты, — *бер урында торып, кулларын җилпиләр*
Суздык аңа жылы учны, — *кулларын алга сузалар*
Менә шулай, менә шулай, — *чүгәлиләр*
Суздык аңа жылы учны. — *башларын ияләр*

**Бармаклар**

Менә минем бармаклар, — *кулларын сузып,*
Шаян алар, шук алар. — *кул чукларын әйләндерәләр*

Бармаклар гел уйныйлар, — *бармакка-бармак сугалар*
Уйный-уйный туймыйлар.

Менә минем бармаклар: — *кулларын күрсәтеп, уң куллары белән*
Баш бармак, имән бармак, — *сул кулның бармакларын берәм-берәм*
Урта, атсыз һәм чәнчә - — *тотып чыгалар*
Бик дус алар, гел бергә. — *кул чабалар*

**Кошлар оча**

Очып баручы кошлар — *кош очу хәрәкәтләре ясыйлар*
Туктaлдылар аланда. — *туктап торалар*
Утырып ял иттеләр, — *чүгәлиләр*
Тагын очып киттеләр. — *кош очу хәрәкәтләре ясыйлар*

**Коңгызлар**

Коңгызлар оча жуылдап, *«жу-жу-жу» дип жуылдап,*
Бж-бж, бж-бж быжылдап. *бүлмә буйлап йөгерәләр*

Оча торгач ардылар, *аркаларына яталар,*
Идәнгә егылдылар. *аяк-куллары белән төрле хәрәкәтләр ясыйлар*

Коңгызлар ял иттеләр,
Тагын очып киттеләр. *очу хәрәкәтләре ясыйлар*

**Су буенда**

Без су буена килдек, *йөрү хәрәкәтләре*
Иелдек тә юындык. *битне, кулны юу хәрәкәтләре*
Кулларны болай итәбез: *йөзү хәрәкәтләре*
Балыклар кебек йөзәбез. *чүгәләү, торып басу*
Ә хәзер судан чыгабыз, *йөрү хәрәкәтләре*
Урыныбызга утырабыз.

**Кыен эш түгел бер дә...**

Аякларың тыпырдат, *аякларын тыпырдаталар*
Кулларыңны чәбәклә, *кул чәбәклиләр*
Бер монда, бер монда, *кулларын бер уңга, бер сулда*
Кыен эш түгел бер дә. *чәбәклиләр*

Башың аска иеп ал, *башларын аска иеп алалар*
Кул бармагың янап ал, *бармак яныйлар*
Бер монда, бер монда, *уңга, сулга бармак яныйлар*
Кыен эш түгел бер дә. *әйләнеп алалар*

Бу дустың белән күреш, *уң яктагы дусты белән күрешәләр*
Бу дустың белән күреш, *сулдагы дусты белән күрешәләр*
Йә, иптәш, йә, әйлән, *әйләнәләр*
Бик кыен түгел бу эш. *баш ияләр*

**Уф, ардык**

Балалар түгәрәккә тезелеп басалар, тәрбияче – уртада. Ул шигырь юлларын укыганда, балалар тиешле хәрәкәтләр ясыйлар.

Бакчада саф һава суладык, *күкрәк тутырып сулыйлар*
Уф, ардык! *туктап ял итәләр*
Шакмаклар, тартмалар өйгәләп, *кирпеч өю хәрәкәтләре*
Биналар ясадык бергәләп.

| | |
|---|---|
| Уф, ардык! | *ял итәләр* |
| Ашадык тәмле аш, күмәчләп. | *«ашыйлар»* |
| Чәй эчтек шикәрләп һәм сөтләп. | *«эчәләр»* |
| Уф, ардык! | *ял итәләр* |

## Зурлар төркеме

**Без инде хәзер зурлар**

| | |
|---|---|
| Без инде хәзер зурлар, | *балалар, аяк очларына басып, кулларын югары күтәрәләр* |
| Күп эшли безнең куллар. | *кулларны төрле якка хәрәкәтләндерәләр* |
| Без идән дә юабыз, | *аска иелеп, идән юу хәрәкәте ясала* |
| Без керләр дә уабыз, | *куллар белән кер юу хәрәкәтләре ясала* |
| Гөлләргә су сибәбез. | *гөлгә су сибү хәрәкәте күрсәтелә* |
| Менә шундый уңган без, | *аяк очларына басып, түгәрәктә* |
| Менә шундый булган без. | *әйләнәләр* |

**Куш кулым**

Балалар парлашып, бер-берләренә карап басалар.

| | |
|---|---|
| Менә сиңа уң кулым, | *икесе дә үзләренең кулларын шапылдаталар һәм уң кулларын бер- берсенә сугалар* |
| Менә сиңа сул кулым; | *кул чабалар, сул куллар сугыла* |
| Уң кулым, сул кулым, | *кул чабалар, уң кул, сул кул чиратлашып чабыла* |
| Менә сиңа куш кулым. | *кул чабалар, ике кул да бер-берләренә сугыла* |

**Заводлар**

| | |
|---|---|
| Эре-эре заводлар, | *аяк очларына басып, куллар янга сузыла* |
| Заводта станоклар. | *куллар алга сузыла* |
| Тиздән үсеп җитәрбез, | *куллар югары күтәрелә, аяк очларына басыла* |
| Шунда эшкә китәрбез. | *урында горур рәвештә атлау хәрәкәтләре ясала* |

**Гөлләр үстерәм**

| | |
|---|---|
| Кара җирне йомшартып | *бармакларны йодрыклау, ачу* |
| Утыртабыз без гөлләр. | *чүгәлиләр* |
| Шытып, яшәреп, үсеп | *торып басалар* |
| Чыгарлар алар тиздән. | *кулларын өскә күтәрәләр* |
| Көн саен карап аларны | *кулларны төшерәләр* |
| Сибәрбез бергә сулар. | *су сибү хәрәкәтләре* |

| | |
|---|---|
| Чәчәк атар гөлләребез | *кулларны як-якка җәяләр* |
| Кызыл, зәңгәр, алсулар. | *кул чабалар* |

### Кәбестә

| | |
|---|---|
| Без кәбестә турыйбыз, | *кул учларының аскы өлеше белән өстәлгә суккалыйлар* |
| Без кәбестә тозлыйбыз, | *ике куллап чеметем тоз салалар* |
| Без кәбестә уабыз, | *кулларны бер-берсенә ышкыйлар* |
| Без кәбестә сыгабыз. | *уч төпләрен кысалар һәм ачалар* |
| Бераз кишер кырабыз, | *учларын каплап, ике кул бармакларын берберсенә* |
| Тозлап, майлап алабыз. | *ышкып алалар* |
| Яхшылап болгатабыз. | *уң кул белән болгату хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Бигрәк тәмле! Ашагыз! | *ике кулны алга сузалар* |

### Куяннар санамышы

| | |
|---|---|
| Бер, ике, өч! | *кулларын иң өстенә күтәрәләр,* |
| Куяннарда бөтен көч! | *як-якка җәяләр* |
| Дүрт, биш! | |
| Безне җиңеп булмый һич. | *гәүдәне алга, артка ияләр* |
| Алты, җиде! | |
| Куяннар башын иде. | *башларын ияләр* |
| Сигез, тугыз, ун! | *куллар, бармаклар ярдәмендә саныйлар* |
| Алты бүре, алты тун. | |
| Без тук бүген, бүре ач. | *як-якка йөгерешеп китәләр* |
| Әнә килә, тизрәк кач! | |

### Үрмәкүч

| | |
|---|---|
| Идәндә чебеннәр | *балалар бию хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Парлашып биеделәр. | |
| Йөри торгач ардылар, | *бер урында атлап торалар* |
| Талдылар. | |
| Әйләнделәр, | *әйләнәләр* |
| Борылдылар. | |
| Як-якка күз салдылар. | *күзләре белән як-якка карыйлар* |
| Күрделәр үрмәкүчне – | *идәнгә тәгәрәшәләр* |
| Хушларыннан яздылар. | |

### Ял итәргә туктадык

Балалар урыннарыннан торалар, шигырьнең сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар

Без бераз гына ардык,
Ял итәргә туктадык.
Җилкәләрне турайттык,
Тирән итеп суладык,

Башны як-якка бордык,
Чүгәләдек һәм тордык,
Бер урында йөгердек,
Аннары без сикердек.

Сузылдык-киерелдек,
Югарыга үрелдек.
Ә аннары тынычланып
Урыныбызга утырдык.

**Аш пешерү**

| | |
|---|---|
| Ярдәм күтеп тормыйбыз, | *гәүдәне уңга-сулга бору* |
| Яшелчәләр турыйбыз; | |
| Чиста итеп юабыз, | *алга бераз иелә төшеп, юу хәрәкәтләре* |
| Без кәбестә турыйбыз. | *турау* |
| Бераз кишер кырабыз, | *учларын каплап, бармакларны бер-берсенә ышку* |
| Ваклап суган турыйбыз, | *турау* |
| Тозлап, майлап алабыз, | *уң кул бармакларын уйнату* |
| Яхшылап болгатабыз. | *кулларны беләзектән әйләндерү* |
| - Бигрәк тәмле, ашагыз! | *кулларны алга сузу* |

**Урманда яңгыр**

| | |
|---|---|
| Яңгыр ява коеп, | |
| Утыра куян боегып. | *балалар чүгәләп утыралар* |
| Колаклары тырпайган, | *кулларын баш өстенә куялар* |
| Аяклары чыланган. | *басып тыпырдыйлар* |
| Аю белән бүре дә | *әле бер, әле икенче аякларын күтәреп,* |
| Яңгыр астында калган. | *әкрен генә чайкалалар* |
| Кача-кача яңгырдан | |
| Аяклары бик арыган. | *йөгерү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Ә төлке–бик хәйләкәр, | |
| Куак астына качкан. | *чүгәлиләр* |
| Көчле яуган яңгырдан | |
| Шулай качып котылган. | *башларын тезләренә яшерәләр* |
| Без дә качыйк яңгырдан, | |
| Йөгереп кайтыйк урманнан. | *урыннарына утыралар* |

**Без шулай ял итәбез**

Хәрәкәтләр сүзләргә туры китереп ясала.

Без әле бераз арыдык,
Ял итәргә уйладык.
Башны иябез алга,
Ә аннары–артка.

Уңга, сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.
Иң өсләрен сикертәбез,
Кулларны биетәбез.

Бер алга, бер артка сузып,
Күңелле ял итәбез.

**Булышу**

Бергәләшеп тышка чыктык, *баралар*
Ике кулга пычкы тоттык.
Утын кистек: зиң- зиң-зиң. *утын кисү хәрәкәтләре*
Кулыбызга балта алдык.
Утын ярдык: дак-док-док. *утын яру хәрәкәтләре*
Өйгә кайттык.
Бераз ардык: уф-уф-уф! *урыннарына утыралар*

**Утырып ардык**

Хәрәкәтләр сүзләргә туры китереп ясала

Утырып инде ардык,
Бераз ял итеп алыйк.
Кулларны билгә куеп,
Башларны чайкап карыйк.
Куллар билгә, өскә, янга.
Утырып-торып алыйк.
Куш аяклап сикерик тә,
Урыныбызга утырыйк.

**Шаян балалар**

Балалар ирекле басалар. Шигырьнең сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.

Бигрәк шаян инде без,
Тик тормыйбыз бер дә без.
Чүгәлибез, торабыз.
Башны уңга борабыз.
Аннан сулга карыйбыз
Һәм сикерә башлыйбыз.

Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез.
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.

**Шофёрлар**

Кабинадан чыгабыз, — *өстәл арасыннан чыгалар һәм бакка бензин*
Бакка бензин салабыз, — *салган хәрәкәтләр ясыйлар*
Кабинага керәбез, — *өстәл арасына кереп утыралар*
Педальгә үреләбез. — *аяклары белән «педальгә басалар» һәм машина моторын кабызу тавышы чыгаралар*

Бик күп җирләрне үттек,
Кире кайтып та җиттек. — *машинаны туктаталар (п-ш-ш-ш-ш)*

**Кер юам**

Балалар түгәрәкләнеп басалар һәм сүзләргә туры килгән хәрәкәтләр ясыйлар.

Мин тик тормыйм, эш эшлим,
Җиң сызганып кер уам.
Керләр уам, керләр уам,
Керләр чайкыйм, кер юам.

Керләрем инде агарган,
Мин аларны җилгә эләм.
Керләр эләм, керләр эләм,
Кипсеннәр кояш белән.

Юдым, чайкадым, элдем.
Керләрем кипкәч, җыйдым,
Үтүгемне кыздырып,
Үтүкләп, төреп куйдым.

**Яңгыр яуганда**

Яңгыр, яңгыр юлларда — *баралар*
Аякларны чылата,
Аякларны күтәреп, — *сикергәләп баралар*
Сикерәбез күл аша.
Менә болай, менә болай, — *бер урында сикерәләр*
Сикерәбез күл аша.

Аякларны чылатмаска, — *итек кию хәрәкәтләре*
Киябез без итекләр.
Яңгырдан без курыкмыйбыз, — *бер урында йөгерәләр*
Аякта бит итек бар.
Менә шундый, менә шундый, — *әле бер, әле икенче*
Менә шундый итек бар. — *аякларын күрсәтәләр*

Матур яңгыр явып үтте, — *яңгыр сибү хәрәкәтләре*
Кояш җылы нур сипте. — *кулларын өскә кәтәрәләр*
Әйдә тизрәк бакчабызга, — *баралар*
Киптерик без күлмәкне.
Менә шулай, менә шулай, — *кием селкү хәрәкәтләре ясыйлар*
Киптерик без күлмәкне.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

### Без яздык

| | |
|---|---|
| Без яздык, без яздык, | *йодрыктагы бармаклар* |
| | |
| Безнең бармаклар талды. | *бер ачыла, бер ябыла* |
| | |
| Без хәзер ял итәбез, | *кулларны аска төшереп,* |
| | *бармакларны селкетәләр* |
| Аннан язып китәбез. | *язу хәрәкәтләре* |

### Көз килә

| | | |
|---|---|---|
| Т ә р б и я ч е: | И балалар, күрегез: | |
| | Тышта әнә килә көз. | |
| Б а л а л а р: | Әйе, әйе, күрәбез, | *балалар басалар* |
| | Көз килгәнен беләбез. | |
| Тә р б и я ч е: | Йә, әйтегез, сөйләгез | |
| | Ничек килә икән көз? | |
| Б а л а л а р: | Кошлар очты көньякка, | *кулларын як-якка җәеп* |
| | Канат кагып еракка. | *чайкалалар* |
| | Балыклар да тындылар, | *балалар чүгәләп,* |
| | Су төбенә чумдылар. | *башлрын яшерәләр* |

| | |
|---|---|
| Агачлар, ялангачлар | |
| Җилләрдә чайкалдылар. | *куллары өстә чайкала* |
| Тик безгә күңелле көз | |
| Без бакчага йөрибез. | |

### Бакчачылар

| | |
|---|---|
| Бакчачылар, әйдәгез, | *кулларын алга сузалар* |
| Менә бакча юлыбыз. | |
| Әйдә барыйк, сулар сибик, | *атлап баралар* |
| Шиңгән булса гөлебез. | |
| | |
| Су тутырып савытларга | |
| Кулларыбызга алыйк. | *башта бер, аннары икенче кул белән* |
| Рәхәтләнсеннәр чәчәкләр - | *су сибү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Сулар белән сугарыйк! | *кул чабалар* |

### Физзарядка ясый куян

Балалар чүгәләп утырганнар, күзләре йомык.

| | |
|---|---|
| Куян күзләрен ача, | *күзләрен ачалар* |
| Төпкә менеп баса. | *басалар* |

| | |
|---|---|
| 1, 2, 3 – утыра, | *чүгәлиләр* |
| 1, 2, 3 – ул тора. | *басалар* |
| Зур агачка тотынып, | *куллар алга-артка чайкала* |
| Куян таган атына. | |
| | |
| Алан тулы төп тә төп, | |
| Сикергәли дөп тә дөп. | *сикерәләр* |
| Кинәт читкә тартылды | |
| Һәм урынына утырды. | *урыннарына утыралар* |

**Иртәнге шатлык**

| | |
|---|---|
| Әтәч, канат кагынып, | *кулларны, як-якка сузып, селкү* |
| Кычкырды инде күптән. | |
| Киерелдек-сузылдык та, | *башларын уңга-сулга бору* |
| Сикереп тордык иртән. | *бер урында сикереп кую* |
| | |
| Урыннарны җыештырдык, | *кулларны, аска төшереп, селкү* |
| Кулларны, битне юдык. | *кул, бит юу хәрәкәтләре* |
| Физзарядка ясарга дип, | *кулларны өскә күтәрү, төшерү* |
| Тышка йөгереп чыктык. | *урында йөгерү* |
| | |
| Җилкә өчен, куллар өчен | *җилкәләрне сикертү* |
| Ясадык күнегүләр | *кулларны күтәрү, төшерү* |
| Һәм саф һавада йөрдек - | *урында йөрү* |
| Күтәрелде күңелләр. | *кул чабу* |

**Кар атышу**

| | |
|---|---|
| Йомшак карны алабыз, | *кар әвәләү хәрәкәтләре* |
| Аннан туплар ясыйбыз. | |
| Кар атышып уйныйбыз, | *атышалар* |
| Бик күңелле яшибез. | *кул чабалар* |
| | |
| Суыктан без курыкмыйбыз, | *кулларын як-якка җәеп йөриләр* |
| Рәхәтләнеп уйныйбыз, | |
| Кар бөртекләрен куып, | *йөгерәләр* |
| Уйнаудан һич туймыйбыз. | |

**Кышкы урманда**

| | |
|---|---|
| Кышкы урманга килдек, | *бер урында атлап торалар* |
| Матур урыннар күрдек. | *кулларын як-якка җәяләр* |
| Тун кигән каен – уңда, | *уңга күрсәтәләр* |
| Ямь-яшел чыршы – сулда. | *сулга күрсәтәләр* |
| | |
| Кар бөртекләре оча, | *кулларын өскә күтәреп, әйләнәләр* |
| Әйләнеп җирне коча. | |

| | |
|---|---|
| Әнә куян сикерә, | *ике аякта сикерәләр* |
| Ул бүредән элдертә. | *бер урында йөгерәләр* |
| | |
| Кызылтүшләр очалар, | *кулларын җилпиләр* |
| Бигрәк тә матур алар. | *кулларын як-якка җәяләр* |
| Урманда рәхәт булса да, | *бер урында атлап торалар* |
| Өйгә кайтыйк, балалар. | *урыннарына утыралар* |

**Һәркайсының үз эше**

| | |
|---|---|
| Баш бармак бау ишә. | *бау ишү хәрәкәте ясала* |
| Имән бармак имән кисә, | *агач кису хәрәкәте* |
| Урта бармак ут кабыза. | *шырпы сызу хәрәкәте* |
| Атсыз бармак ат җигә. | *атта йөрү хәрәкәте* |
| Чәнти бармак чәй эчә. | *чәй эчү хәрәкәте* |

**Тамчылар**

| | |
|---|---|
| Кара каргалар килә, | *очу хәрәкәтләре* |
| | |
| Түбәдән тамчы тама, | *бармак очлары белән өстәл өстенә чиртәләр* |
| Көндез көн җылы була, | *куллары өстә чайкала* |
| Суыта кичкә таба. | *чүгәлиләр* |
| Тамчылар бии тып та тып, | *бармакларны өстәл өстендә биетәләр* |
| Тамчылар сикерәләр, | *урыннарында сикерәләр* |
| Аларны булмый туктатып, | |
| Алар яз китерәләр. | *кул чабалар* |

**Яз килде**

| | |
|---|---|
| Гөрләвекләр агалар, | *утырган килеш кулларын як-якка җәяләр* |
| Күктән кояш елмая. | |
| Каңгылдашып торналар. | *басалар, очу хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Тезелеп үтте бая. | *кулларын өскә күтәрәләр* |
| | |
| Инешләрдә коена | *чуму, йөзү хәрәкәтләре* |
| Канатланып үрдәк, каз. | |
| Җирне яшәртеп безгә | |
| Гөлләр алып килә яз. | *кул чабалар* |

**Кырмыскалар**

| | |
|---|---|
| Мин – кырмыска, | *уң кулны иң башына кую* |
| Син – кырмыска, | *сул кулны иң башына кую* |
| Барыбыз да кырмыска. | *бер урында атлап тору* |
| Йорт салабыз, тырышабыз. | *куллар белән «түбә» ясау* |
| Безгә дуслык булыша. | *бер-берләре белән күрешү* |

**Күбәләкләр**

Бергәләшеп, җыйналып, — *бару хәрәкәтләре*
Без барабыз болынга.
«Хәерле юл» теләп безгә — *уң кулларын өскә күтәреп, селкиләр*
Күктә кояш елмая.

Канатларын җилпи-җилпи, — *кулларын як-якка җәеп селкиләр*
Күбәләкләр очалар.
Ал, кызыл, сары, зәңгәр –
Нинди матурлар алар! — *кулларын өскә күтәреп селкиләр*

**Урманда**

Яшел урман аланында
Без чәчәкләр җыябыз, — *чүгәләп, «чәчәкләр өзәләр»*
Ап-ак ромашкалар өзеп,
Такыялар үрәбез. — *куллар белән үрү хәрәкәтләре*
Ак каеннар төпләреннән
Без гөмбәләр эзләдек. — *чүгәләп йөриләр*
Агач башында уйнаган
Тиеннәрне күзләдек. — *торалар, өскә карыйлар*
Матур чәчәкләр кочып,
Гөмбәле кәрзин тотып, — *әкрен генә урыннарына утыралар*
Без кайтабыз урманнан,
Бераз гына арылган.

**Бер-ике! Бер-ике!**

Барыбыз да тырышабыз — *урыннарында атлыйлар*
Физкультура ясарга.
Бер-ике, бер-ике, — *кул чабалар*
Физкультура ясарга. — *атлыйлар*
Кулларыңны киң итеп җәй, — *кулларын як-якка җәяләр*
Аннан алга таба суз. — *алга таба сузалар*
Бер-ике, бер-ике, — *кул чабалар*
Аннан алга таба суз. — *алга таба сузалар*

Кулларыңны өскә күтәр, — *кулларын өскә күтәрәләр*
Аннан төшер түбәнгә. — *кулларын түбән төшерәләр*
Бер-ике, бер-ике, — *кул чабалар*
Аннан төшер түбәнгә. — *кулларын түбән төшерәләр*
Я, балалар, бергәләп
Бердәм булып кул чабыйк. — *кул чабып торалар*
Бер-ике, бер-ике,
Бердәм булып кул чабыйк.

# Файдаланылган әдәбият

*Ал кирәк, гөл кирәк.* Уеннар китабы / төз. Рәшит Ягъфәров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен* / төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984

*Балачак аланы:* Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / төз. К.В. Закирова. – Казан : РИЦ, 2011.

Галеев Э.Х. *Татарские народные игры и праздники:* кн. для учителя / Э. Х. Галеев, Я. И. Ханбиков. – 2-е изд.,перераб.и доп. – Казань : Татар.кн.изд-во, 1985. – 104 с.

Гарафиева Г.З. *Сөмбеләне кем беләә?:* Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик ярдәмлек. – Казань: ТаРИХ, 2003.

*Детские подвижные игры народов СССР* / Сост. А.В. Кенеман. – Москва: Просвещение, 1988.

Закирова К.В. *Уйный-уйный үсәбез* (Балалар бакчасында уеннар): Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма / К.В. Закирова. – Казан: Татар. Кит. нәшр, 2010. – 175 б.

Закирова К.В., Мортазина Л.Р. *Әй уйныйбыз, уйныйбыз...:* Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

Закирова К.В., Мортазина Л.Р. *Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак:* Балалар бакчасында уеннар. – Казан: РИЦ, 2012.

*Исәнбәт Нәкый.* Нәниләр шатлана. К., – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.

*Иң матур сүз* / Төз. К.В. Закирова. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

Кашапова М.Ф./ *Уйныйк әле, балалар:* Беренче китап. – Казан: РИЦ, 2011

Коротков И.М. / Подвижные игры детей. – Москва: «Советская Россия», 1987

Лихадиевская Т.Г., Ивановская И.М. / *Подвижные игры в детском саду:* пособие для педагогов дошкольных учреждений. – Минск: «Белорусь», 2002

Миңлекәй С. *Балалар өчен җырлы уеннар.* Тулыл. басма / С.Миңлекәй. – Казан: 1925. – 47 б.

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен хәрәкәтле уеннар* / төз. Г.Х. Хуҗаханова, Р.М. Козлова – Казан: Татгосиздат, 1948. – 80 б.

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кагыйдәле хәрәкәтле уеннар:* /Уку-укыту басмасы / төз. Г. Шакирова. Г. Хуҗаханова. – Казан: Тат. кит. нәшр. 2017

*Татар балалар фольклоры/* төз. Р.Ягъфәров. – Казан: «Раннур» нәшр., 1999

Шәехова Р.К.: *Куаныч:* Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2022

Ягъфәров Р. *Кәҗә-мәкәрҗә:* Балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 1994

## ЭЧТӘЛЕК


**I БҮЛЕК. «Балачак- матур чагыбыз»**

**2-3 яшьлек балалар өчен уеннар**

Аю һәм балалар
Атта йөрибез
Эт һәм үрдәкләр
Куышу
Яңгыр, яу!
Бау аша сикер
Кояшкай
Матур уенчык
Кошлар очалар
Шалтыравыкка кадәр
Югарырак үрмәлә
Туп кемдә?
Тупны тәгәрәт
Кем тизрәк?
Төз ыргыт
Машиналар
Кайда шалтырый?
Соңга калма
Кәҗә
Инеш аша
Сукмак буйлап
Куянкай. Татар халык уены
Песи. Татар халык уены

**3-4 яшьлек балалар өчен уеннар**

Минем яныма йөгерегез
Песи һәм тычканнар
Маэмай
Флагка таба йөгерегез
Төлке һәм тавыклар
Күңелле сыерчыклар
Атлар
Такси
Түгәрәктә
Инеш аша үтәбез
Күбәләкне тот
Песи һәм чыпчыклар
Түмгәктән түмгәккә
Тавык һәм чебиләр
Йорт куяннары
Туплар
Кызыл, зәңгәр...
Капкага керт
Тот, ыргыт, төшермә!
Чыпчыклар һәм автомобиль
Трамвай
Үз төсеңне тап
Үз өеңне тап
Уенчыкны сакла
Куык
Кошчыклар
Флагны тап
Күз бәйләш. Татар халык уены
Коймак. Татар халык уены
Аю урманында. Рус халык уены

**4-5 яшьлек балалар өчен уеннар**

Ябалак
Төсле автомобильләр
Очкычлар
Кыңгырау
Сиздермичә йөгереп үт
Беренче булып бас
Шалтыравык
Песи белән тычкан
Песи һәм кошчыклар
Соры бүре
Тавык кетәклегендә төлке
Куяннар
Хәйләкәр төлке
Инеш аша сикереп чык
Курыкмыйм
Көтүче
Песи балалары
Көчекләр
Кошлар оча
Ыргыт һәм тотып ал
Ераккарак ыргыт
Божра
Төз ыргыт
Кем ераграк ыргыта?
Үз төсеңне тап
Сыерчык оялары
Көн-төн
Үзеңә пар тап
Көтүче һәм атлар
Бүләкләр
Үз чиләгеңне тап
Кайда шалтыраттылар?
Кем тавышы?
Куышу уены. Татар халык уены
Ак калач. Татар халык уены
Аю-бүре. Татар халык уены
Песием. Татар халык уены
Яшелчәләр. Татар халык уены
Казлар-аккошлар. Рус халык уены
Ябалак һәм кошлар. Рус халык уены
Минем күңелле тубым. Рус халык уены
Инеш. Рус халык уены

**5-6 яшьлек балалар өчен уеннар**

Куышу
Карусель
Почмак алыш
Урыныңны тап
Балалар һәм әтәч
Песи һәм тычкан
Төлке һәм тавыклар
Балыклар
Куяннар һәм төлке
Чыпчык, чык!
Чәчәк бәйләме
Мин качам, син тот
Яулык
Кармак
Бау аша сикер
Бүре һәм куяннар
Күчтек
Кем тизрәк?
Идәндә калма
Сазлык
Аю һәм бал кортлары
Янгын сүндерүчеләр
Соңга калма
Аучы һәм куяннар
Кыршау эченә ыргыт
Тупны ыргыт
Тупны сетка аша ыргыт
Серсо
Кем тизрәк җыелыр?
Кыршау тәгәрәтү
Флаг янына!
Тупны тизрәк тапшыр
Каршылыклар юлы
Кайсы төркем җитезрәк?
Кемдә йөзек? Татар халык уены
Мияу, мияу, нинди төс? Татар халык уены
Ак димә, кара димә... Татар халык уены
Буяу сатучы һәм буяулар. Татар халык уены
Очты, очты... Татар халык уены
Шат балалар. Рус халык уены
Ике суык. Рус халык уены
Диңгез дулкынлана. Рус халык уены
Тилгән. Рус халык уены
Буяу сатыш. Башкорт халык уены
Давыл. Башкорт халык уены
Без унике кыз идек... Башкорт халык уены
Биляша. Мари халык уены
Туп тәгәрәтү. Мари халык уены

Бoҗра кемдә? Мари халык уены
Козгын. Мордва халык уены
Куяннар. Мордва халык уены
Яулыклар. Мордва халык уены
Туп һәм чокыр. Удмурт халык уены
Тоттым! Удмурт халык уены
Кәҗә бәтиләре һәм этләр. Удмурт халык уены
Чәчәкләр. Чуаш халык уены
Диңгездә – ерткыч! Чуаш халык уены
Таралыгыз! Чуаш халык уены
Балыклар. Чуаш халык уены
**6-7 яшьлек балалар өчен уеннар**
Йортсыз куян
Аю
Куышу
Ачкычлар
Сыерчык оялары
Төлке
Парлашып бас
Сикергечләр
Бакалар
Чикерткәләр
Песи һәм чыпчыклар
Әтәчләр
Күчмә кошлар
Кыңгырау шалтыратам
Кем беренче?
Тупны тапшыр
Иң төз атучы
Куянкай
Тупны биеккәрәк ыргыт
Чыпчык оча
Штандер
Туплы эстафета
Көнгерә
Кем тизрәк?
Матур шарлар
Поезд
Кыргаяклар ярышы
Чүлмәк сатыш. Татар халык уены
Күз бәйләш. Татар халык уены
Төенчек. Татар халык уены
Бүкән. Татар халык уены
Почмак алыш. Татар халык уены
Самавыр. Татар халык уены
Без-без, без идек... Татар халык уены
Аксак төлке. Татар халык уены
Зур туп. Рус халык уены
Буш урын. Рус халык уены
Качышлы. Рус халык уены
Лапта. Рус халык уены
Җәнлекләр өйрәтүче. Рус халык уены
Балык тоту. Рус халык уены
Әбәк-күбәк. Башкорт халык уены
Энә белән җеп. Башкорт халык уены
Йөзек салыш. Башкорт халык уены
Исемен әйт. Башкорт халык уены
Курай. Башкорт халык уены
Әтәчләр сугышы. Мари халык уены
Тилгән һәм казлар. Мари халык уены
Кем тизрәк? Мари халык уены
Тупны тидер. Мордва халык уены
Ачкычлар. Мордва халык уены
Чүлмәкләр. Мордва халык уены
Су анасы. Удмурт халык уены
Кулъяулык белән уен. Удмурт халык уены
Сукыр тәкә. Удмурт халык уены
Атның койрыгын тот. Удмурт халык уены
Бүре һәм куян. Чуаш халык уены
Җитез тиеннәр.Чуаш халык уены
Ай һәм кояш. Чуаш халык уены
Инешләр. Чуаш халык уены
**II БҮЛЕК. «Без уйныйбыз, уйныйбыз»**
**Хәрәкәтле уеннар**
Йөгерүле уеннар
Куып узарга тырыш
Чык, йөгер!
Урынсыз калма
Өйләрегезгә кайтыгыз
Әйдә, куып кара
Йоклама!
Урыныңа йөгер
Көн һәм төн
Бакча дуслары
Бер аякта басып кал
Өченче артык
Бүре һәм казлар
Ятьмә
Күке
Ике һәм өч
Аю, куян
Тыңлаусыз чебиләр
Күгәрчен
Безне куып тот
Бүре белән сарыклар
Куркак тычканнар
Оядагы кошлар
Бал кортлары
Үз парыңны тап
Тычкан оялары
Бүре һәм кәҗә бәтиләре
Тизрәк түгәрәккә кер
Кошчыклар һәм көчек
Сикерүле уеннар
Оясыз сыерчык
Бер, ике, өч – сикер!
Түгәрәктән сикерү
Әбәклəтмә
Бау аша сикерү
Көчле дулкын
Төлке килә!
Чилән белән бакалар
Кул чабыгыз!
Аягыңа тидертмә
Куян балалары
Күчтем-күч
Сикергеч мәктәбе
Үрмәләүле һәм шуышулы уеннар
Нәрсә кайда яши?
Тиеннәр
Төпсез капчык
Төшермә!
Канат буенча югарыга!
Күңелле ярышлар
Читлектәге куяннар
Туплы уеннар (ыргыту һәм тотып алу уеннары)
Туп уйнау (3-5 яшь)
Туп уйнау (5-7 яшь)
Түгәрәктә туп уйнау
Тупны тот
Тупны төшермә
Яхшырак тыңла!
Тупны тәгәрәт
Тупны җибәрмә
Төклетура (шмель)
Тупны бау аркылы ыргыт
Тупны тотып ал
Тупны тап
Туп кемдә?
Туп ыргытыш
Тукта!
Аягыңа тидермә
Туплы әбәк
Кайнар бәрәңге
Ашарга ярый-ярамый
Мин беләм биш исем
Аз хәрәкәтле уеннар
Сүзне әйтеп бетер
Кулларыңны сакла!
Кемдә калды?

Нәрсә бар икәнен бел
Хәйләкәр төлке
Тиз әйт!
Куян
Игьтибарлы бул!
Мәзәкче
Артта кем тора?
Ялгышма!
Кайнар кул
Бакчада нәрсә үсә?
Чишмә
Җиләк, гөмбә, чикләвек
Нәрсә яшерелгән?
Эстафета, ярыш уеннары. Уен-аттракционнар
Гөмбә җыябыз
Чорналыш
Энә күзе
Яңа урын
Игезәкләр
Бакалар сикерешә
Сазлык
Сазлык аша чыгу
Сикергеч белән йөгерү
Пингвиннар
Туп йөртү
Кара-каршы
Кайсы команда беренче?
Тупны төшермә
Футбол
Тапшыр да торып бас
Тупны ал
Күбәләк корты (Гусеница)
Кайсыгыз тизрәк тасманы ала?
Кем тизрәк келгяны ала?
Коткару түгәрәге
Бәрәңге утырту һәм җыю
Өлгер бала
Кыршаулар белән уеннар
Спорт уеннары
Кышкы уеннар
Йөгереп кит
Ыргыт
Кыш бабай
Кыш бабай белән Җәй кызы
Чаналарга!
Чаналар белән ярыш
Чаңгычылар
Һөҗүмнән саклан
Кар шарчыклары
Кар йомарламнары ташу
Кар йомарламын тидертмә!
Кем төзрәк ыргытыр?
Бозларны тизрәк керт
Бозлы юл буйлап
Шайбаны үткәрмә
Алтынтау патшалыгы
Чаңгычылар
Чаналар ярышы
Кече Сабантуй уеннары
Татарча көрәш
Чүлмәк вату
Йомырка салынган кашык кабып йөгерү
Кашык белән су ташу
Капчык сугышы
Капчык киеп йөгерү
Аркан тартыш
Таяк тартышу
Кем иң тиз йөгерә?
Бүләк кисеп алу
Кул көрәше
Ат чабышы
Халык уеннары
Хәрәкәтле татар халык уеннары
Тургай, чыпчык
Мәче һәм тычкан
Читекче
Гөрләмеш, яки кача-кача
Ал кирәк, гөл кирәк
Тозак
Әбәк
Песи белән тычканнар
Әбәкләтмә
Алырмын кош
Ватык телефон
Майламыйча купмый
Мәкаль әйтеш
Кәбестә
Бакалар
Әбәкне кайтар!
Так каравыл
Чүлмәк сатам
Кара һәм ак
Куян
Яулык алыш
Әйт, күгәрчен
Такыя үрәм
Тизрәк атла!
Ашханә
Без дә!
Моңа нишләргә?
Җырлы-биюле уеннар
Уенга җыю җыры
Айгөл бии
Ак калач
Без яулыклар юабыз
Ачык авыз
Бармакларны биетәбез
Башмакчы
Бир, дускаем, кулыңны
Болында
Бу дустың белән күреш
Бүген кемнең Туган көне?
Туганым
Габдулла
Зәңгәр чәчәк
Капкалы
Кәрия-Зәкәрия
Кем яулыгы?
Кунаклар
Куянкай
Куяным
Күрсәт әле, үскәнем
Миңлебай
Наза
Нардуган
Парсыз калма
Су анасы
Там, там, тамчы, там!
Төймә-төймә
Түбәтәй
Түбәтәй белән уен
Түгәрәк алан
Тыйканнар әйлән-бәйлән уйный
Утыр, утыр, Мәликә
Чума үрдәк, чума каз
Яшерәм яулык
**III БҮЛЕК. «Әйдәгез, дуслар, җыелыйк»**
Санамышлар
Физкультминутлар
Беренче кечкенәләр төркеме
Икенче кечкенәләр төркеме
Уртанчылар төркеме
Зурлар төркеме
Мәктәпкә әзерлек төркеме
Файдаланылган әдәбият

Проектның җитәкчесе
**Азат Ганиев**

Автор
**К. В. Закирова**

Рецензентлар:
**М. З. Закирова**,
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры
урынбасары, п.ф.к.
**Л. Н. Ногманова**,
«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»
ӨҺББ ДАББУ ректоры, п.ф.д.
**Й. Ш. Хисамиева**,
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының
мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы

**К. В. Закирова**
Уйныйк, куаныйк әле...
(балалар бакчасында уеннар)
Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм
физкультура инструкторлары өчен
методик кулланма

Әдәби редакция:
**Алсу Низамиева, Зөһрә Фәсхиева**

Дизайн һәм график вёрстка
**Дмитрий Гиацинтов**

IT бүлек җитәкчесе
**Дамир Бариев**


Техник директор
**Илдар Низаметдинов**

420124, Казан шәһәре, Сөләйманова ур., 5.
www.tdpress.ru


ТҮБӘ
татар
чәч
ЗАТ
КҮРШЕ
УМАРТА
ит
үрдәк
зәңгәр
умырзая
ҮЛӘН
СҮЗ
сум
нәрсә
өй
мөһим
юл
кызыл
лачын
кыяр
һәйкәл
ОЧРАШУ
ЗИННҺАР
кыш
ләкләк
көчтәнәч
өн
олы
ел
сабан
нигез
эт
мәхәббәт
пәрәмәч
елга
кадерле
кибет
песи
нечкә
һич
оста
ТӨЗ
исә
лаек
океан
кыяр
кайдан
үрдәк
ял
оя
өй
кызыл
озак
сыйфатлы
дуслашырга
гөбәдия
вак
ерткыч
газиф
гадел
дуслык
егет
еш
даруханә
дүрт
ут
җавап
егерменче
кавын
олы
ҮСМЕР
ОН
НЕФТЬ
күрше
очрашу
очма
һәйкәл
нәрсә
хәл
нигез
җөмлә
җөмһүрият
җомга
җитмеш
чүл
КЫЙБАТ
кыйммәтле
һәм
МӘҢГЕГӘ
һава
нәни
ҺӘРВАКЫТ
ҖЫЛЫТА
су
исәнлек
хәл
тарак
озак
кәләм
пешекче
АЙ
каен
Е
китап
сулыш
эш


ТҮБӘ
КҮРШЕ
УМАРТА
үрдәк
умырзая
ит
зәңгәр
ЗАТ
мөһим
юл
кызыл
кыяр
һәйкәл
ОЧРАШУ
ЗИННҺАР
СҮЗ
ҮЛӘН
нәрсә
өй
көчтәнәч
ЕЛ
мәхәббәт
пәрәмәч
елга
нечкә
оста
кибет
песи
кадерле
ТӨЗ
олы
ЭТ
исә
лаек
океан
озак
ял
оя
дуслык
ертекыч
гадел
вазыйфа
гөбәдия
дуслашырга
егет
даруханә
дүрт
ут
җавап
егерменче
кавын
олы
ҮСМЕР
очрашу
кыйммәтле
КЫЙБАТ
һәм
мәңгегә
нәни
һава
һәрвакыт
җылыта
җөмһүрият
җөмлә
җомга
нигез
хәл
житмеш
ОН
НЕФТЬ
исәнлек
сылу
хәл
татар
тарак
чәч
АЙ
келәм
пешекче
каен
китап
сабан

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ
www.tdpress.ru



www.куаныч.рф

ISBN 978-5-6046008-2-5

